# МӘГАРИФ

education

mәğәrif

просвещение

## ТАТАР ТЕЛЕ

№1/ 2024



Оештыручысы:
**«ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ЖӘМГЫЯТЕ**

МӘГАРИФ education
ТАТАР ТЕЛЕ

5 МАРТ, 2024 ел

№ 1

12+

УЧРЕДИТЕЛЬ: **АО «ТАТМЕДИА».**
Телефон редакции: (843) 222-06-09

Адрес издателя:
420097, г.Казань,
ул. Академическая, 2

www.magarif-uku.ru

Создано при поддержке Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям.

Зарегистрирован в Федеральной службе по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций 04.09.2014 г.

**Эл № ФС 77 – 59204**

Периодичность выхода – 1 раз в квартал.

Мнение редакции не всегда совпадает с мнением авторов. Редакция не располагает возможностью выступать ходатаем в официальных организациях. За достоверность рекламных объявлений ответственность несёт рекламодатель.

Почтовый адрес:
**420066, г.Казань, а/я 47**
**e-mail:** magarif@bk.ru

**Адрес:** 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.
«Мәгариф» журналы редакциясе, а/т 47
**E-mail:** magarif@bk.ru
**Сайт:** magarif-uku.ru
«Мәгариф», 2024 ел

Баш мөхәррир: **Таишева С.Н.**
Чыгаручы мөхәррирләр: **Фаизова Р.Г., Сабирҗанов Т.Ә., Сабиров А.З.**
Әдәби редактор: **Газизова И.М.**
Корректор: **Фәйзуллина Р.Ә.**
Вёрстка: **Халитова Э.И.**

Беренче тышлыкта:
Сабадагы «Сәләтле балалар өчен мәктәп-интернат»ның татар теле һәм әдәбияты укытучысы Ләйсән Шәмсетдинова укучылары Фәридә Хурамшина, Муса Мияссаров, Ильвина Идиятова, Раяз Гарифуллин, Мөслимә Хәлимова, Миләүшә Нәҗметдинова белән

*Альберт САБИР фотосы*

*3, 4, 6 нчы битләрдә Альберт САБИР фотолары*
*20, 22, 41, 47, 51, 56, 67, 70, 74, 78 нче битләрдә Сюмбел ТАИШЕВА фотолары*
*8, 12, 16, 26, 30, 63 нче битләрдәге фотолар «Мәгариф» редакциясе архивыннан алынды*
*35 нче битендә Алмаз Гыймадиевның фотоархивыннан*

*Журнал распространяется бесплатно.*

**АЛЬБЕРТ САБИР.** АНА ТЕЛЕ БЕР ГЕНӘ УЛ....3

**ЛАРИСА ИСМӘГЫЙЛЕВА.** УКУЧЫЛАРНЫҢ ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫГЫН ҮСТЕРҮ – ЗАМАН ТАЛӘБЕ....8

**Гөлназ КАМАЛОВА.** ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ....12

**ГӨЛНАЗ ВӘЛИЕВА.** СИНОНИМ СҮЗЛӘР. СӨЙЛӘМДӘ СИНОНИМНАРНЫ ДӨРЕС КУЛЛАНУ....16

**ГӨЛНАРА ЗАРИПОВА.** «ТӘН ӘГЪЗАЛАРЫ» ТЕМАСЫН КАБАТЛАУ...20

**РУЗИЛӘ САБИРОВА, ЛИЛИЯ ГЫЙЛАҖИЕВА.** Г. ТУКАЙНЫҢ «СУ АНАСЫ» ӘКИЯТЕНДӘ ҮТКӘН ЗАМАН ХИКӘЯ ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ....22

**ГӨЛҮЗӘ ГЫЙМАДИЕВА.** КИСӘКЧӘЛӘР....26

**РӘСИМӘ ИБРАЕВА.** СҮЗ ЯСАЛЫШЫ, ЯСАГЫЧ КУШЫМЧАЛАР ЯЛГАНУ ЫСУЛЫН КАБАТЛАУ....30

**ЭЛЬМИРА ГАЗИЗОВА.** АЛМАЗ ГЫЙМАДИЕВНЫҢ «ИНТЕРНЕТТА – ALF» ХИКӘЯСЕ....35

**ЗИЛӘ ЗИННӘТОВА.** ҺАДИ ТАКТАШНЫҢ «МОКАМАЙ» ШИГЫРЕ...41

**РИММА БИККИНИНА.** «АЛМАШЛЫКЛАР» ТЕМАСЫН ГОМУМИЛӘШТЕРЕП КАБАТЛАУ....47

**НӘЗИЛӘ ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. КЕШЕ БУЛЫП КАЛА БЕЛ!**....51

**ЛӘЙСӘН ВӘЛИЕВА.** 9 НЧЫ СЫЙНЫФТА ТАТАР ТЕЛЕННӘН ДӘҮЛӘТ ЙОМГАКЛАУ АТТЕСТАЦИЯСЕ БИРЕМНӘРЕ....56

**ГӨЛФИЯ ГАЛИЕВА.** И.ЮЗЕЕВНЕҢ «ӨЧӘҮ ЧЫКТЫК ЕРАК ЮЛГА» ПОЭМАСЫН ӨЙРӘНҮ....63

**ЛӘЙСӘН БАҺАВИЕВА.** ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ «ӘЙТЕЛМӘГӘН ВАСЫЯТЬ» ХИКӘЯСЕ....67

**ЗИЛИЯ ГАЛИМУЛЛИНА.** ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘТҮДӘ «МАВЫКТЫРГЫЧ КЕЛӘМ» УЕНЫ....70

**ГӨЛНАРА ГАЛИМОВА.** МӘКТӘПТӘ НЕЙРОН ЧЕЛТӘРЛӘРЕН КУЛЛАНУ...74

**Ләлә МОРТАЗИНА.** ШИҺАБ ХӘЗРӘТ УКУЧЫСЫ....78

1




# АНА ТЕЛЕ БЕР ГЕНӘ УЛ




*Тел – җәмгыятьнең, һәрбер аерым шәхеснең берни белән дә алыштырып булмый торган рухи байлыгы. Ул халыкның акыл хәзинәсен, гореф-гадәтен, иң яхшы традицияләрен, дөньяга карашын, мәдәниятен борынгы заманнардан түкми-чәчми безнең көннәргә алып килгән. Туган ил һәм туган тел сүзен һәркем хөрмәт белән әйтә, алар бер-берсенә аваздаш булып ишетелә. Бу ике сүз күңелләрдә якынлык, кардәшлек хисе, Туган иленә һәм халкына тирән мәхәббәт тойгысы уята. Туган телен кадерләгән халык кына кадерле, абруйлы халык була. Менә ни өчен ана телен яхшы белергә, аның бөтен нечкәлекләрен өйрәнергә һәм өйрәтергә кирәк.*

*Сабадагы 10 ел элек ачылган «Сәләтле балалар өчен мәктәп-интернат»ның югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Ләйсән Тимергали кызы Шәмсетдинова белән әңгәмәбез шушы кыйммәтләр турында сөйләшүдән башланды.*

**– Ләйсән ханым, Сабада күпчелек татарлар яши, әмма уку программасы милләткә карап төзелми, төп фәннәр рус телендә укытыла. Бу туган телебезне өйрәнүгә кызыксынуның кимүенә китермиме?**

–Һич тә алай түгел. Туган телебез бар, һәм ул яшәргә хаклы. Чыннан да, без – республикада саф татар телендә сөйләшүче районнарның берсе. Безнең мәктәптә 188 бала белем һәм тәрбия ала, алар арасында милли җанлы, туган телен – татар телебезне яратып өйрәнүче укучыларым бик күп. Моны еллык нәтиҗәләр дә раслап тора. Һәр уку елында да татар теле һәм әдәбияты буенча фән олимпиадаларының йомгаклау этабында һәм татар теле буенча халыкара олимпиадада укучыларым призлы урыннар ала. Сүзләремне анда катнашучы укучыларымның уңышлары дәлилли. Соңгы елларда республика күләмендә туган тел һәм әдәбияттан алар 33 призлы урынга чыкты, 2 укучым халыкара олимпиада җиңүчесе һәм 4 се призёр булды. Алар арасыннан Дилә Гайзуллина, Динә Сөләйманова, Фәридә Хурамшина, Миләүшә Нәҗметдинова, Рәяз Гарифуллин, Галия Шәрифуллина, Аделина Әхмәтҗанова, Айсылу Кәримуллина күп тапкырлар татар теленнән тирән белемгә ия булуларын күрсәттеләр. Түбәнрәк сыйныфлардан Мөслимә

Хәлимова, Лилиана Шәмсетдинова, Мәрьям Сәйфетдинова, Зөлфинә Хәлилова, Әдилә Мөхәммәдиева, Камилә Гарифуллина аларның эзләренә басып килә. Шунысы куанычлы: алар бик күп, һәр сыйныфта тел-әдәбият өйрәнүгә сәләтле укучыларым бар. Алар, фән олимпиадалары белән бергә, иҗади бәйгеләрдә дә үзләренең осталыкларын күрсәтәләр. Әйтик, Ильвина Идиятова «Илһам» яшь язучылар бәйгесендә лауреат, «Аяз Гыйләҗев» укуларында, «Мин – журналист – 2023» республика бәйгесендә призёр булды. Язилә Гаттарова фән олимпиадасында, конференцияләрдә уңышлы чыгыш ясый. Бу – туган телебезне саклауның бер чагылышы.

Саба район хакимияте башлыгы Рәис Нургали улы Миңнеханов та туган телебезне саклауга, үсеп килүче буыннарга җиткерүгә игътибарлы. Татар теле һәм әдәбияты дәресләре сәгатьләрен саклап калу, милли компонент нигезендә өстәмә дәресләр бирү, укучыларыбызга һәм укытучыларга фән олимпиадаларында җиңгән өчен премияләр түләү – барысы да аның ярдәме белән башкарыла.

**– Балада туган телгә карата кызыксындыру уятуның, аны матур сөйләшергә, аралашырга өйрәтүнең юллары, ысуллары күп. Шәхсән Сезнекенә тукталыйк.**

– Бүгенге көн таләпләреннән чыгып караганда, укучыны дәреслектәге кагыйдәләрне ятлап, дөрес итеп сөйләп бирү кебек формаль эшләр генә канәгатьләндерә алмый. Минем үземә хас укыту алымнарым бар. Галимнәрнең, тәҗрибәле укытучыларның бай мирасын өйрәнәм һәм шуларны эш барышында кулланам. Ул теория белән гамәли күнегүләрнең бергә үрелеп баруыннан гыйбарәт.

Баланы алган белемне киләчәктә кулланырга өйрәтү, иҗади фикерләвен активлаштыру, сөйләм культурасын булдыру – тел укытуга куелган төп таләпләр. Укучыларыбыз телдән һәм язма сөйләм телен үстерү дәресләрендә үз фикерләрен дөрес итеп башкаларга җиткерә белүнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнен аңлап үсәләр.

Туган телне өйрәнү өчен укучыда бу телгә ихтыяҗ булырга тиеш. Бездә ул бар. Башка районнардан аермалы буларак, Саба җирлегендә татар рухы сизелеп тора, җәмәгать урыннарында, хакимият оешмаларында туган телебездә аралашабыз. Балалар тирән мәгънәгә ия булган «Кыңгырау», «Әллүки», «Бәрәкәт», «Тулпар», «Матурай» кебек элмә такталарны кафега, балалар бакчасына, кибеткә кергән саен күрәләр. Бу мәгълүмат күз нурлары аша аларның күңелләренә сеңә бара.

Әгәр элмә librтакталар татар телендә язып куелган икән, монысы аларның хуҗалары – безнең элеккеге укучыларыбызның телебезне саклауга керткән шәхси өлеше дияр идем. Димәк, без дә аларга үз вакытында дөрес белем һәм тәрбия биргәнбез. Кибетләрдә сатыла торган әйберләрнең исеменә, ярлыкларына – аңлатма язуларына игътибар иткәнегез бардыр. Сатудагы әйберләрнең күпмесендә ярлыклар татарча, русча һәм башка телләрдә язылган икән? Дәресләремдә, балаларның игътибарын туган телебезгә җәлеп итү максаты белән, менә шулай аларны уйланырга, эзләнергә этәрүче темаларга проект эшләре бирәм. Эзләнү, табу, чагыштыру алымнарын укучыларыбыз аеруча




үз итә, кызыксынып эшлиләр, күп нәрсәгә өйрәнәләр.

Мәктәбебезгә тирән белем алырга, фән олимпиадаларында, бәйгеләрдә катнашырга зур теләкләре булган укучылар тупланган. Алар арасында күрше районнардан килүчеләр дә бар. Мәктәптә көннең икенче яртысында алган белемне ныгыту, өстәмә белем алу өчен төрле түгәрәкләр эшли. Онлайн-дәресләр үткәрү өчен махсус җиһазланган кабинетларыбыз да бар. Белем алу өчен бездә барлык шартлар да тудырылган. Хәтта соңгы вакытта мәктәпнең ике телдә дә тапшырулар алып бара торган үз телевизион үзәге ачылды. Ул укучыларыбызга яңа офыклар ачар дип өметләнәбез.

**– Саба ул – Г. Камал театрында үлемсез Әлмәндәр ролен иҗат иткән СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров туып үскән төбәк. Телне, гореф-гадәтләрне саклауда шәхесләрнең дә роле зур бит әле**.

– Сүз дә юк, туган телебезне саклауда, үстерүдә театрның роле бик зур. Бездә «Күңелле сәхнә» театр түгәрәге эшләп килә, укучылар төрле бәйгеләрдә катнаша. «Шәүкәт Биктимеров» исемендәге республика балалар театр сәнгате бәйгесендә ел саен уңышлы чыгыш ясыйлар. Быелдан башлап 8, 10 нчы сыйныфларга дәрестән тыш эшчәнлек буенча «Театр яктылыкка, нурга илтә»

дип исемләнгән факультатив дәрес керә башлады. Балаларны сәхнә теленә өйрәтү бик кирәк. Республикабыз мәдәнияте һәм сәнгате, шуның белән бәйле экскурсияләр укучылар көнделендә аерым урын алып тора. Беренче яртыеллыкта Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачылар театрына барып, «Рөстәм маҗаралары» спектаклен карадык, Шәрык клубында тарихи күргәзмәләр белән таныштык. Алга таба Галиәсгар Камал театрына һәм Муса Җәлил музеена баруны ниятләп куйдык. Район мәдәният йортында куелган спектакльләрне һәрдаим карап барабыз.

**– Сезнең мәктәптә рус теленнән Татарстанның халык укытучысы Гөлнур Габделгазиз кызы Байкиева белем бирә. Шундый дәрәҗәле мөгаллимә укыткан белем йортында балаларның татар һәм рус телләрендә бер дәрәҗәдә иркен сөйләшүләренә һич тә гаҗәпләнмим. Үзегездә телгә, гореф-гадәтләребезгә мәхәббәт каян килә?**

– Мин, үзем бөтен предметларны саф татар телендә укып, Казан педагогика университетын тәмамлаган белгеч. Гореф-гадәтләргә хөрмәтне кечкенәдән әбием тәрбияләде, тәртипкә өйрәтте, бишек җырлары, догалар ятлатып, бүләкләр бирә иде. Бу рухи-әхлакый тәрбиянең, туган телгә мәхәббәт уятуның бер формасы булган. Кечкенәдән каз өмәләрендә катнашып, көтү көтеп, Сабантуйларда ярышып, спектакльләрдә катнашып үскән авыл кызы мин. Бала чакта алган тәрбия бүгенге көндә туган телемне укытуда зур ярдәм итә.

Гөлнур Габделгазизовна белән, мәктәп ачылганнан бирле, бер коллективта эшлибез. Ул – минем өчен остаз, киңәшче, сердәшче дә. Беренчедән, татар теле белән рус теленең охшаш яклары бик күп, тәрҗемә өлкәсендә дә киңәшләшеп эшләү отышлы. Аннары, тәҗрибәле укытучы буларак, ул дәрестә сөйләм тембры, тавышны дөрес итеп кую, укучыларның игътибарын тоту кебек серләре белән бүлешә. Фән олимпиадаларында укучыларыбыз ике фән буенча да бик теләп катнаша. Монысы да – уртак шатлык, үзара фикерләшер, тәҗрибә уртаклашыр өчен үзенә күрә бер җирлек. Яшь мөгаллимнәргә абруйлы остаз белән аралашып, бер коллективта эшләү һөнәри үсешкә ирешүдә үзе зур этәргеч ул.

**– Ләйсән ханым, бүгенге көн укытучысы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш дип саныйсыз?**

–Укытучы хезмәте күп көч сорый. Шул ук вакытта кызыклы да, мавыктыргыч та. Иң мөһиме – укытучы балаларны бәхетле булу серләренә өйрәтергә тиеш. Телләр белү – зур бәхет, минемчә. Моннан 2000 еллар элек Сократ: «Һәрбер кеше көнделендә кояш яши, бары тик аңа яктылык тарату мөмкинлеге бирегез», – дигән. Безнең һәркайсыбыз күңел җылысын, ярату хисен башкаларга бирә. Шуңа күрә укытучы, кояш кебек, күбрәк елмаерга тиеш. Уңышка ирешүнең төп формуласы – танылу, ягъни куйган хезмәтеңнең нәтиҗәсен укучыларыңның, ата-аналарның, әйләнә-тирәдәгеләрнең күзләрендә очкыннар итеп күрү шатлыгы ул. Хәзерге заман укытучысы ирешелгәннәр белән генә канәгать булып яши алмый. Ул һәрвакыт алга карарга, заман белән бер сафта барып, гел эзләнеп яшәргә тиеш. Чөнки, син – Укытучы! Мин әнә шуңа омтылам.

**Альберт САБИР**



# УКУЧЫЛАРНЫҢ ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫГЫН ҮСТЕРҮ – ЗАМАН ТАЛӘБЕ

**Лариса ИСМӘГЫЙЛЕВА,**

Казандагы 39 нчы урта мәктәпнең
I квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартларында әйтелгәнчә, бүгенге шартларда укучыларның функциональ грамоталыгын үстерү иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора, һәм ул, беренче чиратта, укытучының функциональ грамоталыгы дәрәҗәсе белән тыгыз бәйләнгән[1]. Әлеге мөһим мәсьәләне хәл итү максатыннан, мәктәбебезнең педагогик коллективы эзлекле һәм системалы эш алып бара. Агымдагы уку елында педагогик эшчәнлеге «Белем һәм тәрбия бирүнең югары сыйфатына ирешү факторы буларак укучыларның функциональ грамоталыгын үстерү» дигән фәнни-методик теманы гамәлгә ашыруга юнәлтелгән[2]. Мәктәбебезнең төп максаты – иҗади, социаль һәм профессиональ яктан компетентлы шәхес тәрбияләү өчен, барлык мөмкинлекләр булдыру һәм шартлар тудыру. Куелган максатка ирешү өчен, мәктәптә эшләүче һәр укытучы үз фәне буенча белем бирүнең сыйфатын тагын да яхшыртырга омтыла, заманча педагогик технологияләрдән файдалана, үзенең методик осталыгын өзлексез арттыруның кирәклеген аңлап эш итә. Бүгенге көндә төп игътибар укучыларның функциональ грамоталыгын үстерүгә юнәлтелә, чөнки әлеге мәсьәлә иң мөһимнәрдән санала.

Галимнәр һәм педагоглар фикеренчә, функциональ грамоталык формалаштыру өчен, уку-укыту процессына кайбер үзгәрешләр кертү сорала. Алар арасында иң әһәмиятлеләре: дәресләрдә укучыларның гамәли эшчәнлеген тәэмин итә торган ситуацияләр куллану; коллективта, төркемдә яки парлап аралашу аша яңа белемнәрне үзләштерүгә ирешү; эзләнүгә корылган төрле биремнәр эшләтү һәм проектлар яклатуга өстенлек бирү; укучыларны мөстәкыйль рәвештә үзбәя бирергә күнектерү[3].

Алдыбызда торган актуаль бурычларны исәпкә алып, мәктәптә махсус педагогик совет утырышы үткәрелде. Аның темасы: «Педагогның функциональ грамоталыгыннан укучыларның функциональ грамоталыгына ирешү» дип билгеләнгән иде. Анда мәктәп укытучылары алдынгы тәҗрибәләре белән уртаклаштылар. Мәсәлән, башлангыч мәктәп укытучылары балаларның уку грамоталыгын үстерүгә юнәлтелгән дәрес эшкәртмәләре белән таныштырдылар. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары укучыларның функциональ грамоталыгын формалаштыру максатыннан үткәрелгән

---

[1] ФГОС ООО *https://www.garant.ru/products/ipo/prime/doc/401333920/*

[2] Сайт МАОУ «СОШ №39» *https://edu.tatar.ru/vahit/kzn/sch39*

[3] Фролова П.И. К вопросу об историческом развитии понятия «Функциональная грамотность» в педагогической теории и практике // Наука о человеке: гуманитарные исследования. 2016. №1 (23). *URL: https://cyberleninka.ru/article/n/k-voprosu-ob-istoricheskom-razvitii-ponyatiya-funktsionalnaya-gramotnost-v-pedagogicheskoy-teorii-i-praktike* – 25 с.

сыйныфтан тыш чараларның эшкәртмәләрен тәкъдим иттеләр. Мисал буларак укучыларның төрле темаларга эшләнгән иҗади эшләре күрсәтелде («Укыйбыз һәм укыганның эчтәлегенә карата үз мөнәсәбәтебезне белдерәбез: моңсуланабыз, шатланабыз, гаҗәпләнәбез»; «Кемне чын китап укучы дип атап була?» һ.б.). Әйтелгәннәрдән күренгәнчә, мәктәп укытучылары әлеге юнәлештә максатчан эш алып бара. Кайсы гына дәресне алсак та, укытучы балаларны, беренче чиратта, мәгълүматны кабул итәргә, аңларга һәм аның нигезендә үз текстын булдырырга өйрәтә.

Функциональ грамоталык турында сүз алып барганда, беренчедән, алган белемнәрне тормышта куллану күнекмәләре булдыруны күз алдында тотабыз: яңа мәгълүматны табу, аның дөреслеген раслау, шуның нигезендә мөстәкыйль эшчәнлек оештыра алу. Проблемалы биремнәрне эшләгәндә, укучыларның максатчанлыгы, фикерләү сәләте, аралашу культурасы үсеш ала. Аңлашыла ки, укучыларда шундый күнекмәләр булдыру өчен, укытучы үзе дә әлеге осталыкларга ия булырга тиеш. Педагогик тәҗрибә күрсәткәнчә, укучыларның функциональ грамоталыгы үсеш алсын өчен, берничә таләпне үтәргә кирәк: аларның тәнкыйди фикер йөртү һәм коммуникатив күнекмәләрен үстерү; фикер алышуларда катнашып, үз мөнәсәбәтен телдән яки язмача белдерергә күнектерү; дөньяны танып белү процессын оештырырга өйрәтү (максат кую, план төзү, кирәкле карарны кабул итү, анализлау, нәтиҗә ясау һ.б.).

Без, мәктәбебезнең барлык татар теле һәм әдәбияты укытучылары да, рус төркемнәрендә «Сәлам» УМКсына нигезләнеп белем бирәбез. «Сәлам» УМКсында түбәндәге функциональ грамоталылыклар исәпкә алынган:

1. Компьютер грамоталылыгы үсеше өчен җирлек тудыру.

**Эш төрләре:**

– өй эше итеп Интернет чыганакларыннан мәгълүмат табып килү; проект эшләрен башкару; диаграммалар төзеп килү һ.б.

2. Коммуникатив грамоталылык үсеше өчен җирлек тудыру.

**Эш төрләре:** төркемнәрдә эш; текстка сораулар уйлау; диалоглар төзү; репликалар өстәү.

3. Чит телне үзләштерү грамоталылыгы *(рус телле укучылар татар телен чит тел буларак өйрәнә)*.

**Эш төрләре:** яңа сүзләр өйрәнү; сүзлекләр белән эш.

4. Көнкүреш проблемаларын хәл итү грамоталылыгы.

Мәсәлән, «Ашамлыклар» темасында кибеттә сатып алырга, сайлап алырга өйрәнәләр.

«Өем зур» темасын өйрәнгәндә, җиһазлар, бүлмәләр, өйдәге техника, савыт-саба белән танышу һ.б.

5. Финанс грамоталылыгы үсеше өчен җирлек тудыру.

Мәсәлән, мегаполис, шәһәрләр, кечкенә шәһәрләр турында сөйләшкәндә, кайда яшәү яхшырак? Ни өчен? Эш хакы турында сөйләшү һ.б.

6. Уку грамоталылыгы – функциональ грамоталылыкның иң

мөһим өлеше. Ул укучыда текстларны аңлау, куллану, бәяләү, алар турында уйлау сәләтен үстерә.

**Эш төрләре**

– Текстларны укыйлар, тәрҗемә итәләр, сүзлек өстендә эшлиләр, сорауларга җавап бирәләр.

– Текст буенча өстәмә биремнәр – дөрес/ялгыш, тоташтыр, җөмлә төзе, абзацларга исем бир, план төзе, төшеп калган сүзләр белән текст яз (аудиоязма тыңлыйлар).

– Җыр текстлары укыйлар, җырлыйлар.

– Тексттагы рәсемнәрне сүзләр белән алмаштыру.

«Сәлам» УМКсы белән танышуны йомгаклап, шуны әйтеп була: дәреслектә функциональ

грамоталылыкка карата барлык юнәлешләр дә кулланылган: булган мәгълүматны укып, язу белән ныгыту, аңлаганны, истә калганны башкаларга җиткерү һ.б.

Функциональ грамоталылык кешенең тышкы мохит белән мөнәсәбәтләргә керү, анда җайлашу һәм эзләнү сәләтен күзаллый. Ә «Сәлам» УМКсында уеннар аша кешенең чын тормышын күрсәтү һәм ачып бирү чагыла.

Татар телен чит тел буларак укытканда, уку грамоталылыгының төп компонентлары: сүз байлыгын киңәйтү; контексттан таныш булмаган сүзләрне аңлау; грамматик категорияләрне ныгыту; сөйләм күнекмәләрен камилләштерү.

Эш вакытында укучыларда универсаль уку гамәлләре: танып белү, коммуникатив, регулятив, шәхси гамәлләр формалаша.

Түбәндә 3 нче сыйныф дәреслеге буенча «Сәлам» УМКсы тәкъдим иткән текст өстендә эш формалары белән танышып үтик.

Текст өстендә эшләүнең 3 этабы бар: укуга кадәр; уку вакыты; укудан соң.

**Укуга кадәрге этап**

Бу этапта укучыда мотивация тудырабыз, тел һәм сөйләм авырлыкларын киметү өстендә эшлибез.

1. Текст белән танышуны мәкальдән башлап җибәреп була.

«Хәрәкәттә – бәрәкәт». Бу мәкаль нинди максат белән язылган?

2. Текстның исеме белән бәйле ассоциацияләрне әйтү (сәламәтлек, саф һава һ.б.).

3. Рәсемнәр ярдәмендә текстның тематикасын уйлау.

**Уку вакыты этабы**

Бу этапта укучыларның тел күнекмәләрен үстерү, сөйләм осталыкларын киңәйтү өстендә эшлибез.

**Күнегүләр**

1. Текстта сорауларга җавап тап.
2. Дөресме/ялгышмы?
3. Җөмләләрне тәртип буенча урнаштыр һ.б.

**Укудан соң этап**

Бу этапта укучыларда тел һәм язу кунекмәләрен, танып белү активлыгын үстерәбез.

Укучылар текстның төп фикерен әйтәләр, текстны өлешләргә бүләләр, план төзиләр һәм, планга таянып, текстны сөйлиләр.

Йомгак ясап, шуны әйтергә кирәк: укучыларның функциональ грамоталыгын үстерү яшь буынны үзгәреп тора торган тормыш шартларында үзара хезмәттәшлеккә әзерләүне үз эченә ала. Әлеге юнәлештә уңышка ирешү өчен, мәктәпнең педагогик коллективыннан бердәм эшчәнлек алып баруы зарур.




# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ

**Гөлназ КАМАЛОВА,**

*Мамадыштагы академик К.Вәлиев исемендәге 2 нче лицейның югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Бүген укытучыдан бик күп нәрсә таләп ителә: үз фәнеңне бик яхшы белү, балаларны яратудан тыш, аларның фикерләү сәләтен үстерү, уку-танып белү эшчәнлеген оештыру, рухи һәм физик үсешен тәэмин итү. Ә моның өчен укытучыдан үз шәхесенә тәнкыйть күзлегеннән карау, яңалыкка омтылу, заман сулышын тоеп, белемне өзлексез камилләштерү, укыту-тәрбия процессына иҗади якын килеп эшләү сорала. Заман таләбе кушуы буенча, укучыларның компьютер технологияләренә булган кызыксынуларын истә тотып, «Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә инновацион технологияләр куллану» проектын тормышка ашыру өстендә эшлим. Проект эшемне академик Ә. Хуҗиәхмәтовның «Педагогик технологияләр» исемле фәнни эшенә нигезләнеп алып барам.

**Төп максатым**: белем сыйфаты белән идарә итү өчен төрле юллар һәм алымнар кулланып, киләчәктә илнең чын хуҗалары була алырлык белемле, акыллы, сау-сәламәт шәхес тәрбияләү.

**Бурычларым:**

– укучыларның белемгә булган омтылышларын үстерү;

– махсус белем һәм күнекмәләр формалаштыру;

– иҗади эшчәнлекне үстерү мөмкинлеген тудыру;

– укучыларның фикерләү сәләтен үстерү.

**Педагогик проектта катнашучылар:** укытучы, укучылар, ата-аналар.

**Проектны башкару вакыты:** 4 ел.

Ике ел эчендә «Татар теле һәм уку дәресләрендә инновацион технологияләр куллану» проекты буенча эш билгеле бер системага салынды. Ул параллель рәвештә дәресләрдә һәм сыйныфтан тыш эшләрдә тормышка ашырыла.

Шушы педагогик проект буенча үткәрелгән дәресләр уңай мотивация тудыра. Укучыларның танып белү эшчәнлеген активлаштыру һәм укучыларда уңай мотивация булдыру өчен төрле эш методлары һәм алымнары кулланып эшлим.

1. Уку материалын аңлатканда:

– сүз белән эшләү методлары (сөйләү, сүзлек эше, әңгәмә һ.б.);

– гамәли методлар (күнегүләр, буклетлар, презентацияләр эшләү, электрон дәреслекләр чыгару кебек методлар) кулланам.

2. Фикерләү, уку эшчәнлеге белән идарә иткәндә исә проблемалы эзләнү методына (проблемалы сорау кую, проблемалы ситуация тудыру, үзаллы, парлы, группаларда эшләү, фәнни-тикшеренү эшләре) өстенлек бирәм.

Дәрестә дә, өй эше итеп тә эзләнү, тикшеренү, уйлану таләп иткән эшләр бирергә тырышам.

3. Уку эшчәнлеген активлаштыру өчен дәресләрдә эмоциональлеккә ирешү, танып белү уеннары, уңыш ситуациясе булдыру, үзара ярдәм оештыруны отышлы алым дип саныйм.

Эш ике юнәлештә алып барыла: дәрес вакытында халкыбызның телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, күркәм йолаларын, тарихи үткән юлын теоретик яктан тирәнтен өйрәнсәк, сыйныфтан тыш эшләрдә иҗади эзләнү эшенә күбрәк игътибар бирәм. Шул рәвешле, балалар иркен, мөстәкыйль фикер йөртү дәрәҗәсенә ирешә.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә информацион технологияләрне куллануның

өстенлекле яклары күп:

– материал югары күрсәтмәле дәрәҗәдә булуы белән отышлы;

– укучының шәхси сыйфатларын ачыкларга мөмкинлек була;

– контроль һәм үзконтроль дәрәҗәсе югары;

– төрле дәресләрнең үзара бәйләнешен булдыру мөмкинлеге бар;

– укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү дәреснең эчтәлеген баерак һәм кызыграк итә.

Дәрес үткәргәндә, еш кына интерактив тактага мөрәҗәгать итәм, чөнки интерактив такта куллану дәресләрне тагын да мавыктыргыч, нәтиҗәле итә. Төрле темага күрсәтмә материаллар һәм укыту ресурсларын табарга һәм аларны кабат-кабат файдаланырга мөмкин. Бу алым укучыларның белем сыйфатын үстерергә булыша. Яңа материалны һәр укучыга җиңел, аңлаешлы итеп җиткерергә дә ярдәм итә.

Яңа стандартлар кертү сәбәпле, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә **проектлар методын** куллану отышлы, чөнки бу метод **–** укучыларның билгеле бер нәтиҗәгә ирешүен максат итеп куйган ысул. Проектлар методы укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән. Ул – теге яки бу проблеманы тирәнтен өйрәнү максатында, укытучы җитәкчелегендә эшләнә торган мөстәкыйль иҗади эш.

Проект методын куллануның уңай яклары:

1. Тел һәм әдәбият буенча материал белән таныштыру карала.

2. Укучы дәресләрдә төп белем ала, эш төрләре, кагыйдәләр белән таныша.

3. Бу метод кызыксынучанлыкны, һәр яңа эш төрен ихлас, дәртле итеп башкару теләген уята.

4. Проекттагы информация һәр дәрестә укучының күз алдында була, кирәк вакытта ул аңа мөрәҗәгать итә ала. Бу исә материалның хәтта йомшак укучылар тарафыннан да үзләштерелүен тәэмин итә.

Күпчелек очракта бу эш төркемнәрдә эшләнә һәм берничә этаптан тора.

**Проект өстендә эш этаплары:**

1. Проект темасын тәкъдим итү. Иҗади эшләрнең тематикасы дәрестә үзләштергән белемнәрне тирәнәйтү, актуальләштерү, гамәлдә куллануны таләп итәрлек итеп сайлана. Мәсьәлә кую.

2. Эш юнәлешен сайлау. Балаларны төркемнәргә бүлү. Информация җыю алымнарын сайлау һәм эзләнүне башлау. Беренче нәтиҗәләрне тикшерү.

3. Проектны презентацияләү, бизәү һәм яклау.

4. Йомгаклау, нәтиҗә чыгару.

Проект методикасы куллану түбәндәге бурычларны үти:

– Эш барышы телне өйрәнүгә теләк уята.

– Проект эшен оештыру барышында укучылар үзара аралаша, укытучы тикшерүче ролен түгел, киңәшче ролен үти.

– Укучыны билгеле бер тема өстендә иҗади эшләргә, төрле чыганакларны кулланып, үзаллы мәгълүмат табарга өйрәтә, уку

эшчәнлеге активлаша.

– Бөтен уку процессы укучыга юнәлтелә, аның кызыксынуы, тормыш тәҗрибәсе, шәхси сәләтләре искә алына.

Гомумән, проектлау технологиясенең кулланылу даирәсе бик киң, аны дөрес һәм урынлы кулланганда (укытучы үзе кирәкле дип тапканда), укытучыга ышанычлы ярдәмче функциясен үти ала. Ә иң мөһиме шул: схема-проектны һәр дәрестә файдалану үзмаксат түгел, ә проект укучыларның белем алуда активлыгын тәэмин итү, предметка карата кызыксыну уяту, төпле белем бирү чарасы булуын истән чыгарырга ярамый.

Бүгенге көндә мәктәпләрдә төрле предметлардан компьютерлар өчен эшләнгән гамәли укыту программалары бар. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә куллану өчен дә интерактив дәреслекләр чыгарыла башлады. Миндә видеоматериаллар карауның тәэсирен кабатлауның нәтиҗәле ягы белән берләштерү теләге туды. Һәм Movie Maker программасына нигезләнеп, «Сайланган сәхнә сынавы» проектын төзедем. Проект өчен 5–7 минутлык кыска гына өзек сайлап алына. Балаларга иң якын «Г.Тукай әкиятләре» темасын сайладык. «Кәҗә белән Сарык хикәясе», «Шүрәле», «Су анасы» әкиятләре буенча проектыбыз әзер инде. Гомумән, видеоязмалар карауның төрле алымнарын үз эшемдә кулланам. Мәсәлән, 5–7 минутлык өзекне алдан карау, аннан тавышны ябып кабатлау барышында укучылардан диалог төзетү яки, киресенчә, рәсемне аерып куеп, тавышка нигезләнеп, әсәрне уйнап күрсәтү. Әсәрнең өзеген карау барышында бирелгән язмадагы бер герой турында репортаж язу һ.б. Сөйләм телен үстерү дәресләрендә куллану өчен презентацион программалар бик кулай. PowerPaint программасында укыган әсәргә иллюстрацияләр эшләргә, принтер аша чыгарып, һәр укучыга таратып та бирергә була. Бу эшләрне дә укучылар бик теләп башкара. М.Җәлил, Г.Тукай, Г.Ибраһимов кебек шәхесләрнең тормышын, иҗатын өйрәнү дәресләре өчен эшләнгән презентацион программаларыбыз да бар.

Әлбәттә, сәләтле балаларга аеруча игътибар итәм. Бу эшнең әһәмияте – шәхеснең перспектив үсешен фаразлауда. Табигать тарафыннан бирелгән иҗат һәм сәләт чаткылары булган балаларны туплау һәм үстерү – төп бурычыбыз.

«Шәкертләрне гыйлем белән тәрбияләү, изге шәригатьтә аңлатылган күркәм холыклар белән таныштыру һәм гадәтләндерү укытучының беренче эше булыр», – дигән Р. Фәхреддин. Бүгенге укучыларның төпле белем, яхшы тәрбия алырга тулы мөмкинлекләре бар. Безгә бары тик гыйлем алуга тырышлык, теләк һәм омтылыш тәрбияләргә кирәк. Укучыларыбыз милләтебез горурланырлык шәхесләр булсыннар иде.

4



# СИНОНИМ СҮЗЛӘР. СӨЙЛӘМДӘ СИНОНИМНАРНЫ ДӨРЕС КУЛЛАНУ

*(2 нче сыйныфта татар теле дәресе)*

**Гөлназ ВӘЛИЕВА,**

Балык Бистәсе районы Яңа Арыш урта мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы

**Максат:** синонимнар турында белемнәрне ныгыту; сүзләрнең синонимнарын табу, мәгънәдәш сүзләрне сөйләмдә дөрес куллану; синоним сүзләр ярдәмендә әкият геройларын тасвирлау; начар һәм яхшыны аера белергә өйрәтү, чисталык-пөхтәлек тәрбияләү; татар теле дәресләренә карата кызыксынучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлау:** уен өчен плакатлар, сүзле карточкалар, ноутбук, интерактив такта.

**Материал:** Шәкүрова М.М., Гыйниятуллина Л.М., Хисамов О.Р. Туган тел (татар теле). 2 нче сыйныф. Башлангыч гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен дәреслек.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру өлеше**

**Укытучы.** Исәнмесез, балалар! Хәерле көннәр сезгә!
Зиһен һәм тел ачкычлары
Телимен һәммәгезгә!

**Укучылар.** Хәерле булсын безнең дәресебез!
Хәерле булсын безнең һәр эшебез!

Елмай әле, син елмайсаң
Яратыр олы-кече.
Дөньяда иң матур кеше –
Елмайган, көлгән кеше!

**Укытучы.** Укучылар, бер-беребезгә карап елмаеп, татар теле дәресен башлап җибәрик.

**II. Актуальләштерү**

– Сүзнең лексик мәгънәсе темасын искә төшереп башваткычны чишәләр.

1. Кече яшьтәге ир бала. *(Малай.)*
2. Укырга өйрәтә торган дәреслек. *(Әлифба.)*
3. Әдәби әсәрдәге төп персонаж. *(Герой.)*
4. Шук, шаян. *(Наян.)*
5. Тылсымлы көчләр, сихерчеләр турында әсәр. *(Әкият.)*

– Өй эшен тикшерү.

**III. Проблемалы сорау ярдәмендә дәрес темасын ачу мәсьәләсен кую**

**Укытучы.** Укучылар, дәфтәрләрне ачабыз, числоны язабыз. Түбәндәге шигырь юлларын укып китик әле. Бу – безнең матур язу күнегүе.

Дөрес итеп утырыгыз, дәфтәрләрегезне дөрес итеп куеп, матур итеп күчереп язабыз.

***Туган тел – иң татлы тел,***
***Туган тел – иң тәмле тел.***

Шигырьне укыгыз әле. Бу шигырь юлларында сүз нәрсә турында бара? (*Туган тел турында.*) Автор аны нинди ди? (*Татлы, тәмле.*) Әйе. Бу сүзләр мәгънәләре белән ошаганмы? (*Әйе.*) Димәк, бүгенге темабыз нинди икән? ( *Бер мәгънәле сүзләр.*) Әйе, балалар, бүгенге темабыз бер мәгънәле сүзләр – синоним сүзләр.

**IV. Дәреслек белән эш. Синоним темасын аңлату**

Китапларның 91 нче битен ачабыз, 9 нчы күнегүне укыйбыз

1. Песи, песи, пескәем,
Соры синең төскәең.
*( Р. Миңнуллин)*

*2.* Балалар чана шуалар,
Эт чаба яннарында.
Урманга тәмле ис чыга,
Мәче сизә барын да.
(*Л. Гиматдинова)*

3. Минем бар маэмаем,
Кара борын Акбаем.
*(М. Җәлил)*

**Укытучы.** Шигырьләрдән бер үк мәгънәне белдерелгән сүзләрне табып укыгыз әле. *(Песи, мәче, эт, маэмай.)*

– Әйе, афәрин! Димәк, бу

сүзләр нинди сүзләр булалар? (*Синонимнар.*)

Дәфтәрләргә күчереп язып куябыз.

Кагыйдәне укыйбыз.

**Мәгънәләре охшаш сүзләр синонимнар дип атала.**

**Укытучы.** Укучылар, 10 нчы күнегүдәге рәсемне карыйбыз. Бу нинди әкияттән? («*Шалкан» әкиятеннән.*)



Әйе, дөрес. Бу шалкан нинди? (*Зур, дәү.*) Бу синонимнарны дәфтәргә язып куябыз.

Синонимнарны кулланып, әкият геройлары турында сөйләгез.

*Әби белән бабай дәү һәм өлкән. Мәче белән эт кечкенә, тычкан бәләкәй.*

**Ял минуты**

Яздым җөмлә, ижек, сүз.
Бик арыды минем күз.
Йомам күзем – ял итсен,
Ачам күзем – күп күрсен.
Тагын йомам һәм ачам,
Бер йомам да бер ачам.
Күзләр хәрәкәте белән
Зур әйләнә сызам.

V. **Карточкалар белән эш**

| | |
|---|---|
| Кечкенә | Дәү әни |
| Йорт | Бәләкәй |
| Бабай | Зур |
| Әби | Өй |
| Олы | Дәү әти |

– Бу синоним сүзләрне тоташтырыгыз.

– *Кечкенә – бәләкәй.*
*Йорт – өй.*
*Бабай – дәү әти.*
*Әби – дәү әни.*
*Олы –зур.*

**Укытучы.** Афәрин, булдырдыгыз! Укучылар, әйдәгез әле, сәнгатьле уку минуты үткәреп алыйк. «Кечкенә Кошчык» әкиятен рольләргә бүлеп укыйк.

Әкиятне уку.

**VI. Тест сорауларына җавап бирү.**

**а**) Кош ни өчен җылы якка очмый?

*1) теләми; 2) канаты сына; 3) өлгерми.*

**ә**) Кошчыкка кайсы агачлар ярдәм итә?

*1) чыршы, нарат; 2 )имән, нарат; 3) каен, имән.*

**б**) Ни өчен җил чыршы белән наратка тими?

*1) яшел булган өчен; 2) зур агачлар булган өчен; 3) кошчыкка ярдәм иткән өчен.*

**Укытучы.** Балалар, бу әкият нинди булырга өйрәтә? (*Ярдәмчел, кешелекле.*) Сез дә шундый булырсыз дип ышанып калам. Бер-берегезгә ярдәм итеп яшәгез. Кешелекле булыгыз.

– Ә хәзер *кечкенә, салкын, дус* сүзләренә синоним сүзләр уйлап язабыз.

**Тактага өч әкияттән язулар эленгән.**

| **Кечкенә** Кошчык | Йомры **икмәк** | Кечкенә кыз **яхшы** |
|---|---|---|
|  |  |  |

– **Бу геройлар кайсы әкиятләрдән?**

| | | |
|---|---|---|
| Кечкенә Кошчык | Йомры икмәк | Өч кыз |

**Укытучы.** Әйе, дөрес, афәрин! Әкиятләрне беләсез икән.

Кара белән бирелгән сүзләргә синоним сүзләр язарга кирәк.

*Кечкенә – бәләкәй.*

*Икмәк – күмәч.*

*Яхшы – әйбәт.*

Димәк, синонимнардан парлы сүзләр ясап була, дигән нәтиҗә ясыйбыз.

**VII. Рефлексив бәяләү**

Кагыйдәләрне кабатлау.

Бүген без нинди сүзләр өйрәндек? Нинди сүзләргә синоним сүзләр дибез? (*Мәгънәләре охшаш сүзләргә.)*

**VIII. Өй эше**

Синоним сүзләр кергән мәкальләр табып язарга.

**IX. Йомгаклау**

**Укытучы.** Укучылар, ничек уйлыйсыз? Синонимнарны телдә без ни өчен кулланабыз? (*Синонимнар куллану текстта кабатланулардан котылырга ярдәм итә. Синонимнар безнең сөйләмебезне баета, төрләндерә, эмоциональ яктан бизи.*)

**Укытучы.** Дөрес, балалар. Синонимнар телне баеталар, фикерне төгәлрәк әйтеп бирергә ярдәм итәләр. Бүгенге дәрестә актив катнашкан укучыларга «5» билгесе куям, ә калганнар исә киләсе дәресләрдә күбрәк җавап бирерләр, дип ышанам. Игътибарыгыз һәм хезмәтегез өчен зур рәхмәт. Дәрес бетте. Сау булыгыз!



5

# «ТӘН ӘГЪЗАЛАРЫ» ТЕМАСЫН КАБАТЛАУ

*(2 нче сыйныфта татар теле дәресе)*

**Гөлнара ЗАРИПОВА,**

*Казандагы 189 нчы күп профильле «Заман» гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Максат:** тән әгъзалары турындагы белемнәрен ныгыту, сөйләмдә дөрес куллана белү; исемнәрне тартым белән төрләндерү һәм сөйләмдә дөрес куллану, укучыларның коммуникатив эшчәнлекләрен активлаштыру; тән әгъзаларын чиста тоту, гигиена таләпләрен үтәүгә омтылыш тәрбияләү.

**Чыганаклар:** Р. З. Хәйдәрова, Н. Г. Галиева, Г. М. Әхмәтҗанова «Күңелле татар теле», «Сәлам» программасы.

**Җиһазлау:** таратма материал, интерактив такта, карточкалар, компьютер, экран.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру**

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Белемнәрне актуальләштерү**

**Укытучы.** Хәерле көн, укучылар, без бүгенге дәресебезне һәммәгезгә матур теләкләр белән башлап җибәрик әле! Хәлләрегез, кәефләрегез ничек? Укучылар игътибар иткән булсагыз, һәр төркем алдында хәрефләр бар, әйдәгез, шул хәрефләрдән сүзләр төзеп карыйк әле. Нинди сүзләр килеп чыкты? *(Күз, баш, чәч.)* Бик дөрес, шулай булгач, без сезнең белән нәрсә турында сөйләшербез икән? *(Кеше әгъзалары турында.)* Әйе, балалар, бик дөрес, бүген без сезнең белән тән әгъзалары турындагы теманы ныгытабыз, кабатлыйбыз. Бу сүзләрне ныгытыр өчен без нәрсә эшләрбез икән? *(Укыйбыз, сүзләр әйтәбез.)* Дөрес, укучылар, без бүген сезнең белән тән әгъзалары турындагы сүзләрне ныгытабыз, кабатлыйбыз, язабыз.

**III. Белемнәрне ныгыту**

**Укытучы.** Хәзер, әйдәгез, яхшы кәеф белән эшкә керешик. Сезнең алдыгызда бирем бар, игътибар итсәгез, анда күп итеп төрле хәрефләр язылган. Янында рәсемнәре дә бар. Рәсемнәрдә күргән әйберләрне татарча язып чыгып карыйк әле. Әйдәгез, тикшереп алыйк, укучылар! Тактада да эшлик әле шуны.

**Тактада рәсем җыю**

**Укытучы.** Укучылар, карагыз әле, безнең дәресебезгә Буратино килгән. Тик аның нигәдер төсе качкан, кәефе дә юк. Әйдәгез, без аны матурлыйк. Моның өчен мин сезгә сүзләр әйтәм, ә сез табып урынына ябыштырыгыз. *(Баш, күз, чәч, колак, борын, авыз, кул, аяк.)* Булдырдыгыз, укучылар! Дәресебезне дәвам итик.

**Диалог**

– Бу кулмы?
– Әйе, кул.
– Бу күзме?
– Юк, бу – күзләр
– Бу аякмы?
– Юк, бу аяк түгел, бу – куллар.

**Ял минуты**

*(Күз, борын, авыз, колак.)*

**Текст өстендә эш**

**Укытучы.** Укучылар, алдыгызда яткан текстны бер кат укып чыгыгыз.

*Алсу – бик чиста кыз. Ул иртән йокыдан тора, сабын белән кул һәм бит юа. Кечкенә щётка белән теш чистарта. Йомшак сөлге белән бит сөртә.*

– Игътибар белән тыңлагыз, бер кат укып чыгам. *(Чиратлап берәр җөмлә укып чыгалар. Сорауларга җавап бирәләр.)*
– Алсу чиста кызмы?
– Ул теш чистартамы?
– Алсу нәрсә белән битен һәм кулын юа?
– Алсу нәрсә белән бит сөртә?

**Укытучы.** Булдырдыгыз, укучылар. Хәзер тексттан тән әгъзалары булган сүзләрнең астына сызыгыз.

**IV. Диалог**

– Бу – минем кулым**.** Самир, ә бу синең кулыңмы?
– Бу синең башыңмы?
– Бу синең чәчеңме?

*(Диалогны дәвам итәләр.)*

**Тактада сүзләрне җыю**

**V. Өйгә эш**

**Укытучы.** Укучылар, сезгә өйдә малайның тән әгъзаларын буш шакмакларга дөрес итеп урнаштырырга кирәк булачак.

Үзегезнең яраткан героегызның рәсемен ясап, тән әгъзаларын языгыз.

**VI. Рефлексия**

**Укытучы.** Укучылар, без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләштек? *(Кеше һәм аның тән әгъзалары турында.)* Сезгә дәрес ошадымы? *(Әйе.)* Миңа да сезнең белән эшләве бик ошады. Үзегез өчен дә, минем өчен дә дәресне никадәр аңлавыгызны, дәреснең ошау-ошамавын билгеләп китегез. Буратинога үзегез сайлаган шарларны биреп чыгыгыз.

Кызыл шар – кызык булды.
Яшел шар – ошады.
Шәмәхә шар – аңламадым.

**Укытучы.** Барыгыз да бик актив катнаштыгыз, бик зур рәхмәт. Сау булыгыз!




6

# Г. ТУКАЙНЫҢ «СУ АНАСЫ» ӘКИЯТЕНДӘ ҮТКӘН ЗАМАН ХИКӘЯ ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ


*(4 нче сыйныф өчен интеграцияләштерелгән татар теле һәм инглиз теле дәресе)*

**Рузилә САБИРОВА,**

Арчадагы 5 нче гимназиянең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Лилия ГЫЙЛАҖИЕВА,**

Арчадагы 5 нче гимназиянең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы



**Максат:**
*Белем бирүдә:* татар телендә үткән заман хикәя фигыльләрнең ясалышын, зат-сан белән төрләнешен, җөмләдә кулланылышын инглиз теле белән чагыштырып кабатлау.
*Үстерелешле:* укучыларның сүз байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм телен, игътибарлыкларын үстерү, хәтерләрен ныгыту.
*Тәрбияви:* туган телгә мәхәббәт тәрбияләү, белем алуга ихтыяҗ булдыру, бер-берең белән парларда, төркемнәрдә эшләү өчен коммуникатив культура тәрбияләүгә шартлар тудыру.
**Метод һәм алымнар:** проект методы, интерактив (укучы–укытучы һәм бер-берең белән эшчәнлек итү).
**Дәреснең тибы:** белем һәм күнекмәләрне системалаштыру һәм ныгыту дәресе.
**Фәнара бәйләнеш:** инглиз теле, татар әдәбияты.
**Дәрес барышы**
**I. Оештыру өлеше**
**Татар теле укытучысы.** Хәерле көн, укучылар! Әйдәгез, бер-беребезгә хәерле иртәләр теләп, елмаеп, дәресебезне башлап җибәрик.
**Инглиз теле укытучысы.** Good morning boys, girls and our guests. We are very glad to see you. How are you?
Today we are having an unusual lesson. We are speaking both English and Tatar now. Sit down, please. Let's begin our lesson. **(1 нче слайд)**
**Татар теле укытучысы.** Укучылар, бүгенге дәресебез гади генә түгел, ә татар теле белән инглиз теле бергә бәйләнеп барачак. Шуңа күрә сездән зур игътибарлылык һәм активлылык сорала.
– Һәр дәрестә куллана торган, бүген дә онытмаска тиешле нинди өч кагыйдә бар? Шуны искә төшерик.
**Көтелгән җавап.** Тулы җөмләләр белән җавап бир. Give a full answer.
Игътибар белән тыңла. Be attentive.
Кеше фикерен кабатлама, үзеңнекен әйт. Think yourself.

**II. Белемнәрне актуальләштерү**
**Татар теле укытучысы.** Ә хәзер игътибарны экранга юнәлттек, фонетик зарядка, ягъни авазларны кабатлап алабыз.
**Инглиз теле укытучысы.** Children! Some Tatar sounds help us to learn English sounds. Look, listen and repeat, please.
**(2 нче слайд)**
Well done.
**Нәтиҗә.** Димәк, бу ике телдә дә булган авазлар безгә телебезне тирәнрәк өйрәнергә ярдәм итә.
Дәфтәрләрне ачып, бүгенге числоны язып куйыйк.
**Матур язу минуты:** бер юлга әле кабатлаган татар теле сүзләрен, икенче юлга инглиз теле сүзләрен язып куябыз.
Do the task, please. *(Укучылар яза.)*
**III. Уку мәсьәләсен кую**
**Инглиз теле укытучысы.** You are going to do interesting exercises today. We have guests, that's why do your best and show what you know about The Past Simple Tense. *(Прошедшее неопределённое время.)*
For your first task you need to remember some irregular verbs
Look at the following pictures. What do you see? Say and write 3 forms of the verbs. *(На экране появляются рисунки, изображающие действия: плавать, смотреть, взять, бежать, дать. Ученики смотрят на экран, определяют действие, записывают 3 формы неправильных глаголов, по очереди записывают на доске, затем идёт проверка по презентации.)* Swim-swam-swum, see-saw-seen, take-took-taken, run-ran-run, give-gave-given. **(3 – 12 нче слайдлар)**
**Татар теле укытучысы.** Укучылар, бу сүзләр сезгә нинди әкиятне хәтерләтә? *(Г. Тукайның «Су анасы» әкиятен.)* **(13 нче слайд)**
– Сезнең өстәлләрдә карточкалар бирелгән. 1 нче номерлы карточкаларны алабыз. Игътибар белән карагыз әле, анда нинди сүзләр төшеп калган? *(Фигыльләр.)* (**14 нче слайд)**
– Әкияткә нинди фигыльләр куябыз?

**(14 нче слайд)** Бу фигыльләр нинди заманда? *(Үткән заманда.)* Димәк, бүгенге дәресебезнең темасы нинди булыр? *(Үткән заман хикәя фигыль.)*

Дәресебезнең максатын билгелик әле. Димәк, бүген дәрестә нишләрбез? *(Үткән заман хикәя фигыльләрне кабатларбыз, фигыльләрне сөйләмдә кулланырга өйрәнербез; инглиз теле белән чагыштырырбыз.)* **(15 нче слайд)**

**Инглиз теле укытучысы.** What topic will we continue to talk about? *(Учитель также обращает внимание на доску, где написано правило.)* **(16 нчы слайд)** Делаем вывод. We will continue to talk about The Past Simple Tense.

It's important to learn the rules. I would like you to remember them.

*(Учитель сначала предлагает сравнить утвердительное и вопросительное (общий вопрос) предложении.)*

Look at the sentences. Compare them. What is the rule?

What do we add to the verb? **(17 – 18 нче слайдлар)**

What is the word order in interrogative sentences? **(19 – 20 нче слайдлар)**

Now look at the screen, write the past simple form of a verb. *(Выполнение упражнения на интерактивной доске. Учащиеся выбирают и подставляют правильную форму глагола в простом прошедшем времени.)* **(1 нче кушымта)**

**Ял минуты**

**Инглиз теле укытучысы.** Listen and sing a song «Oh, what a mystery!» *(Ученики смотрят на экран, слушают песню и повторяют с движениями.)* **(21 нче слайд)**

**IV. Алган белемнәрне ныгыту, мөстәкыйль куллану**

1. Үткән заман хикәя фигыль кушымчаларын кабатлау.

**Татар теле укытучысы.** Балалар, инглиз телендә үткән заман хикәя фигыльгә кушымчалар ялгана. Бу күренеш татар телендә дә шулай ук барлыкка килә. Татар телендә үткән заман хикәя фигыльнең ничә төре бар? Нинди кушымчалар ялгана?

**Көтелгән җавап.** Ике төре бар: билгеле һәм билгесез. *(Кагыйдәләрне искә төшерү.)* **(22 нче слайд)**

2. Парларда эш.

**Укытучы.** Сезнең каршыда 2 нче номер белән бирелгән карточкалар бар. Шушы карточкадан билгеле үткән заман һәм билгесез үткән заман фигыльләрен табып язасыз.

Тикшереп чыгу. **(23, 24 нче слайдлар)**

**Укытучы.** Балалар, әкият сезгә таныш. Хәзер мультфильм карап узабыз. **(25 нче слайд)**

**Инглиз теле укытучысы.** For the second exercise you should work in pairs with the cards – you need to put words in the right order in different types of sentences. Make up the sentences from these cards. *(После просмотра фильма учащиеся работают в парах, собирая предложения из слов и словосочетаний. Затем зачитывают их вслух. Класс слушает, отвечает на вопросы.)* **(Приложение 2)**

3. Барлык, юклык форманы кабатлау.

**Укытучы.** Балалар, ә хәзер сез инглиз телендәге бу фигыльләрне татар теленә тәрҗемә итеп язасыз.

– Нинди тәрҗемәләр барлыкка килде? *(Булды, йөгердем, чыктым, киендем, күрдем.)* Бу фигыльләр нинди формада? *( Барлыкта.)* Ә хәзер юклыкка куеп язабыз. *(Тикшереп чыгу.)* **(26 нчы слайд)**

**Нәтиҗә.** Димәк, фигыльләр барлыкта һәм юклыкта килә ала (определённая и неопределённая форма). Ә менә инглиз телендәге юклык форма татар телендә юклык форма буларак кулланыла.

– Ә бу әкиятнең авторы турында сез нәрсәләр беләсез? *(Г.Тукай – якташ язучыбыз, татар халкының бөек шагыйре.)* **(27 нче слайд)**

**Төркемнәрдә эш**

**Укытучы.** Һәр төркемгә әкиятнең бер сюжеты буенча рәсемнәр өләшәм. Каршыгызда әкиятнең тулы варианты бар. Сез шушы рәсемгә туры килгән өлешне табарга һәм шул өлештән фигыльләрне табып, заманнарын билгеләргә тиешсез. **(28 – 31 нче**

**слайдлар)**

**V. Рефлексия. Дәрескә йомгак ясау**

**Укытучы.** Дәрестә үзең өчен нинди нәтиҗә чыгардың? «Рефлексив экран»да үз эшчәнлегеңә туры килгән җөмләләрне сайлап алып дәвам ит.

- Хәзер мин беләм…
- Мин башкара алам…
- Миңа кызык булды…

**Инглиз теле укытучысы.** What have you learnt today? Complete the sentences **(28 нче слайд)**

Open please your diaries and write down your home tasks. Read the fairy tale and write down verbs in the Past Simple Tense.

My dear friends! Our lesson is over. Thank you very much for the lesson. Have a nice day! Stand up, please. Good-bye, my gear children!

**VI. Өй эше**

Г.Тукайның «Су анасы» әкиятенең 2 нче бүлегеннән үткән заман хикәя фигыльләрне табып язарга.

**Укытучы.** Дәресебезне инглиз телендә исәнләшүдән башладык, татар телендә саубуллашу белән тәмамлыйбыз.

**1 нче кушымта**

Put the verbs into the correct form (Past Simple)

1) Anna __________ (have) a great last summer.

have haved has had

2) My sister __________ (play) computer games yesterday.

plays played plaied

3) He __________ __________ (not / bring) an umbrella an hour ago.

didn't bring doesn't brought

4) __________ Jake __________ (buy) a car last month?

buy Did Does bought

5) Suzzy __________ (miss) the train two hours ago.

missd misses missed missing

6) The Smiths __________ __________ (not / travel) to London last year.

don't travelled didn't travel

7) Where __________ Julia and Matt __________ (eat) dinner?

ate eat did do

Answer key:

1) had
2) played
3) didn't bring
4) Did … buy
5) missed
6) didn't travel
7) did … eat

**2 нче кушымта**

1) He walk the summer day ? Did to a small village

P1 and P2: Did he walk to a small village the summer day ? -Yes, he did.

2) for a rest? you stop Did

P3 and P4: Did you stop for a rest? - Yes, I did.

3) he an awful woman Did see?

P5 and P6: Did he see an awful woman? - Yes, he did.

4) sit near the river? A woman Did

P7 and P8: Did a woman sit near the ri er? -Yes, she did.

5) a boy want to take Did the comb?

P 9 and P10: Did a boy want to take the comb? -Yes, he did.

6) Did the boy? Water Maid run after

P11 and P12: Did Water Maid run after the boy? Yes, she did.

7) put on a hat? Did a boy

P13 and P14: Did a boy put on a hat ? - No, he didn't.

8)with his friends? Was he

P15 and P16: Was he with his friends? -Yes, he was.

**Кулланылган әдәбият**

1. Шәкүрова М.М. Туган (татар теле). 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2020.

2. Тукай иленә сәяхәт – Путешествия в мир Тукая/ төз.-авт.: Т. Шакирова, Г. Хәйдәрова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013.

3. Быкова Н.И., Дули Д., Поспелова М.Д. и др. Английский язык. 4 класс. – М.: «Просвещение».

4. Спотлайт 4 класс, видео к учебнику.

5. englishvideoles.ru Sergey Chernishov.

7




# КИСӘКЧӘЛӘР

*(4 нче сыйныфта татар теле дәресе)*

**Гөлүзә ГЫЙМАДИЕВА,**

*Балык Бистәсе районы Яңа Арыш урта мәктәбенең I квалификация категорияле башлангыч сыйныфлар укытучысы*

**Максат:** сүз төркемнәре турындагы белемнәрне камилләштерү; кисәкчәләр турында төшенчә бирү, аларны аерып тану; кисәкчәләрне сөйләмдә дөрес куллану, җөмләдә дөрес язуга ирешү.

**Ирешеләчәк нәтиҗә (бурычлар)**

**Предмет күнекмәләре:**

– Кисәкчәләрнең төп билгеләрен әйтеп бирү; кисәкчәләрне кушымчадан аера белү.

**Метапредмет УУГ**

*Регулятив УУГ:*

**–** Уку мәсьәләсен кабул итү һәм саклау; гамәлләрне бәяләү, ясалган хаталар характерын исәпкә алып, эш-гамәлләргә төзәтмәләр кертү.

*Танып белү УУГ:*

**–** Уй-фикерне сөйләм формасында төзү; бирелгән критерийлар буенча чагыштыру һәм классификацияләү үткәрү; объект турында хикәяләү; укытучы ярдәмендә дәреснең максатын чыгару.

*Коммуникатив УУГ:*

**–** Кешеләрдә төрле фикерләр булу мөмкинлеген кабул итү; уртак эшчәнлектә гомуми чишелешкә килү; төрле сөйләм чаралары куллану.

*Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре (УУГ):*

– Уку материалына кызыксыну булдыру; үз уку эшчәнлегеңне бәяләү сәләте формалаштыру.

**Төп терминнар**: ярдәмче сүз, кисәкчәләр, аларның төркемчәләре.

**Ресурслар:** дәреслек: Татар теле, 4 нче сыйныф, 2 нче кисәк. И.Х.Мияссарова, К.Ф.Фәйзрахманова.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру өлеше**

Дәрестә уңай атмосфера тудыру.

**Укытучы.** Хәерле көн, укучылар! Мин дә сезне, белем дәрьясына чумып, андагы хәзинәне табарга чакырам.

**Матур язу күнегүләре**

Юл һәм баш **т, Т** хәрефләрен язу.

Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр. *(Мәкаль)*

**II. Белемнәрне актуальләштерү**

**Көтелгән нәтиҗә:** үтеләчәк темага нигезләнеп үткәннәрне кабатлау.

**Грамматик викторина**

1. Сөйләм нәрсәдән тора? *(Җөмләдән.)*
2. Җөмлә нәрсәдән тора? *(Сүзләрдән.)*
3. Предметны белдергән сүз нәрсә дип атала? *(Исем.)*
4. *Кайталар* сүзе нинди сүз төркеменә керә? *(Фигыль.)*
5. Нинди сүзләр дәрәҗәләрдә килә? *(Сыйфат.)*
6. Исемне алмаштырып килә торган сүзләр нинди сүзләр була? *(Алмашлык.)*
7. Исем, сыйфат, фигыль, сан, алмашлыкны нәрсә дип атыйбыз? *(Сүз төркемнәре.)*

– Укучылар, без сезнең белән нинди сүз төркемнәрен өйрәндек?

– Әйе, хәзер «Үз оясына» урнаштыр уенын уйнап алабыз. Моның өчен экрандагы сүзләрне бирелгән сүз төркемнәре астына урнаштырырга кирәк булыр. Башладык.

*усал, тә, яза, татлы, гына, барды, Идел, да, мин, кеше, алар, кенә*

**III. Проблемалы ситуация булдыру**

**Көтелгән нәтиҗә:** авырлыкларны ачыклау. (*Ни өчен шундый сорау килеп туды? Без әле нәрсәне белмибез?)* Дәреснең темасын ачыклау, дәреснең максатын төп сорау итеп билгеләү.

– Нинди сүзләр калды? Нигә калган сүзләрне беркая да кертә алмадыгыз? Ни өчен алар артык калды? *(Гына, ич.)*

– Бу сүзләргә сорау куеп карагыз әле?

– Аларның лексик мәгънәләре бармы? Димәк, телдә сорау куеп булмый торган, лексик мәгънә аңлатмый торган сүзләр дә була

икән. Алар ничек атала һәм ни өчен кирәк, бүген шуны ачыклап китәрбез.

**IV. Яңа белемнәрне ачу**

**Көтелгән нәтиҗә:** кисәкчәнең аерым сүзләрнең яки җөмләләрнең мәгънәләренә өстәмә төсмер бирүче ярдәмлек сүз төркеме икәнен искә төшерү. Төркемчәләре белән танышу.

**Укытучы.** Димәк, укучылар, сорау куеп булмый торган сүзләр дә бар икән. Татар телендә сорау куеп булмый торган сүз төркемнәре тагын бар әле. Ләкин без бүгенгә кисәкчәләрдә тукталып китәрбез. Кисәкчәләрне белү бик мөһим. Чөнки бик күпләр кисәкчәләрне язганда хата җибәрәләр. Я сүзгә куша торган кисәкчәләрне аерым язалар, яисә аерым языла торганнарны кушып куялар. Менә шундый хаталарны булдырмас өчен, әйдәгез, кисәкчәләрне карап үтик. Иң беренче чиратта шуны әйтергә кирәк: кисәкчәләр ярдәмче сүз төркеменә керәләр *(модаль сүз төркеме)*. Алар аерым сүзләрнең яки җөмләләрнең мәгънәләренә аерым төсмер бирәләр. Кисәкчәләрнең мәгънәви төркемчәләре бар. Ул – **көчәйткеч, чикләүче, сорау, раслау, үтенүне белдерүче, инкярны (юклыкны), билгесезлек** кисәкчәләре. Ә хәзер һәрберсен аерым карап үтик.

1. **Көчәйткеч кисәкчәләр:** а) ап-, зәп-, кып-, түм-, өр-, чем-. Алар сүзнең беренче иҗегенә туры киләләр һәм сызыкча аша язылалар. Мәсәлән: *ап-ак, зәп-зәңгәр, түм-түгәрәк, чем-кара.*

ә) иң, чалт, чатнама, дөм, нәкъ, шыр. Бу кисәкчәләр сүздә аерым языла. *(Иң яхшы, чалт аяз, дөм сукыр, шыр надан.)*

б) **да, дә, та, тә** кисәкчәләре үзләре ияреп килгән сүзгә көчәйтү төсмере өстиләр. *Бакчада чәчәкләр күп. Мин мәктәптә укыйм.* Беренче җөмләдә *мәктәптә* сүзе урын-вакыт килешендәге исем. Безнең авылда мәктәп **тә**, балалар бакчасы **да** бар. Икенче җөмләдә **тә** – кисәкчә. Ялгышмас өчен **белән, һәм** сүзен куеп карый алабыз.

2. **Чикләүче кисәкчәләр: гына/генә, кына/кенә кисәкчәләре үзләре ияреп килгән сүзгә чикләү төсмере өстиләр, ахырда киләләр һәм аерым язылалар** *(син генә, сак кына).*

3. **Сорау кисәкчәләре: -мы/-ме, -мыни/-мени. Бу кисәкчәләр сүз ахырында киләләр һәм кушылып язылалар.** Мәсәлән: *Ул кибеткә барамы? Аны белмәдемени?* Димәк, -**мы/ме, -мыни/-мени** кисәкчәләре сүзгә кушылып языла.

4. **Раслау кисәкчәләре: бит, ич, ла/лә, лабаса/ләбаса. Бу кисәкчәләр сүз яки җөмлә ахырында киләләр, аерым язылалар.** Мәсәлән: *килә лә, күрдем ләбаса* һ.б.

5. **Үтенүне белдерүче кисәкчәләр: -чы/-че, -сана/-сәнә. Сүз ахырында киләләр һәм кушылып язылалар** *(күрсәнә, карачы).*

6. **Инкярны, юклыкны белдерүче кисәкчәләр: а) һич, түгел. Бу кисәкчәләр инкяр итүне (кире кагуны), юклыкны белдерәләр. Һич** кисәкчәсе юклык алмашлыкларын ясаган очракта сүзгә кушылып языла. Мәсәлән: *һичкем, һичкайчан, һичнәрсә* һ.б. **Түгел** кисәкчәсе гел аерым языла. Мәсәлән: *мин түгел, синеке түгел.*

7. **Билгесезлек кисәкчәләре: әллә, -дыр/-дер, -тыр/-тер. *Әллә* кисәкчәсе һәрвакыт аерым языла. *-дыр/-дер, -тыр-/-тер*** кисәкчәләре сүзгә кушылып язылалар. Мәсәлән: *әллә нинди, киләдер, кайтадыр* һ.б.

2. **Җөмләләрне дөрес интонация белән укырга өйрәнү.**

**Көтелгән нәтиҗә:** җөмләләрне дөрес тавыш белән уку,

Бакчада чәчәкләр күп.

Бакча да миңа бик ошады.

**V. Телдән әйтеп карап беренчел ныгыту**

**Көтелгән нәтиҗә:** җөмләләрне дөрес тавыш белән уку; кисәкчәләрнең сүзләргә нинди мәгънә төсмере өстә-

гәнен ачыклау.

**1 нче бирем.** Уен: «Артык сүзне тап!»

Гөмбә, генә, гөрләвек, гөлҗимеш.
Китерә, күтәрә, көлдерә, кенә.
Та, саф, ак, тар.

**2 нче бирем.** Текстны укы. Калын хәрефләр белән бирелгән кисәкчәләр, үзләре белән янәшә килгән сүзләргә нинди мәгънә төсмере өстиләр?

«Кулына тотып таяк, килә**дер** теге кәкре аяк», – дип уйлаган Куян, чыннан да шулай булып чыккан.

Куян килүчегә сүз кушкан:

– Аю бабай, башкалардан артка калмыйсыңдыр, үзеңә койрык сайлыйсың**дыр**, шунда миңа да, нинди генә булса да, бер койрык алып кайта алмассыңмы икән? — дигән.

– Әгәр **дә** онытмасам, алып кайтырмын, авыр эш**мени** ул,— дигән Аю.

**3 нче бирем.** Кисәкчәләрне табыгыз, төркемнәрен билгеләгез.

Әбиләр дә авырый,
Бәбиләр дә авырый...
Салкын тисә аз гына,
Дару кирәк барсына.
Чирли хәтта китап та.
Ник көләсең?.. Чынлап та:
Бите төшә, ертыла —
Ул бит көн дә тотыла.
Тотам шуңа сак кына,
Авырдымы чак кына,
Чирен шундук күрәм мин,
Дәвасын да беләм мин. *(Х.Халиков)*

**4 нче бирем.** Кагыйдәләрне уку, истә калдыру.

**VI. Ныгыту**

**Көтелгән нәтиҗә:** җөмләләрне дөрес тавыш белән уку; кисәкчәләрне дөрес кулланып яза белү.

**1 нче бирем.** Нокталар урынына Кисәкчәләрне табып, шигырьне күчереп яз.

**Почмакта торам**

Әни почмакка
Бастыра мине,
Нигә икәнен
Беләсез инде!
Чыкмый тыным да,
Еламыйм хәтта.
Елау турында
Уйламыйм хәтта.
Торам төз генә,
Телләшми генә,
Сер бирми генә,
Сөйләшми генә.
Әзер мин монда
Көн дә торырга –
Өйрәнәм бит мин
Солдат булырга!
Солдат булырга –
Сакта торырга!

*(Роберт Миңнуллин)*

Кисәкчәләр: *да, дә, генә (урында), бит.*

**VII. Нәтиҗә һәм бәяләү. Рефлексия**

**Көтелгән нәтиҗә:**

– дәрестәге эшчәнлеккә объектив бәя бирә белү:

– кисәкчәләрне дөрес уку:

– кисәкчәләрне дөрес яза белү:

– алган белемнең куллану өлкәсен күзаллый белү.

– Бүгенге дәрестә сез нәрсәләр белдегез?

–Үзегез өчен нинди яңалык ачтыгыз?

– Җөмләдә кисәкчәләрнең дөрес язылышын ничек белә алабыз?

– Аны безгә ни өчен белергә кирәк?

Слайдта чыккан җөмләләрне тәмамларга кирәк.

– Мин белдем ... .
– Мин истә калдырдым ... .
– Мин эшли алдым ... .

Үз эшегезгә бәя куегыз.

**VIII. Өй эше**

35 нче күнегү.

«Минем әни» дигән темага кисәкчәләр кулланып, хикәя төзергә.




8

# СҮЗ ЯСАЛЫШЫ, ЯСАГЫЧ КУШЫМЧАЛАР ЯЛГАНУ ЫСУЛЫН КАБАТЛАУ

*(Рус мәктәбендәге татар балалары өчен 5 нче сыйныфта татар теле дәресе)*

**Рәсимә ИБРАЕВА,**

Арчадагы 2 нче урта мәктәпнең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:** сүз ясалу, кушымча ялгау ысулын искә төшерү; ясагыч кушымчалар белән ясалган сүзләрне аера белү; төрле сүз төркемнәре ясый торган кушымчалар белән яңа сүзләр ясау күнекмәләрен формалаштыру; янәшәдәгеләргә игътибарлылык, дусларга карата хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**

*Регулятив:* ясагыч кушымчалар белән ясалган сүзләрне таный, аера һәм куллана белү.

*Танып белүдә:* тексттан тиешле мәгълүматны табып билгели белү, текстлардагы образларны чагыштырып, дөрес нәтиҗә ясый белү.

*Коммуникатив:* әдәби телдә дөрес һәм образлы итеп сөйләү, үз фикерләрен төгәл итеп җиткерүләренә ирешү.

*Шәхескә кагылышлы:* дуслык хисе һәм дусларга карата хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Дәреснең тибы:** алган белем һәм күнекмәләрне ныгыту.

**Төп төшенчәләр:** исем, фигыль, сыйфат, сан, тамыр, ясалма, мәгънә, ясалыш.

**Предметара бәйләнеш:** әдәбият, рус теле.

**Эшне оештыру төрләре:** әңгәмә, биремнәрне аерым-аерым һәм төркемләп үтәү, текст белән эш, сәнгатьле уку.

**Җиһазлау:** сүз ясалышын күрсәткән, ясагыч кушымчалар язылган таблица, текстлар, терәк схема, үзбәя картасы.

**Дәрес барышы**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру.

**Укытучы.** Һәр дәресемә шатланып керәм,/ Укучыларымның хәлләрен беләм.

Хәерле көн, дусларым! Әйдәгез, дуслар белән бергә булуыбызга шатланып, матур теләк-омтылышлар белән дәресебезне башлап җибәрик.

**II. Белемнәрне актуальләштерү**

**Укытучы.** Укучылар, үзебезнең иң якын дусларыбыз турында сөйләшеп алыйк әле. Сез күбрәк дуслыкны кемнәр арасында нык дип уйлыйсыз? Фикерләрегезне үз тормышыгыздан мисаллар китереп җиткерә аласыз. *(Укучылар җавабын тыңлау.)*

**Укытучы.** Сезнең якыннарыгызга, бигрәк тә дүрт аяклы дусларыгызга карата булган җылы мөнәсәбәт миңа бик ошады. Бүгенге дәресебез нәрсә турында буласына инде төшенгәнсездер. Әйе, укучылар, без бүген дуслык турында сөйләшербез. Әгәр дәресебезне «Дуслык – зур байлык» дип атасак, каршы килмәссез дип уйлыйм. *Дус, дуслык, байлык* сүзләренең ясалышы хакында ни әйтерсез икән? *(Бер укучы такта янына чыга, ә башка укучылар әлеге биремнәрне урыннарда башкара.)* Дәфтәрләргә бүгенге числоны, теманы язабыз. Бирелгән сүзләрнең төзелешен тикшерәбез.

*Дуслык* – сүзнең нигезе – *дуслык*, *-лык* – сүз ясагыч кушымча, ясалма нигезле сүз, тамыры – *дус*.

*Байлык* – сүзнең нигезе – *байлык*, *-лык* – сүз ясагыч кушымча, ясалма нигезле сүз, тамыры – *бай*.

**Укытучы.** Укучылар, без бергәләп нинди зур теманы искә төшердек? *(Без татар теленең сүз төзелеше һәм сүз ясалышы турындагы белемнәребезне ныгыттык. Сүз төзелеше бүлеге сүзләрнең мәгънәле кисәкләрен өйрәнә.)* Әйдәгез, бергәләп бүгенге дәресебездә үзебез өчен максат куйыйк. Моның өчен тактадагы сүзләргә тагын бер кат карагыз.

Тамырга яки нигезгә сүз ясагыч кушымчалар өстәгәч, сүзнең лексик мәгънәсе үзгәрдеме? *(Әйе, үзгәрде, яңа лексик мәгънәле сүзләр барлыкка килде.)* Димәк, татар телендә яңа сүзләр нинди юллар белән ясала икән? *(Ясагыч кушымчалар ялганып.)* Дөрес, яңа сүзләрне кушымча ялгап ясап була. Бүген без шуны күрдек. Дәресебездә без тагын нәрсә турында сүз алып барырбыз икән?

**Көтелгән җавап.** Бүгенге дәрестә сүзләрнең ясалыш юлларын кабатларбыз.

**Укытучы.** Дөрес, бүгенге дәресебез сүзләрнең ясалыш ысулларына, ясагыч кушымча ялгау ысулына багышлана. Бергәләп формалаштырган максатыбызга ирешү өчен, без төрле күнегүләр башкарырбыз, текст өстендә эшләрбез, үзебез чыгарган кагыйдәләрне дөресләрбез.

**III. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Тукталышлар алымын кулланып, әкият белән танышу.

**Укытучы.** Мин сезгә бүген Галимҗан Гыйльмановның «Дуслык һәм шар» әкиятен алып килдем. Без аны кызыклы бер алым белән укырбыз. Мин укый башлыйм һәм иң кызык урынында туктыйм һәм сез үзегез теләгәнчә дәвам итеп карыйсыз.

«Бер йортта ике мәче баласы яшәгән. Баштарак бик тату торганнар алар. Дус булганнар. Уйнап-шаярып йөргән вакытларында мәче балаларының берсе һава тутырылган шар табып алган. Ул шар шулкадәр матур булган, мәче баласы хәтта үзенең дусты хакында да оныткан. Дустын үпкәләтермен дип тә уйламыйча, аның дәшүенә, чакыруына да карамыйча, табылдык шар белән уйнаган да уйнаган. Моны күреп, дусты чынлап та үпкәләгән, читкә китеп барган. Бераздан ул үзе дә яңа дус тапкан – күршедә генә шундый ук ялгыз мәче баласы дус эзләп йөри икән...» *(Укучыларга әкиятне үзләре теләгәнчә дәвам итеп карау мөмкинлеге бирелә.)*

**Укытучы.** Укучылар, ни өчен мәче баласы дустына үпкәләде инде? Яңа дус элекке дусны алыштыра алырмы?

Шар белән уйнап йөргән мәче баласы, башкалар алдында мактаныр өчен, шарын урамга алып чыккан. Әмма урамда шар тик тормаган, һаман өскә, күккә омтылган. Мәче баласы аны ничек тә ычкындырмаска, үзенеке генә итәргә тырышкан. Шар очып китәм дигәндә генә, йөгереп килеп, аны кочаклап ала икән. Шулай бер йөгереп килеп тотканда, ул үзе дә сизмәстән, ялгыш кына тырнакларын шарның

йомшак тәненә батырган. Шар шартлап киткән һәм теткәләнеп чәчелеп беткән. Мәче баласы урам уртасында япа-ялгызы утырып калган.

Шулай ямансулап утырганда аның исенә иске дусты килеп төшкән. Бу мәче баласы шул дустын эзләп киткән. Әмма элеккеге дустының икенче бер дусты бар икән инде. Шуңа күрәме – ул дуслыкны матур шарга алыштырган мәче баласын кире куып җибәрә… *(Укучыларга әкиятне үзләре теләгәнчә дәвам итеп карау мөмкинлеге бирелә.)*

**Укытучы.** Укучылар, нигә элеккеге дустын куып җибәрә соң мәче баласы? Дөрес эшләде дип уйлыйсызмы?

Шунда бу хәлләрне күзәтеп яткан олы мәче әйткән:

– Дуслар икәү генә түгел, өчәү дә, күбәү дә булырга мөмкин. Сез дә кабат дуслашыгыз. Моннан соң бервакытта да бер-берегезне рәнҗетмәгез. Дуслыкны бернинди уенчыкка да, матур шарларга да алыштырырга ярамый, шуны истән чыгармагыз, – дигән.

Өч дус әле һаман да бергә тату яшиләр, имеш. Хәзер инде алар зур үскәннәр, үзләре башкаларга акыл биреп йөриләр, ди.

**Укытучы.** Укучылар, олы мәче дусларга нинди акыллы киңәш бирде икән?

– Җавабыгыздан күренгәнчә, сез дусларыгызны рәнҗетмисез, алар белән юк-барга үпкәләшеп тә йөрмисездер? Әгәр үпкәләшкән булсагыз, дуслашу җаен табарсыз дип ышанам.

2. Текст ярдәмендә тамырга ясагыч кушымча ялгану ысулы турындагы белемнәрне гомумиләштерү.

**Укытучы.** Укучылар, тексттан ясагыч кушымча ялгану ысулы белән ясалган сүзләрне дәфтәргә язып алабыз.

**Ял минуты** *(туп белән)*.

**«Дустыңа бир»**

*(Сүзнең тамырын әйтеп туп бирү. Дөрес җавап биргән укучы тупны тамыр сүз әйтеп иптәшенә бирә.)*

**IV. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту**

**Укытучы.** А4 форматындагы битне урталайга ике кабат бөклибез. Уртадагы почмакны бөкләп ачабыз. Тексттан алынган ясалма сүзләрнең грамматик билгеләрен күрсәтәбез; уртага ясалышы ягыннан ысулны язабыз.

Таблицада бирелгән ясагыч кушымчаларны кулланып, яңа сүзләр төзеп язу. Мәгънәле кисәкләргә бүленешен күрсәтү.

**1 нче төркем:**

-даш/-дәш – партадаш, сердәш
-таш/-тәш – якташ, яшьтәш
-чы/-че – юлчы, эшче
-ма/ -мә – юллама ( путёвка), бүлмә (комната), җәймә ( простыня)
-лык/-лек – корылык, яшеллек
-ыш/-еш – узыш, йөреш
-ак/-әк – торак (йорт), бүләк
-гыч/-геч – кыргыч, элгеч
-кыч/-кеч – кыскыч, кискеч
-гак/-гәк – төргәк

**Нәтиҗә чыгару.** Исем дип язабыз. Исем ясагыч кушымчалар бирелгән.

**2 нче төркем**

-лы/-ле – баллы, ямьле
-сыз/-сез – тозсыз, күңелсез

-гы/-ге, -кы/-ке – язгы, көзге, кышкы, көлке
-чыл/-чел – кунакчыл, ярдәмчел
-чан/- чән – тормышчан, эшчән
-лык/ -лек – кышлык (печән), түбәлек (калай)
-ынкы/-енке – басынкы, җәенке
-нак/ -нәк – җыйнак, үрнәк
-ма/- мә – сайланма (әсәр), бәрмә (уен коралы)

**Нәтиҗә.** Сыйфат дип язабыз, сыйфат ясагыч кушымчалар бирелгән.

**3 нче төркем**

-ла/-лә – уйла, эшлә
-лан/-лән – куллан, төрлән
-лаш/-ләш – дуслаш, серләш
-ар/-әр/ -р – агар, яшәр
-а/-ә, -ай/-әй – аша, яшә, зурай, күбәй
-гар/-гәр – сугар, җилгәр.
-сын/- сен – буйсын, күзсен
-ылда/-елдә – мырылда, җемелдә

**Нәтиҗә.** Фигыль дип язабыз, фигыль ясагыч кушымчалар бирелгән.

**Төркемнәрдә эшләр тикшерелә. Нәтиҗәләр чыгарыла.**

**2 нче бирем**. Бирелгән сүзләрне ясалышы ягыннан нинди сүз төркеме икәнлеген аерып, шунда ук эшлибез. *(Һәр төркем үзенә туры килгәнен генә язып куя.)*

Исемнәр, сыйфатлар, фигыльләр

**Сүзләр**: әзерлә, җырчы, дуслык, оялчан, сана, моңлы, язгы**,** көрәк, хыяллану, якташ, кадерле, дәвала.

| **Исем** | **Сыйфат** | **Фигыль** |
|---|---|---|
| дуслык,<br>җырчы,<br>көрәк,<br>якташ | оялчан,<br>моңлы,<br>язгы,<br>кадерле | әзерлә,<br>сана,<br>дәвала,<br>хыяллану |

**V. Рефлексия**

**Укытучы.** Инде дәрестә үзебез чыгарган кагыйдәне һәркем эчтән генә исенә төшерсен. Укучылар, без күнегүләрдән соң ясаган нәтиҗәләр дөрес булганмы? Без дусларга карата нинди мөнәсәбәттә булырга тиешбез? Дуслык байлык була аламы? Дәресебез темага туры килдеме? Фикерләрегезне тыңлыйк әле. *(Укучылар җавабы.)*

**VI. Өй эше бирү**

**Укытучы.** Укучылар, һәрвакыттагыча, мин сезгә өч төрле өй эше тәкъдим итәм. Көндәлекләрегезгә язып куегыз.

1. Дәреслектән бирелгән күнегүне эшләргә.
2. Дуслык турында ясагыч кушымча ялганып ясалган сүзләр кергән биш мәкаль табып язарга.
3. Кышкы каникулдан алган тәэсирләреңне дустыңа хат итеп язарга.

**VII. Йомгаклау**

**Укытучы.** Инде дәрестә алган белгеләрегезне йомгаклап, гомумән, дәрес өчен белге куяр вакыт җитте. Ягез, кемнәр ничәле алыр икән? *(Укучыларның үзбәяләре тыңлана, кирәк булса, төзәтмәләр кертелә. Билгеләр көндәлекләргә куела.)* Бүгенге дәрес кемнәргә авыр тоелды? Ә кемнәр алдагы дәрестә тагын да тырышыбрак эшләргә сүз бирә?

**Укытучы**. Укучылар, дуслык – чыннан да, зур байлык ул. Янәшәңдә ышанычлы дуслар булганда, берни дә куркыныч түгел. Чын дуслар беркайчан да хыянәт итми. Дусларыгызны рәнҗетмәгез! Дуслыкның кадерен белегез.




# АЛМАЗ ГЫЙМАДИЕВНЫҢ «ИНТЕРНЕТТА – ALF» ХИКӘЯСЕ

*(5 нче сыйныфта татар әдәбияты дәресе)*

**Эльмира ГАЗИЗОВА,**

Арчадагы 6 нчы урта мәктәпнең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:** укучыларга Алмаз Гыймадиевнын тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү; «Интернетта – ALF» хикәясе белән таныштыру, әсәрдәге юморны аңлау; мөстәкыйль фикерләргә һәм үз фикерләрен төгәл итеп әйтә белергә өйрәтү; укучыларда белемле булырга омтылыш, теләк тәрбияләү.

**Бурыч:** укучыларның фикерләү активлыгын, сөйләм телен үстерү.

**Предметара бәйләнеш:** татар теле, информатика.

**Җиһазлау:** дәреслек (Хәсәнова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я. Татар әдәбияты. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларының 5 нче сыйныфында татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен.– Казан: Мәгариф – Вакыт, 2014. – 1 нче кисәк – 122–124 б.), компьютер, экран, проектор, презентация.

**Эш төрләре:** фронталь, индивидуаль, парлап, төркемнәрдә.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәрне өйрәнү.

**Дәрес барышы**

| Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге |
|---|---|
| **I. Оештыру өлеше, мотивация**<br>**Максат:** дәрестә укучылар белән уңай психологик халәт тудыру. | |
| Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру.<br>– Исәнмесез, укучылар. Кәефләрегез ничек? Әйдәгез әле, бер-беребезгә елмаеп, изге теләкләр телик һәм дәресебезне башлап җибәрик.<br>– Барыбызның да шат күңелле, бәхетле буласы килә. Шулай булырга тиеш тә. Мәшһүр Г.Тукай «Бәхетле бала» булуның менә нинди юл күрсәтә:<br>«Бәхетле шул баладыр, кайсы дәрсенә күңел бирсә,<br>Мөгаллимне олугъ күрсә, белергә кушканын белсә.<br>Сабакка калмаса соңга, борылмый барса уң-сулга,<br>Уенга салмаса ихлас – менә бәхте аның шунда».<br>– Ә сезнеңчә бәхетле бала нинди булырга тиеш икән соң? Әйдәгез, бәхетле балага хас сыйфатлар моделен төзик әле. | Укучылар бер-берсенә елмаялар, изге теләкләр телиләр.<br><br>– Бәхетле бала – тырыш, эшчән, акыллы, кызыксынучан, белемле, тыңлаучан һ.б. |
| **II. Мотивация (эшкә кызыксыну) тудыру**<br>**Максат:** белем алу, белемле булу турында фикер алышу. Әсәрне өйрәнергә әзерләү. | |

| | |
|---|---|
| Укытучы сораулар биреп, укучылар белән белем алу, белемле булу турында әңгәмә оештыра.<br>– Укучылар, белемле кеше дип нинди кешене атыйбыз?<br>– Белем алу ни өчен кирәк?<br>*(Белем алу турында мәкальләр тәкъдим итә, фикер алышу уткәрә.)*<br>Иле барның теле бар.<br>Күп укысаң, күп белерсең.<br>Белмәү гаеп түгел, белергә теләмәү гаеп.<br>Олы кешенең сүзен бүлдермә.<br>Белем бәхетле итә.<br>Белемле кеше югалмас.<br>Ашның бәрәкәте кунак белән.<br>Белемнең чиге юк.<br>Белемдә – көч.<br>Ана – шәфкать диңгезе.<br>Белем – нур, белмәү – хур.<br>Белем – бәхет ачкычы, дәрәҗәнең баскычы.<br>– Кайсы мәкальне үзегезгә девиз итеп алыр идегез? Аны язып куегыз. | Укучылар сорауларга җавап бирәләр, белем алу, белемле булу турында үз фикерләрен әйтәләр.<br><br>Укучылар мәкальләр белән танышалар, шулар арасыннан белем, белемле булу турында булганнарын сайлап әйтәләр һәм мәгънәләрен аңлаталар. |
| **III. Уку мәсьәләсен кую**<br>**Максат:** белгәннәр нигезендә ачыкланган белергә тиешле уку мәсьәләсен кую. | |
| 1. – Укучылар, бүгенге дәресебездә нәрсә турында сөйләшербез икән?<br>– Укучылар, сез компьютер артында утырырга, Интернет киңлекләрен иңләргә барыгыз да яратасызмы?<br>– Бүгенге дәресебезгә нинди максат куярбыз? | – Белем, белем алу, белемле булу турында сөйләшербез.<br>– Компьютер артында утырырга, Интернетка чыгарга яратабыз.<br><br>– Белемле булу турында әсәр укырбыз, эчтәлеген аңларбыз. |
| 2. «Интернет» сүзенә синквейн төзүне тәкъдим итү. Төркемнәрдә эшләтү.<br>**Синквейнны язу тәртибе:**<br>1 нче юл. Теманы ачыклаучы сүз, исем.<br>2 нче юл. Ике сыйфат.<br>3 нче юл. Өч фигыль.<br>4 нче юл. Теманың эчтәлеген ачучы фраза, җөмлә.<br>5 нче юл. Темага карата үз фикереңне бер сүз белән чагылдырган нәтиҗә, ассоциация. (Резюме.) | Синквейнны язу тәртибен искә төшерәләр. Сүзне язып куялар. |
| 3. Проблемалы сорау кую: Алмаз Гыймадиев «Интернетта – ALF» хикәясендә нәрсә әйтергә теләгән? | – Проблемалы сорауга җавап бирербез. |
| **IV. Уку мәсьәләсен чишү**<br>**Максат:** хикәяне сәнгатьле уку, эчтәлеген аңлау; авторның әйтергә теләгән фикерен ачыклау (проблемалы сорауга җавап бирү). | |

| | |
|---|---|
| – Бүгенге дәрестә Алмаз Гыймадиевның тормышы, иҗатына кыскача күзәтү ясарбыз, компьютер яратучы бер малай белән танышырбыз, «Интернетта – ALF» хикәясен укырбыз һәм фикер алышырбыз. | Укучылар фикерләрен әйтә. |
| 1. Алмаз Гыймадиевның тормыш юлы, иҗаты белән танышу. | Укытучыны, алдан әзерләнгән укучыны тыңлыйлар. |
| 2. Сүзлек өстендә эш.<br>*кача-поса* – яшеренеп, качып<br>*чәлпәрәмә китереп* – ватып-җимереп<br>*лапылдап* – аякларны авыр итеп басып<br>*җирән* – кызгылт-сары<br>*гарьлегеннән* – оятыннан | Аңлашылмаган сүзләрне аерып алалар, укыйлар. Сүзлек өстендә эш «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н һәм «Татарча-русча сүзлек» кулланып оештырыла. Сүзләрнең мәгънәләрен ачыклыйлар, аңлаталар, сүзтезмәләр, җөмләләр төзиләр. |
| 3. Күзләрне ял иттерү:<br>– Күзләрнең горизонталь хәрәкәте: уңга-сулга.<br>– Күзләрнең вертикаль хәрәкәте: өскә-аска.<br>– Күз карашы белән сәгать теле буенча һәм капма-каршы юнәлештә хәрәкәтләр ясау.<br>– Күзләрне еш кына ачыгыз һәм йомыгыз. | Укучылар укытучы әйтеп торган биремнәрне үтиләр, шулай итеп күзләрен ял иттерәләр. |
| 4. Алмаз Гыймадиевның «Интернетта – ALF» хикәясен сәнгатьле уку. | Укучылар әсәрне сәнгатьле укып чыгалар, әсәр эчтәлеген аңлыйлар. |
| 5. Эчтәлеген аңлауларын ачыклау өчен, сорауларга җавап бирү.<br>– Әлферитнең компьютер белән мавыгуына әнисе ничек карый?<br>– Малай яшьтәшләре белән кайда әңгәмә кора?<br>– Ул кем белән таныша?<br>– «Ромашка» кем булып чыга? Ул ни өчен җир тишегенә керердәй булган?<br>– Әлферит нәрсәне аңлый?<br>**Укытучы.** Җитди нигезле яратып көлү, «көлү битлеге артында хуплау» **юмор** дип атала.<br>– Хикәядә нәрсәдән яки кемнән көлү күренә?<br>– Әсәрнең юморы нидән гыйбарәт?<br>– Сез Интернетта аралашасызмы?<br>– Кемнәр белән аралашасыз? | Укучылар сорауларга җавап бирәләр, әсәрнең эчтәлеген аңлауларын күрсәтәләр. Интернетта аралашуга үз фикерләрен белдерәләр. |

| | |
|---|---|
| 6. Хаталарны төзәтү.<br>**ALF.** Привит рамашкы нихәль мин сине сагнып беттем.<br>**Ромашка.** Альф, минем хәлләр әйбәт. Сагынган кеше дустын кунакка чакыра ул.<br>**ALF.** Уау, әйдә, безгә кунакка киль.<br>**Ромашка.** Бүген үкме?<br>**ALF.** Канишны.<br>**Ромашка.** Әти-әниең ни дияр?<br>**ALF.** Алар дачада. | Укучылар, төркемнәрдә эшләп, әсәрдә бирелгән Альфред сөйләмендәге хаталарны төзәтәләр. |
| 7. Интернет-сүзлек белән танышу.<br>– Сез Интернетта барыгыз да аралашасыз. Ә терминнарны беләсезме?<br>*Аватар* – компьютер кулланучы үз йөзе итеп куя торган фотосурәт яки рәсем.<br>*Аккаунт* – сайтка керү өчен кулланыла торган шәхси мәгълүмат тупланган хисап язмасы.<br>*Блог* – вакыйгалар интернет-журналы, интернет-көндәлек, онлайн-көндәлек.<br>*Блогер* – блог алып баручы.<br>*Гифка* – анимацион рәсем.<br>*Онлайн* – хәзерге вакытта челтәрдә булу.<br>*Офлайн* – хәзерге вакытта челтәрдә булмау.<br>*Смайл* – компьютер кулланучының кәефен белдерә торган төрле тыныш билгеләренең җыелмасы.<br>*Спам* – реклама характерындагы электрон хат яки хәбәр, чүп.<br>*Чат* – кулланучыларның онлайн режимында язышуы. | Әсәрдә очраган терминнар турында фикер алышалар һәм интернет-сүзлек буенча парлап эшлиләр. Сүзләрнең мәгънәләрен ачыклыйлар, аңлаталар, сүзтезмәләр, җөмләләр төзиләр. |
| **V. Рефлексия. Нәтиҗә һәм бәяләү**<br>**Максат:** дәрестә эшләгән эшләргә нәтиҗә ясау. | |
| 1. Проблемалы сораугa җавап бирү. | Төркемнәрдә фикер алышып, проблемалы сораугa җавап бирәләр. |
| 2. Модельне тулыландыру<br>– Әсәрне укыганнан соң, «Бәхетле бала» моделенә тагын нинди сыйфат өстәр идегез? | «Грамоталы» сыйфатын өстәп куялар. |
| 3. «Интернет» сүзенә төркемнәрдә төзегән синквейн белән танышу. | Төзегән синквейннарын укып күрсәтәләр. Мәсәлән,<br>1. Интернет.<br>2. Акыллы, куркыныч.<br>3. Булыша, аралаштыра, оялта.<br>4. Белү – нур, белмәү – хур.<br>5. Челтәр. |

| | |
|---|---|
| 4. – Бүгенге дәресебездә нинди уку максатын чиштек?Ниләр белдек? Ниләр эшләдек? | – Бүгенге дәрестә белем алу, белемле булу турында сөйләштек, Алмаз Гыймадиевның тормышы, иҗатына кыскача күзәтү ясадык, компьютер яратучы Альфред исемле малай белән таныштык, «Интернетта–ALF» хикәясен укыдык, яңа сүзләр белдек, хикәя буенча фикер алыштык, әсәрнең юморын билгеләдек. |
| **5. Бәяләү. Үзбәя үткәрелә. Укучыларга билгеләр куела.** | Укучылар үзбәя үткәрәләр. Үзбәя өчен критерийлар:<br>а) «Дәрестә нинди уку максатын чиштек? Ничек эшләдек?Ниләр белдек?» сорауларына үз фикерен тулы, төгәл, аңлаешлы итеп әйтеп бирә алса – «5»ле;<br>ә) куелган сорауларга җавап тулы булмаса – «4»ле;<br>б) «Дәрестә нинди уку максатын чиштек? Ничек эшләдек? Ниләр белдек?» дигән сорауларга укытучы яисә иптәше ярдәме белән генә сөйләп бирсә – «3»ле;<br>в) укытучы яисә иптәше ярдәме белән дә сөйләп бирә алмаса – «2»ле. |
| **VI. Өй эше бирү**<br>**Максат:** укучыларга өй эшен башкару буенча күрсәтмәләр бирү. | |
| 1. «Белем – нур, белмәү – хур» мәкаленә туры килгән вакыйга турында сөйләргә.<br>2. Алмаз Гыймадиевның «Телефонлы кәҗә» хикәясен укырга. *(Буктрейлер ярдәмендә китапны алып укырга тәкъдим итү.)*<br>3. Интернет-сүзлектә танышкан сүзләрне кулланып, кечкенә хикәя язарга. | Өй эше буенча сораулар бирәләр. |
| **Нәтиҗә:** Г.Тукайның тагын бер «Эшкә өндәү» дигән гаҗәп тәрбияви шигыренә мөрәҗәгать итеп, менә мондый киңәш әйтәсе килә:<br>«Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә,<br>Аһ! Оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә». | |

10



# ҺАДИ ТАКТАШНЫҢ «МОКАМАЙ» ШИГЫРЕ

*(6 нчы сыйныфта татар әдәбияты дәресе)*

**Зилә ЗИННӘТОВА,**

*Казандагы 47 нче урта мәктәпнең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Максат:** танылган шагыйрь Һади Такташның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру. «Мокамай» шигырен анализлау; укучыларның тыңлап аңлау, логик фикерләү сәләтләрен, диалогик сөйләм, бүгенге көн күзлегеннән бәя бирү күнекмәләрен үстерү. Лирик геройны әсәрдән табу; Һ.Такташ шигъриятендәге матурлыкны күрә белергә өйрәтү. Чын дуслыкның кадерле сыйфат икәненә төшендерү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Метапредмет:* һәр кеше тормышында хатирәләр булуы, аларның яхшы яки начар булуының кешенең үзеннән күп торуы турында аңлау.

*Предмет:* поэма турында теоретик төшенчә белән танышу, «Мокамай» поэмасын уку, аңлау.

*Шәхескә кагылышлы:* чын дуслык кадере, ялгыш адым ясамаска кирәклек турында аңлау.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәр ачу, әсәргә анализ ясау, белем-күнекмәләрне ныгыту.

**Метод, алымнар:** әңгәмә, әсәргә анализ ясау, сәнгатьле сөйләм өстендә эш, сүзлек өстендә эш.

**Материал:** дәреслек (Мотыйгуллина Ә.Р., Ханнанов Р.Г., Гыйззәтуллина Э.Х. Татар әдәбияты 6 нчы сыйныф, 2 нче кисәк).

**Җиһазлау:** мультимедиа проекторы, экран (такта), слайдлар:Һ.Такташ портреты, Һ.Такташ китаплары.

**Дәрес барышы**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру**

**1.** Дәресне оештыру. Дәресне башлау, психологик уңай халәт тудыру.

**Укытучы.** Исәнмесез! Кәефләрегез ничек? Барыбызга да хәерле көннәр, уңышлар теләп, дәресебезне башлыйк.

**2.** Актуальләштерү.

–Һ.Такташның тормышы, балачагы турында алдагы дәрестә үткәннәрне искә төшерү.

– Өй эшен тикшерү: поэмадан өзекне сәнгатьле уку.

– Уку мәсьәләсен кую.

– Бүгенге дәреснең темасы – Һади Такташның «Мокамай» әсәре.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

1. Сүзлек белән эш.

– Сүзлектән чыгып, эчтәлек турында фикер йөртү – нәрсәләр аңларга була?

шаулау – шуметь (деревья)
ахры – наверное, по-видимому
усак – осина
имән – дуб
хыял – мечта
яфрак ярырлар – будут распускать листья
андый – такой, такие
андагыдай – как там
зурлар кебек – *здесь*: как взрослые
кыен (кыенлык) күрү – испытывать трудности, переносить невзгоды
шаяру – шалость, озорство, шутка
кәсеп – *здесь:* привычка
һәлакәт – гибель, беда
бурчым (бурычым) – свой долг
кан – кровь
каен башларына үрмәләп – карабкаясь на берёзы
бергәләп – вместе
дөнья белән танышу – знакомство с миром
югарыга табан – наверх

менәлмәдең (менә алмадың) – не смог подняться

йолу (юкка чыгару) – уничтожить

үткәннәрем – моё прошлое

күләгә – тень, отражение

хаклы идең – имел право

чабаталар үрдек – плели лапти

булдыксызлык – неспособность, бездарность

адаштың – сбился с пути

2. Мокамайның кем икәнлеген аңлату.

**Укытучы.** Мокамай – кушамат. Үз исеме – Мөхәммәтҗан. Ул Сыркыды авылының Бәкер исемле иң ярлы бер кешесенең баласы иде. Такташның балачак дусты. *(Һ.Такташ искәрмәсе.)*

3. Әсәрнең язылу тарихы.

**Укытучы.** Һ.Такташ кечкенәдән шаян холыклы, җор сүзле булып үсә. Ул һәр вакыйгага үзенчә такмак-шигырь чыгара торган була. Аның балачак дусты Мокамай-Мөхәммәтҗан күкәй урлап тотылгач, кечкенә Һадиулла мондый җыр чыгара:

Дыр-дыр, дырабан,
Мокамай күкәй урлаган;
Әйшә тәтәй тоткан,
Каравылын кычкырткан!

Еллар уза, Һади Такташ зур шагыйрь була. Мокамай да Мөхәммәтҗан булып үсеп җитә. Шулчак авылда берәүләрнең арба тәгәрмәче югала. Тәгәрмәчне Мокамайга сылтыйлар. Мөхәммәтҗанны, каты кыйнап, караңгы базга ябып, ач тоталар. Ул бу кимсетүләргә, бу гарьлеккә түзә алмыйча, үз-үзенә кул сала.

Һади Такташ бу фаҗигане бик авыр кичерә һәм «Мокамай» әсәрен яза. Язучы бу әсәрен сәхнәдән укыганда, халык үксеп елый, бәгырьләре өзгәләнүдән кешеләр: «Һади абый, тукта, җитте!» – дип ялвара торган булалар. *(Һ.Такташ альбомы. – 183 б.)*

4. «Мокамай» поэмасын аудиоязмада тыңлау. *(Әзһәр Шакиров укый.)*

**Укытучы.** Балалар, сез бу поэманы ничек аңладыгыз икән? Сорауларга җавап биреп карыйк әле. Сүз нәрсә турында бара? *(Мокамай турында, аның язмышы турында.)* Мокамай язмышы турында гынамы? *(Әсәр үзәгендә ике герой: Һ.Такташ һәм Мокамай тора.)* Әсәр нинди жанрга карый? *(Бу әсәр – поэма.)*

5. Теоретик төшенчәне укырга.

*Поэма – сюжетлы, зур күләмле лиро-эпик әсәр. Поэма жанры вакыйгалар һәм хисләрнең шигъри хикәяләвенә нигезләнә; халык, ил тормышындагы хәлләрне тасвирлый.*

**Укытучы.** Ни өчен әлеге әсәрнең поэма булуын аңлатыгыз.

6. Бөтен әсәр белән өлешләп танышып чыгу.

1) Әсәрнең кереш өлешен уку.

**Укытучы.** Әсәр кем исеменнән сөйләнә? *(Лирик герой – автор үзе.)*

«Лирик герой» төшенчәсен аңлату.

*Лирик герой – әсәрдә, шагыйрьнең хисләреннән тыш, күпчелек кешеләргә хас уй-кичерешләрне гәүдәләндерә торган образ.*

**Укытучы.** Поэма «Белмим...» дип башланып китә. Лирик герой нәрсәне белми соң? Бу сорауга җавапны әсәр азагында табарбыз. Без укыган бүлектә сүз нәрсә турында бара? *(Шагыйрьнең туган ягы, табигате турында.)* Автор

аны ничек тасвирлый? *(Лирик герой табигатьне бик матур итеп тасвирлый, урманнарда – ап-ак каеннар, камыш сабаклары искиткеч шаулый, алар герой күңелендә мәңге онытылмаячак)* Бу чынлап та шулаймы соң? *(Һәркемнең туган ягы үзенә якын һәм кадерле. Бу өлештә лирик геройның туган ягына мәхәббәте турында сөйләнелә.)* Нинди хисләр бирелә? *(Соклану, ярату, сагыну хисләре.)*

2) Әсәр укуны дәвам иттерү.

**Укытучы.** Әсәрнең бу өлешендә нәрсә турында сөйләнә? *(Геройларның балачагы турында.)* Әсәрдәге икенче герой кем? Аның портретын автор ничек сурәтли? Шул юлларны табып укыгыз. (*Икенче героебыз – Мокамай. Ул – кара чәчле, коңгырт кара күзле. Мокамай – лирик геройның дусты. Менә аны яратып, автор болай ди: «Кәкре аяклы дустым, җанкисәгем, Ул, Мокамай бәгърем, син идең».)* Алар нинди? *(Эчкерсезләр, гөнаһсызлар, беркатлылар.)* Дусты Мокамай белән авторның нинди уртак сыйфатлары бар? *(Икесе дә шук, наян, шул тик тормаулары аркасында шактый гына кыйналганнар. Аларның һәрнәрсәгә исе китә. «Бернәрсә дә бездән качмый иде, Бар нәрсәгә кулыбыз җитә иде...» – ди.)* Бу өлештә нинди хисләр чагылдырыла*? (Балачакны сагыну хисе, шатлану, куану, ярату, дуслык хисләре.)*

3) Әсәр укуны дәвам иттерү.

**Укытучы.** Нәрсә турында сөйләнә? *(Ике баланың капма-каршы язмышы сурәтләнә.)* Нинди хисләр? *(Борчылу хисе.)*

4) Әсәр укуны дәвам иттерү.

**Укытучы.** Бу өлештә сүз нәрсә турында бара? *(Автор тагын әкияттәге балачакка әйләнеп кайта. Балачактагы шаярулар «кәсепкә» әйләнү, тормышның һәлакәт белән тәмамлануы күрсәтелә.)* Ахыргы юлларны укып китик әле.

*Кем уйлаган, шушы шаярулар*
*Синдә кәсеп булып калыр дип,*
*Уйнап башланган эш тормышыңны*
*Һәлакәткә алып барыр дип...*

Бу юллар белән автор ни әйтергә теләгән? *(«Урлау кебек кәсеп – начар гадәт», – ди.)* Шагыйрь дустының эшләвенә ышанамы соң? (*«Кем уйлаган», – ди, икеләнә.)* Нинди хис? *(Икеләнү хисе.)*

5) Алдагы өлешне уку**.**

**Укытучы.** Бу өлештә сүз нәрсә турында бара? Авторның дустына мөнәсәбәте ничек бирелә? *(Шагыйрь дустын гаепли.)* – Нәрсәдә гаепли? *(Үз-үзеңә кул салу ул – зур гөнаһ. «Син алай эшләргә тиеш түгел идең», – ди.)*

– Әгәр чын карак булса, Мокамай шулай хурланыр, үз-үзенә кул салыр идеме икән? Шагыйрь аны якыннан белмәсә, аны яклар иде микән? Начар кешене яратып буламы? *(Юк. Шагыйрь аны акларга тырыша.)* Нигә аклый? *(Чөнки аның тормышы авыр әкият, тормыш баткагы, ачлык тырнагы. Алай гына да түгел, ул яшәргә тиеш, чөнки ул яхшы күңелле, тырыш, уңган.)* Лирик геройның Мокамайга мөнәсәбәте ничек? *(Автор Мокамайга җылы мөнәсәбәттә: ул аны гаепләми, тормышның*

*авырлыгы, ачлык сине шушы хәлгә төшерде, ди. «Син адаштың, ләкин син яхшы идең... Тормыш авырлыгын бергәләп җиңеп чыгарга иде», – ди. Ул Мөхәммәтҗанны гаепләми, киресенчә, аны акларга тырыша.)* Нинди хисләр бирелә? (*Үкенү, борчылу хисе.)*

6) Соңгы өлешне уку.

**Укытучы.** Мокамай язмышында кем гаепле соң? Нигә ул мондый фаҗигагә юлыкты? Күз алдына китерегез: ярлылыкның соңгы чигенә җиткән, ачлыктан интеккән үсмергә авыл халкы ярдәм итәсе урынга, аны җыенда кыйнап, идән астына ябып куя. *(Кешеләр битараф. Яшүсмер язмышы аларны борчымый.)* Ә бүгенге көндә ничек? Битарафмы без? *(Укучыларның җаваплары тыңланыла.)* Бу әсәре белән шагыйрь нәрсә әйтергә тели? *(Тормышта кеше ялгыз булырга тиеш түгел!)* Ни өчен әсәр көчле тәэсир итә? Ул нинди формада язылган? (*Хат формасында. Мокамай белән хат аша сөйләшү.)*

**III. Белемнәрне ныгыту. Модельләштерү**

**Укытучы.** Әйе, автор Мокамайның уңай якларын да, кире якларын да сурәтләгән. Димәк, автор Мокамайны сурәтләгәндә нинди алымнан файдаланган? *(Каршылык алымыннан.)*

– Мокамайның үлеме лирик геройда нинди хис тудыра? *(Үкенеч хисе.)*

– Дустының хатасын ул ничек атый? *(Адашу.)*

– Икенче өлештә чагыштыру, каршылык алымнарын таптык. Тагын бер алымны эзлибез. *(Кабатлау алымы бар. «Әкияттәге ике бала кебек» – бу сүзләрне автор дүрт мәртәбә кабатлый.)*

– Шушы сүзләрне кат-кат кабатлап, шагыйрь нәрсә әйтергә тели? *(Дус булулары турында.)*

– Бу өлештә тагы бер кабатлау бар. Нәрсәгә ант итә шагыйрь? Шул юлларны табып укыйбыз.

1. Мин ант итәм һичбер вакытта да 2. Юк, Мокамай, һичбер вакытта
Сине усал итеп сөйләмәм…
Сине карак итеп сөйләмәм…

**Укытучы.** Нәтиҗә ясыйбыз. Шушы сүзләр аша автор нинди хисне күрсәтергә тели? *Шаулау* сүзе нинди хисне белдерә? *(Борчылу хисен; шаулый-борчыла.)* Димәк, бу шигырен шагыйрь ни өчен яза? *(Аның карак дигән исемен бетерү өчен.)* Дустының үлеме күпме генә авыр булмасын, шагыйрьне дусты турында начар сүз яшәве борчый. Шуңа күрә ул кат-кат кабатлый, сине карак итеп сөйләмәм, ди. Дус дустына тугрылыклы булып кала: ул балачакта Мокамайны үзеннән өстен итеп тасвирлый. Авторның Мокамайга яхшы карашын күрсәтү өчен шагыйрь нинди тел-сурәтләү чараларын куллана? Чагыштыруларны язып алабыз. Әсәрдә чагыштырулар да кулланылган. (*Ак каенга асылып менгән кебек, әкияттәге ике малай кебек, чабатаңдай матур үрмәдең, май аедай.)*

**Укытучы.** Шагыйрь фразеологизмнардан да оста файдаланган. Фразеологизмнарны язабыз. (*Югарыга табан юл алдым – тормышта үзеңне табу;*

*исебез китә иде – кызыксыну; тал чыбыгы ашадык – кыйналу (терпели розги), йолу синең яманатыңны – үзгәртү, канлы пычак белән чикләдең – үлем; җәфа чигү – страдать; яманат – дурная слава; ачлык тырнагы – голод; тормыш баткагы – хаос, беспорядок, неразбериха.)*

Әсәрдә сынландырулар да бар. Сынландыруларны язып алабыз. *(Имәннәр озатып барырлар, шаярулар кәсеп булып калыр дип, әкиятнең соңгы битләре.)*

Димәк, тел-сурәтләү чараларыннан уңышлы файдалану лирик шагыйрьнең эмоциональлеген арттыра, укучыга тәэсир итү көчен күрсәтә.

Укучылар, әсәр белән таныштык, анализладык. Хәзер геройлар турында сөйләшик әле. Аларга нинди сыйфатлар хас икән?

1 нче рәтләр – лирик геройга, 2 нче рәтләр Мокамай образына бәяләмә бирә. Укыйбыз. Нәрсә яздык?

| **Лирик герой** | **Мокамай** |
|---|---|
| Шаян, тиктормас, тормышның матурлыгын күрә белә, авырлыклар алдында куркып калмый, ихтыяр көче зур. | Шаян, тиктормас, хезмәт сөя, нинди эшкә тотынса да, аны оста башкара, тик үзалдында торган проблемаларны хәл итә алмый. |

**Укытучы.** Димәк, тормышта төрле авырлыклар килеп чыгарга мөмкин, аларны җиңәргә кешедә зур ихтыяр көче булырга тиеш. Моңа ирешү өчен нишләргә кирәк соң?

**Нәтиҗә.** Кече яшьтән үк үзеңә-үзең ышанырга кирәк, төрле авырлыклар алдында сыгылып төшмичә, тыныч күңел белән проблемаларны чишә белергә өйрәнү бик мөһим. Димәк, үзеңдә ихтыяр көче булдырырга кирәк. Шигырьдәге Мокамайга менә шул сыйфат җитеп бетмәү сәбәпле, бик иртә кара җир астына керә, яшь гомере өзелә. Юкса алар икесе дә бер үк җәмгыятьтә яшәгән кешеләр бит. Тик юллары ике якка аерыла: берсе гел алга барып, зур шәхескә әйләнә, икенчесе кара гүргә керә. Мокамайның аянычлы язмышы мисалында шагыйрь бала вакыттан ук үзеңне батыр, кыю, тәвәккәл итеп тәрбияләргә куша.

**IV. Рефлексив бәяләү**

1. Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме? Һ.Такташның балачагы ничек үткән? Бу турыда белү поэманы аңларга ярдәм итәме? Поэма нәрсә ул? «Мокамай» поэмасы турында нәрсәләр исегездә калды?
2. Дәрескә гомуми бәя. Укучыларга билге кую.

**V. Өй эше**

1. Поэмадан ошаган өзекне ятларга.
2. Поэманың ошаган өлешен сәнгатьле укырга өйрәнергә.
3. Сезнең якын дустыгыз башка шәһәрдә яки авылда яши, ди. Аңа хат языгыз.

11



# «АЛМАШЛЫКЛАР» ТЕМАСЫН ГОМУМИЛӘШТЕРЕП КАБАТЛАУ

*(Татар теле. 6 нчы сыйныф. Татар төркеме)*

**Римма БИККИНИНА,**

Казандагы 189 нчы күп профильле «Заман» гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:**
*Фәнни:* мөстәкыйль сүз төркеме буларак, алмашлыкны җөмләдә дөрес билгели алу; алмашлык төркемчәләрен дөрес куллану.
*Коммуникатив:* алмашлыклар турындагы белемнәрне ныгыту; төркемнәрдә эшли белү күнекмәләрен формалаштыру.
*Тәрбияви:* туган телгә, милли мәдәниятебез, гореф-гадәтләребезгә ихтирам тәрбияләү.
**Көтелгән нәтиҗәләр**
*Предмет:* мөстәкыйль сүз төркемнәре буларак, алмашлык турында белемнәрне ныгыту; җөмләдә алмашлыкларны аера алырга өйрәтү.
*Шәхескә кагылышлы:* сөйләмдә алмашлыкларны кулланып, укучылар сөйләмендә кабатлаулар булдырмау.
**Метапредмет нәтиҗәләре**
*Коммуникатив УУГ***:** үз фикереңне әйтә һәм дәлилле белү; иптәшеңә ярдәм итү; башкаларның фикерен тыңлау.
*Регулятив УУГ:* максат куя, үз эшеңне планлаштыра белү.
*Танып белү УУГ:* тексттан кирәкле мәгълүматны таба, куллана һәм нәтиҗә ясый белү.
**Дәрес тибы:** кабатлау-йомгаклау**.**
**Җиһазлау**: техник чаралар: компьютер, интерактив такта.
**Метод һәм алымнар:** аңлату, мультимедиадан файдаланып, төрле биремнәр үтәү, белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру.
**Дәрес барышы**
**I. Оештыру өлеше. Мотивлаштыру**
**II. Актуальләштерү**
**Укытучы.** Хәерле көн, укучылар!Бүген **мин,** эшне башлап, **сезгә** хәерле көн телим һәм, дәресебезнең девизы итеп, шагыйрь Равил Фәйзуллин иҗатыннан

**Без** күбрәк **«Без!»** дип әйтсәк,
Җирдә бердәмлек артыр!

дигән шигъри юллар укырга тәкдим итәм. **(1 нче слайд)**
Чыннан да, укучылар, халык мәкалендәге кебек:

Аерылганны – аю, бүленгәнне бүре
Ашар дигән **безнең** әбиләр.
Бердәм булып, тату яшик, дуслар,
Ашамасын **безне** «бүреләр».
Бердәм булыйк, дуслар, кайгыларда,
Шатлыкларда бергә кайнашыйк.
Нинди генә хәлдә калсак та **без,**
Дуслар булып калыйк, аңлашыйк.
Төрле милләт халкы булсак та **без,**
Илебезгә телик тынычлык.
Тормышыбыз рәхәт, өстәлләр мул,
Яшик, дуслар, күрми кыенлык.
Диннәр төрле, ләкин теләкләр бер,
**Без** тынычлык кына телибез.
Һәр туар таң бәхет алып килсен,
Чәчәк атсын туган илебез.

*(Рафилә ФӘТТАХОВА)*

**(2 – 3 нче слайдлар)**
**Укытучы.** Әлеге шигырьнең асылында нәрсә ята, дип уйлыйсыз, укучылар? *(Дуслык, татулык төшенчәсе.)*
**Укытучы.** Бик дөрес. Без һәрвакыт бер-беребезнең гореф-гадәтләрен, йолаларын хөрмәт итеп, татулыкта, дуслыкта яшәргә тиеш. Кайсы гына милләт вәкиле булсак та, һәр халыкның йолаларын, бәйрәмнәрен белеп, санлап, милли-мәдәни элемтәдә торабыз. Бары тик бердәм булганда гына безнең мәдәниятебез, иң беренче чиратта, туган телебез яшәвен дәвам итәчәк. Дәрес башында мин терәк сүзләрне аерым интонация, басым белән әйтергә тырыштым. Әгәр сез игътибар иткән булсагыз, бу терәк

сүзләрне сизгәнсездер дип уйлыйм. Ә хәзер узган дәрестә бирелгән биремне карыйк әле. Текстны күчереп язарга һәм калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын ачыкларга кирәк иде. *(Өйгә бирелгән бирем: 82 нче биттә 175 нче күнегү. Өй эше тикшерелә. Җаваплар тыңланыла.)*

**III. Уку мәсьәләсен кую**

**Укытучы.** Укучылар, безнең бүгенге дәресебез гадәти түгел. Без сезнең белән морфология дөньясына сәяхәткә чыгабыз. Хәзер дәфтәрләрегезне ачып, бүгенге числоны язып куйыйк. *(Дәфтәрләрдә эш.)*

– Исем, сыйфат, сан, рәвеш, турында күп нәрсәләр белдек. Бүген дәрестә морфология дөньясының кайсы почмагына барачагыбызны шушы мәкальләр ярдәмендә белербез. **(4 нче слайд)**

1. Акыллы сүзен **мин** дип башламый.
2. **Кем** эшләми – **шул** ашамый.
3. **Кайда** татулык – **шунда** тынычлык.
4. **Кемнең** сүзе хак – **шуның** йөзе пакь.

*(Укучылар аерым карточкалар нигезендә мәкальләрне җыялар. Теманы ачыклыйлар, дәреснең максатын билгелиләр.)*

**Укытучы**. Димәк, без бүген «Алмашлык» темасын кабатларбыз, ныгытырбыз.

Сәяхәткә чыктык. Сәяхәтебезне дәвам иттерер өчен, берничә сорауга җавап бирәсе булыр. Аның өчен сезгә менә шушы Җир шарын тотып торучы куллардагы сорауларны алырга кирәк. *(Һәр төркемнән берничә бала кәгазьләрне ала һәм җавап бирә, анда түбәндәге сораулар язылган.)*

1. Алмашлык нинди сүз төркеме? *(Мөстәкыйль сүз төркеме.)*
2. Башка сүз төркемнәреннән алмашлык нәрсә белән аерылып тора? *(Алмашлык – исемне, сыйфатны, сан һәм рәвешне алмаштырып килә торган мөстәкыйль сүз төркеме.)*
3. Күрсәтү алмашлыкларын санап чыгыгыз. *(Бу, теге, ул, әнә, менә.)*
4. Зат алмашлыгына мисаллар китерегез. *(Мин, син, ул, без, сез, алар.)*

*(Укучылар җавап бирә, мисаллар китерелә.)*

**IV. Уку мәсьәләсен чишү**

**Укытучы.** Хәзер «Кем тизрәк?» уенын уйнап алырбыз. Уенның тәртибе түбәндәгечә: сез хәзер тиз генә өч командага бүленәсез. Тактада ябыштырылган сүзләр.

**Укытучы**. Бу нинди сүзләр? *(Җаваплар бирелә.)*

**Укытучы.** Дөрес. Сорау алмашлыклары. Кулларыгызда – конвертлар. Конверттан сүзләрне алып, димәк, 1 нче команда сорау алмашлыкларыннан – билгесезлек, 2 нче команда – юклык, 3 нче команда билгеләү алмашлыклары ясарга тиеш булачак. *(Тактада эш.)*

**1 нче төркемгә бирем.** Сорау алмашлыкларыннан билгесезлек алмашлыклары.

**Күтелгән җаваплар:** кемдер, кайсыдыр, әллә ничек, әллә кайчан, ничектер, ничәдер, күпмедер, әллә кем һ. б.

**2 нче төркемгә бирем.** Сорау алмашлыкларыннан юклык алмашлыклары.

**Көтелгән җаваплар:** һичкем, һичнәрсә, һичкайсы, беркая, беркайчан, берни, һичкайда һ. б.

**3 нче төркемгә бирем.** Сорау алмашлыкларыннан билгеләү алмашлыклары.

**Көтелгән җаваплар:** һәркем, һәрнәрсә, һәркайда, һәркайчан, һәркайдан һ. б.

**V. Белемнәрне ныгыту**

**Укытучы.** Нәтиҗә ясыйк, укучылар. Димәк, кайбер алмашлыклар ярдәмендә башка төркемгә караган алмашлыклар да ясарга мөмкин икән. Укучылар, дәресебез башында мин сәяхәт итәбез, дидем. Чөнки без күпмилләтле Татарстан Республикасында яшибез. Сәяхәт иткәч, димәк, без юлда төрле милләт кешеләрен дә очратырга мөмкинбез, шулай бит. Безнең Татарстаныбызда нинди халыклар яши икән, уйлап карыйкчы.

**Укучылар.** Татар, рус, чуваш, мари, удмурт, таҗик, төрекмән, башкорт һ. б.

**Укытучы.** Бу милләтләрнең һәрберсенең дә үз гореф-гадәтләре, йолалары, милли киемнәре була. Сез минем белән килешәсезме? *(Укучыларның җаваплары.)*

**Укытучы.** Сез татар кызларын, татар егетләрен ничек итеп күз алдыгызга китерәсез? Я булмаса, рус, чуваш халыкларын? **(5 нче слайд.** *Презентациядә төрле милләт халыкларының рәсемнәре чыга, укучыларның җаваплары тыңланыла.)*

**Укытучы.** Моны ачыклау өчен, биредә мин сезгә бер кызыклы гына бирем әзерләдем. *(Тактада 4 төрле милләт вәкилләре – татар, рус, чуваш һәм мари. Һәр командага конверт бирелә. Конвертта – милли киемнәр, аларда алмашлык кергән җөмлә.)* Шул алмашлыкның нинди төркемчәгә караганын белеп, сез үзегезгә тиешле милләт вәкилен киендерергә тиеш булачаксыз.

*(Зат алмашлыклары, билгеләү алмашлыклары, тартым алмашлыклары, юклык алмашлыклары; нәтиҗәдә татар кызы, татар егете, чуваш кызы һәм рус егете барлыкка килә.)*

**Укытучы**. Бик дөрес. Карагыз әле, аларның һәрберсенең дә киемнәре бик үзенчәлекле, шулай бит?!

**Ял минуты**

**Укытучы.** Дәресебезне дәвам итәбез. Укучылар, хәзер тактага карагыз әле. Бирелгән җөмләләрдә предметны аерып күрсәтү өчен кулланылган сүзләр бармы?

1. **Бу** авылның һич онытмыйм,
   Һәр ягы урман иде…
2. **Теге** урамда безнең йорт.
3. **Әнә** безнең алдыбызда кибет.

*(Бу, теге, әнә сүзләре.)*

**Укытучы.** Бу нинди сүзләр? *(Күрсәтү алмашлыклары.)*

**Укытучы.** Әйе. Бирелгән күрсәтү алмашлыкларын дәфтәрләрегездә килеш белән төрләндерегез. *(Бирелгән сүзләрне килешләр белән төрләндерү эше башкарыла.)* Хәзер бер-берегезнең эшләрен тиз генә тикшереп алыгыз һәм үз бәягезне бирегез.

**VI. Дәресне йомгаклау**


**Укытучы.** Нәтиҗә ясап алыйк. Димәк, алмашлыкларны да, калган сүз төркемнәре кебек үк, килеш белән төрләндерергә мөмкин.

**Сораулар**

**–** Алмашлыклар дип нинди сүз төркеменә әйтәбез? *(Исем, сыйфат, сан кебек сүз төркемнәрен алмаштырып килгән сүзләрне алмашлык сүз төркеме дип атыйбыз.)*

– Сез бүгенге дәрестә алмашлык турында тагын нәрсәләр белдегез? *(Алмашлыкларның берничә төркемчәсе бар, шулай ук алмашлыклар килешләр белән дә төрләнә; бер төркем алмашлыгыннан икенче төркемдәге алмашлыкны да ясап була.)* **(6 нчы слайд)**

12




# КЕШЕ БУЛЫП КАЛА БЕЛ!

*(7 нче сыйныф. Т.Миңнуллинның «Акбур» хикәясе аша бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе)*

**Нәзилә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА,**

Менделеевскидагы Советлар Союзы Герое М.С. Фомин исемендәге 1 нче урта мәктәпнең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Дәрес темасы:** «Кеше булып кала бел!» темасына Т. Миңнуллинның «Акбур» хикәясе аша бәйләнешле сөйләм үстерү *(хикәя «тукталышлар» алымы белән укыла)*.

**Максат:**

**–** укучыларның татар телендә аңлаешлы, үтемле һәм әдәби телдә фикерле белү күнекмәләрен үстерү һәм камилләштерү;

– Т. Миңнуллин шәхесе, аның әсәрләре аша китап укуга кызыксыну тәрбияләү;

– укучыларның «Кылган гамәлләрең өчен үкенерлек булмасын! Нинди генә очракта да Кеше булып калырга кирәк!» фикерләре аша дәрес нәтиҗә ясый алуларына ирешү.

**Җиһазлау:** проектор, презентация, Айрат Сафин башкаруында «Яшә җирдә эз калдырып» җырына үзебез төшергән клип, китаплар күргәзмәсе, чабата, тула оек, бишмәт.

**Материал: «**Татар теленең аңлатмалы сүзлеге», Т. Миңнуллинның «Акбур» хикәясе.

**Дәрес төре:** «тукталышлар» алымы аша сөйләм үстерү дәресе.

*(Автордан: әлеге алым белән дәрес уздыру өчен укучыларга таныш булмаган хикәя алына. Хикәя бик озын да булмаска тиеш, шулай ук анда «тукталышлар» ясау мөмкинлеге дә булырга тиеш.)*

**Дәрес барышы**

**1. Оештыру. Уңай психологик халәт тудыру**

**2. Укытучының кереш сүзе**

**–** Укучылар, бүгенге дәресебез «Кеше булып кала бел!» девизы астында үтәчәк! Сез бу гыйбарәне ничек аңлыйсыз?

– Укучылар, сезнең уйламыйча, берәр нәрсә эшләп, үкенгән чакларыгыз булдымы?

Без бүген укыячак «Акбур» хикәясендә дә сезнең шикелле бер малай шундый хәлдә калган. Хикәянең авторы – Т. Миңнуллин. Ә сез үзегез Т. Миңнуллин турында нәрсә беләсез? *(Укучыларның фикерләре тыңлана, укытучы слайдлар ярдәмендә җавапларны тулыландыра.)*

– Укучылар, бүгенге дәресебез башка дәресләрдән бераз аермалырак булыр. Ни өчен дисәгез, бүген Туфан ага Миңнуллинга ияреп, без дә иҗат итәчәкбез. Мин укыйм-укыйм да туктап калам, ә сез дәвам итәчәксез.

**3. «Акбур» хикәясе өстендә эш**

а) сүзлек өстендә эш.

**кушамат –** кешедән көлеп, мәзәк өчен бирелгән икенче исем

**җан көеге –** эч пошыргыч кеше яки әйбер

**бишмәт –** мамыкны тукыма белән сырып тегелгән өс киеме

**тула –** өйдә сугылган калын, тыгыз тукыма

**тула оек –** йоннан басылган киез, туладан тегелгән аяк киеме

**чабата –** юкә, карама кайрылары тасмаларыннан үреп ясалган баулы сай аяк киеме

**чабата киндерәсе –** чабатаның кырыйларын тотып торган һәм аны аякка беркетү өчен хезмәт итә торган нечкә бау

**мич казнасы** – мич астындагы куышлык һәм аны каплаган нигез

**чәлдерү** – урлау

**сабак** – дәрес

б) хикәяне «тукталышлар» алымы белән уку. *(Укытучы укый-укый да иң кызык урында туктап кала һәм сорау бирә, укучылар үз фикерләрен әйтеп, хикәяне дәвам итәләр,*

*аннары укытучы калган урыннан тагын дәвам итә.)*

Сугыш беткән елны булды бу хәл. Төгәлрәге – декабрь аеның суык, буранлы бер көнендә. Мин шул көнне акбур урладым. «Мин» дигәнем бишенче класста укучы «кофе чәйнеге» һәм «җан көеге».

«Кофе чәйнеге» дигән кушаматны ботаника укытучы Җәүһәрия апа кушты.

**– Ни өчен кофе чәйнеге?** *(Укучылар җавабы.)*

Дәрес вакытларында бертуктаусыз бөтерелеп, ягъни мәсәлән, кайнап утырганым өчен. Мин чәйнек дигән сүзнең мәгънәсен аңласам да, кофеның ни икәнен белми идем. Күргән, ишеткән нәрсәм түгел. Мин генәме, классыбызда беркем белми**.**

**– Ни өчен белмиләр? Сез беләсез бит?** *(Укучылар җавабы.)*

Җәүһәрия апа үзе аңлатып бирде. Җылы якларда үсә торган үсемлекнең орлыгы икән, аны киптереп, төеп, чәй урынына эчәләр икән. Күрәсең, җылы якта гына үскәч, затлы әйбердер. Шуңадыр ахрысы, үз кушаматым үземә ошый иде, хәтта горурлана идем. Аны тагын бер кат ишетер өчен, кайвакытларда кирәгеннән артык «кайнап» ташый идем. Билгеле, нык кайнасаң ташып та китәсең. Андый чакта Җәүһәрия апа усаллана, класс журналына минем фамилия турысына симез генә таяк сыза иде.

Ә «җан көеге» — әни тапкан кушамат.

**– Укучылар, әнисе ни өчен үз улын «җан көеге» дип атады икән?** *(Укучылар җавабы.)*

Дөресен генә әйткәндә, кушамат та булмагандыр инде ул. Нишләсен әни. Малаеның буе дисәң буе юк, тазалыгы ташка үлчим, ә үзен көн саен мәктәпкә озатырга кирәк. Ярый ла, аның мәктәбе бакча артында гына булса, күрше авылда бит. Ике чакрым ара. Көз-яз көннәре әллә ни дә түгел. Кышы бар. Кышның салкыны, җиле бар, ә малайны киендерергә җылы кием юк. Башында йоннары кыршылып беткән бүрек, өстендә мамыгы киезләнеп «такта»га әйләнгән бишмәт, аягында тула оек белән чабата. Менә шул «җан көеге»н кыш көннәрендә юлга чыгарып җибәр. Үзе тагын җил дими, буран дими, мәктәбенә атлыгып тора, җибәрмәсәң елый.

Акбур урлаган көнне дә әни мине мәктәпкә җибәрмәскә тырышты. Катып үләсең бит, хәерсез, диде. Үрсәләнеп елагач, «җан көеге» дия-дия, кыз чагыннан калган шәленә төреп, мине җиденче класста укучы бер малайга такты.

Шушы көнне инде мин классыбыздагы акбурны чәлдердем.

**– Ни өчен алган?** *(Укучылар җавабы.)*

Ни өчен кирәк булган ул акбур – хәзер уйлап-уйлап карыйм – һич очына чыга алмыйм. Шунысын шәп беләм: акбур бик тә, бик тә кадерле иде. Күрәсең, ул җитешмәгән, аны мәктәпкә бик аз биргәннәр, саклап кына тотарга кушканнар. Укытучылар класска акбурны үзләре белән алып керәләр иде дә үзләре белән алып чыгып китәләр иде. Андый кадерле нәрсәне кулга төшереп, койма-капкаларга исемеңне язып йөрү кызык тоелгандыр инде, шуңа урлаганмын мин ул акбурны.

Ничек урлаганым хәтердә калмаган. Әмма бу эшнең оста башкарылганы бәхәссез. Чөнки

акбурның дәрес вакытында «җилгә искәнлегән» укытучы Җәүһәрия апа да, бүтәннәр дә белделәр, тик кая киткәнлеген беркем күрмәгән булып чыкты. Дәрескә алып кермәгәнмен, онытып калдырганмын, дияр иде Җәүһәрия апа, тактада карага ак белән язылган язуы ярылып ята.

Эзләп интекте Җәүһәрия апа акбурны, бездән сорады.

– Күрмәдек, апа, белмибез, апа, – дидек.

Мин дә шулай дидем.

– **Кая яшергән ул акбурны?** *(Укучылар җавабы.)*

Ә акбур тула оек балтыры эчендә. Ныклап капшамасаң, белә дә алмыйсың. Чөнки тула оек үземнеке түгел – әнинеке, аякка сыланып тормый, акбурның кабарып торганы күренми.

Дәресләр беткәндә, буран тагын да котыра төште. Бөтен дөньяны айкый. Күрше авыллардан йөреп, укучыларны өйләренә җибәрмәскә булдылар. Кайсын кая фатирга урнаштырдылар. Ул чак интернат дигән нәрсәләр юк иде.

Мине Җәүһәрия апа үзләренә алып китте.

**– Ни өчен Җәүһәрия апа малайны үзләренә алып кайта?** *(Укучылар җавабы.)*

«Кофе чәйнеге» дисә дә яраткандыр, мөгаен. Яратмаса, җилдән ышыклый-ышыклый урам буйлап кулымнан җитәкләп йөрмәс иде. Җитмәсә, өе дә үзенеке түгел, үзе дә кеше өстендә – фатирда тора. Яратмаса, башымнан әнинең шәлен алып, аңа сырган карларны селкеп кермәс иде, бүрекне, бишмәтне салдырып, чөйгә элеп куймас иде. Яратмаса, мине идән уртасына утыртып, чабатам киндерәләрен чишмәс иде. Аякларың туңгандыр, оегың юпь-юеш, дип сөйләнеп, тула оекларны салдырырга тотынмас иде.

Эх, тотынмаган булса!

**– Сез ничек уйлыйсыз, ни өчен шулай өзгәләнә автор?** *(Укучылар җавабы.)*

Тула оекны сул аяктан тартып чыгаруы булды, көндезге акбур, оек эченнән идәнгә төшеп, мич ягына тәгәрәде. Китапча итеп әйтсәм, эчем жу итеп китте, башымнан миллион уйлар узды. Нишләргә? Хәер, берни эшли алырлык хәлдә түгел идем. Мич казнасына барып терәлгән акбурга карадым да каттым.

**– Җәүһәрия апа бу күренешне ничек кабул иткән?** *(Укучылар җавабы.)*

Җәүһәрия апа, һични булмагандай, уң аяктагы оекны салдырып, оекларны мич алдына киптерергә куйды. Акбурны күрмәдеме икән әллә? Юк, күрмәслек түгел, оек эченнән атылып чыккан акбурны ничек күрмәсен. Әйе, әйе. Хәтта акбур тәгәрәгән якка карап та торды бугай.

Ә нигә соң алай булгач, бер сүз дә әйтмәде? Нигә ачуланмады? Нигә бүтән укытучылар кебек, әни кебек, «урлашудан да начар эш юк», димәде?

**– Ә сез бу сорауларга ничек җавап бирер идегез?** *(Укучылар җавабы.)*

Бу сорауларга җавапны мин озак еллар эзләдем. Җәүһәрия ападан унынчы классны бетергәнчегә кадәр куркып-оялып йөрдем. Әле менә хәзер дә, кырыкка

җиткәндә дә, Җәүһәрия апаны очратсам оялам, каушыйм.

– Нихәл, инде акбур урлавыңны ташладыңмы? – дип әйтер төсле. Ләкин ул әйтми. Бәлки, хәзер оныткандыр. Ә ул чакта…

– **Укытучы нишләгән?** *(Укучылар җавабы.)*

Мине юындырып, ашатып, акбурдан да аграк тышлы юрганга төреп йоклатты. Үз гомеремдә беренче тапкыр ак тышлы юрган астында йоклавым Җәүһәрия апа фатирында булды.

Акбур турында бер сүз дә әйтмәде шул Җәүһәрия апа. Беркайчан да исемә төшермәде.

– **Ни өчен искә төшермәде?** *(Укучылар җавабы.)*

Бәлки, акбурдан да ак чырайлы малайның үз гаебеннән үзе оялып комач кебек кызаруын күргәндер ул. Шушы очрак малай өчен, «кофе чәйнеге» өчен, гомерлек сабак буласына ышангандыр. Шулайдыр.

в) Образларга бәяләмә бирү, синквейн төзү.

– Менә, укучылар, бергәләшеп хикәяне иҗат итеп бетердек. Һәркемнең фикере игътибарга лаек. Укучылар, Җәүһәрия апаның тәрбия алымы турында нәрсә әйтә аласыз? Әйдәгез, бергәләшеп Җәүһәрия апа образына синквейн төзеп карыйк. 1 укучы тактада төзер, калганнар урыннарда. *(Автордан:синквейнны без һәр дәрестә төзибез, ул образларга бәяләмә биргәндә бик уңайлы чара, фикереңне төгәл һәм кыска итеп белдерергә ярдәм итә. Синквейн – «5 юллык шигырь» дигән сүз. 1 нче юлда кем образына төзелә, шул образның исеме языла. 2 нче юлда ике сыйфат, ягъни ул нинди? 3 нче юлда 3 фигыль, ягъни ул нишли? 4 нче юлда ул образны характерлаган 1 җөмлә языла. 5 нче юлда 1 сүз яки сүзтезмә була, ягъни 1 сүз белән аны кем дип атап була?)*

**Җәүһәрия апа**

- Аңлаучан, мәрхәмәтле.
- Аңлый, ярдәм итә, ярата.
- Малайны уңайсыз хәлдә калдырмый.
- Чын укытучы.

– Ә малай турында нәрсә әйтә аласыз? Ул тагын шушы адымга барырмы? Хәзер малай образына синквейн төзеп карыйк.

**Малай**

- Җан көеге, кофе чәйнеге.
- Аңлый, уңайсызлана, югалып кала.
- Уйламыйча эшләгән эшенә үкенә.
- Тәрбияләнә.

**4. Дәрескә нәтиҗә ясау**

– Әйе, укучылар, тормыш шундый катлаулы инде ул, төрле хәлләр булырга мөмкин. Ләкин һәр кеше үзенең эшләгән гамәле өчен үзе җавап бирә, шуңа күрә үкенерлек гамәлләр кылмаска кирәк. Р. Фәхреддин әйткәнчә, бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас! Бала чактан ук Кеше булырга омтылыгыз. Нинди генә очракта да Кеше булып кала белергә кирәк.

Нәкъ менә шушы җырдагыча, «Кылган гамәлләрегез өчен үкенерлек булмасын!» *(7 нче сыйныф укучыларының үзләре катнашында төшерелгән клипны карау. Клип Айрат Сафин башкаруындагы «Яшә җирдә эз калдырып» җырына төшерелде.)*

**5. Өй эше**

– Шушы темага туры килгән татар халык мәкальләре язып килергә.

13



# 9 НЧЫ СЫЙНЫФТА ТАТАР ТЕЛЕННӘН ДӘҮЛӘТ ЙОМГАКЛАУ АТТЕСТАЦИЯСЕ БИРЕМНӘРЕ

**Ләйсән ВӘЛИЕВА,**

*Арча районы Иске Чүриле урта мәктәбенең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Соңгы елларда, уку-укыту системасына яңалыклар кертелү сәбәпле, укучылар һәм укучылар алдына куелган таләпләр үзгәрде. Алар уку-укыту әсбаплары алышынуда, дәрестә яңа эш төрләрен һәм алымнарын куллануда, информацион технологияләрне файдалануны активлаштыруда, белемне тикшерү системасы үзгәрүдә чагылыш табалар. Мондый үзгәрешләр татар теле дәресләрен дә читләтеп үтми, әлбәттә. 9 нчы сыйныфта дәүләт йомгаклау аттестациясе эчтәлегенә дә узган уку елында берникадәр үзгәреш керде. Эчтәлек мәктәп программасына туры килгәнлектән, аңа кереп китү авырлык тудырмады. Тик әзерләнү өчен материалның аз булуы гына кыенлык тудыра. Укытучыларның үзләренә яңа вариантлар төзү ихтыяҗы килеп баса. 22 нче код буенча (рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына) имтиханга әзерләнү өчен үзем төзегән вариантларны тәкъдим итәм.

**Беренче бүлек** 7 биремнән (1–7) тора. Беренче бүлектәге биремнәр сүзләр, җөмләләр, текстны анализлауны таләп итә. Әлеге биремнәрнең җаваплары сүз (сүзтезмә) яки цифрлар белән җаваплар бланкына языла. Соңыннан 1 нче номерлы җавап бланкына күчерелә.

**Икенче бүлектәге** бирем 1 нче бүлек биремнәрен эшләгәндәге текст буенча башкарыла. Эшли башлаганчы, тәкъдим ителгән биремнәрнең (8.1 һәм 8.2) берсен генә сайларга һәм үз фикереңне дәлилләп, эзлекле рәвештә киңәйтелгән җавап бирергә кирәк. Әлеге бирем 2 нче номерлы җавап бланкында эшләнә.

Бланкларны тутырганда, кара гель яки капилляр ручка кулланырга, имтиханда орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт ителә.

Биремнәрне караламада эшләргә була, әмма андагы һәм тикшерү материалларындагы язулар билге куйганда исәпкә алынмый.

Үтәлгән биремнәр өчен куелган баллар бергә кушыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремгә дөрес җавап биреп, югарырак балл җыярга тырышыгыз.

Эшләп бетергәч, 1 нче һәм 2 нче җавап бланкындагы һәр җавапның дөрес номер янында язылуын тагын бер тапкыр тикшерегез.

**1–7 нче биремнәрнең җавапларын сүз (берничә сүз) яки цифрлар белән языгыз. Һәр хәреф яки цифр, бланктагы үрнәктәгечә, аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар буш шакмак калдырмыйча, өтерсез һәм башка тамгаларсыз языла.**

**I вариант**

**I бүлек**

**Синтаксик анализ**

Текстны укыгыз.

1) Еллар үткән, чәчләребезгә чорлар тегермәненең кунагы булып көмеш бәс сарган, маңгайларыбызда вакыт тәгәрмәченең эзләре тирәнәйгән саен, хәтер дигәнең саега бара. 2) Әмма балачакта һәм яшьлек елларында булып узган вакыйгалар кеше күңелендә мәңгегә сүнми, сүрелми икән. 3) Киресенчә, еллар узган саен алар бөтен

ваклыклары, нечкәлекләре белән кабат яңару, адәм баласын инде еракта, бик еракта, күзгә күренсә дә, мәңге барып җитмәслек офыкларда калган саф яшьлек еллары өермәсенә алып китү хасиятенә ия. 4) Сәер хәл бит! 5) Без бүген иртән ни ашаганыбызны (1) ни сөйләгәнебезне оныткан хәлдә дә (2) моннан кырык-илле еллар элек булган вакыйгаларны бөтен нечкәлекләре белән хәтерлибез (3) төнлә уятып сорасалар да (4) сөйләп бирә алабыз. 6) Менә шуңа күрә белемне балага сабый чагында, хәтер дигәнең алмаздай саф яшьлек елларында биреп калырга кирәктер дә. 7) Яшьлектә алган сабаклар онытылмый.

**1. Баш кисәкләр дөрес билгеләнгән җавап вариантларының номерларын языгыз.**

1) Вакыйгалар сүнми, сүрелми икән. *(2 нче җөмлә)*

2) Яңару хасиятенә ия. *(3 нче җөмлә)*

3) Сәер хәл бит. *(4 нче җөмлә)*

4) Без хәтерлибез. *(5 нче җөмлә)*

5) Сабаклар онытылмый. *(7 нче җөмлә)*

**2. Пунктуацион анализ**

Тыныш билгеләрен куегыз. Өтер куелырга тиеш урыннарның цифрларын языгыз.

*Без бүген иртән ни ашаганыбызны (1) ни сөйләгәнебезне оныткан хәлдә дә (2) моннан кырык-илле еллар элек булган вакыйгаларны бөтен нечкәлекләре белән хәтерлибез (3) төнлә уятып сорасалар да (4) сөйләп бирә алабыз.*

**3. Синтаксик анализ**

Төшем килеше кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне табып языгыз.

*Менә шуңа күрә белемне балага сабый чагында, хәтер дигәнең алмаздай саф яшьлек елларында биреп калырга кирәктер дә.*

**4. Орфографик анализ**

Язылышы дөрес аңлатылмаган сүзләрнең номерларын языгыз.

1) *көмеш* – ө хәрефе сүзнең беренче иҗегендә генә языла.

2) *урманлар* – яңгырау тартыкка беткән сүзләргә яңгырау тартыктан башланган кушымча ялгана.

3) *кырык-илле* – парлы сүз, шуңа күрә сызыкча аша языла.

4) *яшьлек* – *ь* билгесе аеру билгесе буларак кулланыла һәм шуңа күрә нечкә иҗектән соң ь билгесе языла.

*5) кульъяулык* – ъ билгесе аеру билгесе буларак кулланыла һәм шуңа күрә калын иҗектән соң ъ билгесе языла.

**Текстны укыгыз һәм 5 – 7 нче биремнәрне үтәгез.**

1) Сәгать алты тулар-тулмас иртәнге прогулкага чыгып барганда, күрше квартирага звонок биреп торучы карчыкка юлыктым. 2) Звонок төймәсе шактый биектә, әбинең буе тәбәнәк кенә: ул, аяк очларына басып, өскә үрелгән. 3) Язгы пальто өстеннән бөркәнгән ак шәле җилкәсенә җыерылып төшкән. 4) Карчык, кулын звонок төймәсеннән алмый гына, миңа текәлеп куйды. 5) Йөзе борчулы, күз карашында нindидер өметсезлек, аптыраш сизелә иде. 6) Болай да ябык, җыйнак гәүдәсе борчудан куырылып калган кебек тоела.

7) Әбигә күршеләремнең бер генә атна элек ялга китүләрен әйттем.
8) Ул, хәвефләнеп, ни әйтергә белми тотлыгып калды.
9) Аның тәмам өметсезлеккә төшүен күреп, кызганып куйдым. 10) «Бик кирәк идемени соң алар?»– дим.
11) Карчык баскан җирендә таптанып алды, авыр сулады.
12) «Кирәк иде шул, бәбкәм, бик кирәк иде. 13) Өченче килүем инде.
14) Мунчага барганда, акчамны онытып калдырып, Хәбирәдән 25 тиен акча алып торган идем.
15) Шуны бирәсем бар иде», – ди.
16) «И әби, шул 25 тиен артыннан йөрмәсәң инде, – дим, – әллә ни зур акча түгел ич!»

17) Карчык миңа ялт кына карап алды. 18) Сүзләремне ошатмавы шундук йөзенә чыкты.
19) «Бирәчәкнең зурысы-кечесе юк аның, бала. 20) Олы кешегә андый бирәчәк белән яшәү дөрес түгел.
21) Үлеп-нитеп китсәм, өстемдә кала ич!» – диде. 22) «Алайса, калдыр соң миңа 25 тиенеңне, алар кайткач кертеп бирермен», – дим.

23) Әбиемнең йөзе балкып китте.
24) Җыерчыклары язылды. 25) Ул, кире уйламасын тагын дигәндәй, миңа ашыгып, тиеннәрен сузды.
26) «И балам, игелекле кеше икәнсең, рәхмәт яугыры, тагын ничекләр килермен дип хафаланган идем.
27) Рәхмәт, балам, аягың-кулың сызлаусыз булсын».

28) Әбинең өстеннән тау төштемени! 29) Ул ашыга-кабалана ишектән чыгып китте. 30) Бурычыннан арынган әбинең эчке бер нур белән балкыган йөзе, ак челтәр шәле күз алдымда торды.

**5. Текстның эчтәлеген анализлау**

Текстның эчтәлегенә туры килә торган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Әби бик шат кыяфәттә күршеләренә звонок бирә иде.

2) Мин әбинең бурычын үзем кертеп бирәм дип алып калдым.

3) Әбинең бирәчәге бик зур иде.

4) Әби миңа олы рәхмәтләрен укыды.

5) Бирәчәкнең зурысы-кечесе юк аның.

**6. Сәнгатьлелек чараларын анализлау**

Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләләрнең номерын языгыз.

1) Язгы пальто өстеннән бөркәнгән ак шәле җилкәсенә җыерылып төшкән.

2) Тик алма, соң өлгерә торганы туры килгәнгә, ачы иде.

3) Карчык миңа ялт кына карап алды.

4) Әбиең өстеннән тау төштемени!

5) Ул, кире уйламасын тагын дигәндәй, миңа, ашыгып, тиеннәрен сузды.

**7. Лексик анализ**

Тексттан «карт» сүзенә синоним булган сүзне табып языгыз.

**II бүлек**

8.1. «Бирәчәкнең зурысы-кечесе юк аның, бала. Олы кешегә андый бирәчәк белән яшәү дөрес түгел.
21) Үлеп-нитеп китсәм, өстемдә кала ич!»– диде.

Текстта китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, инша языгыз. Укылган тексттан фикерләрегезне раслый торган ике дәлил китерегез. Мисаллар биргәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерларын күрсәтегез. Иншаның күләме 100 сүздән ким

булмаска тиеш. Әгәр ул сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу рәвешендә генә булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә. Иншаны пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

8.2. *Бурыч* сүзен ничек аңлыйсыз? Үзегез формалаштырган билгеләмәне дәлилләгез. Үзегез язган билгеләмәне тезис итеп алып, «Бурычлы булып яшәү дөрес түгел» дигән темага инша языгыз. Тезисыгызныраслый торган **ике** дәлил китерегез: дәлилнең **берсен** укылган тексттан алыгыз, **икенчесен** тормыш тәҗрибәгездән чыгып формалаштырыгыз.

Әгәр инша сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу рәвешендә генә булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Иншаның күләме 100 сүздән ким булмаска тиеш.

Пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

**Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.**

**Җаваплар**

| | |
|---|---|
| **1** | 145 |
| **2** | 13 |
| **3** | белемне биреп калырга |
| **4** | 24 |
| **5** | 245 |
| **6** | 34 |
| **7** | олы |

**II вариант**

**I бүлек**

**Синтаксик анализ**

Текстны укыгыз.

1) Кышлак читендә ялгыз бер өй булган. 2) Биредә Хәлимә исемле кечкенә кызы белән Мәрьям апа яшәгән. 3) Ишегалларында гөлчәчәк куаклары үскән. 4) Ана белән кыз әлеге куакларны бик кадерләгәннәр. 5) Көз килсә, аларны камышлар белән төреп, салкын кыштан яшереп куя торган булганнар. 6) Көннәрдән бер көнне ана белән кыз яңа йортка күчәргә җыенганнар.

7) – Әнкәй! Безнең гөлчәчәкләребез каламыни? – дип, әнкәсеннән сорап куйган Хәлимә.

8) – Без күчәсе йортның алдында гөлчәчәкләр күп булса да, боларны да ятим итеп монда калдырмабыз, үзебез белән күчерербез.

**1. Баш кисәкләр дөрес билгеләнгән җавап вариантларының номерларын языгыз.**

1. Өй булган. *(1 нче җөмлә)*
2. Мәрьям апа яшәгән. *(2 нче җөмлә)*
3. Гөлчәчәк үскән. *(3 нче җөмлә)*
4. Ана белән кыз кадерләгәннәр. *(4 нче җөмлә)*
5. Хәлимә куйган. *(7 нче җөмлә)*

**2. Пунктуацион анализ**

Тыныш билгеләрен куегыз. Өтер куелырга тиеш урыннарның цифрларын языгыз.

*Көз килсә (1) аларны камышлар белән төреп (2) салкын кыштан яшереп (3) куя торган булганнар.*

**3. Синтаксик анализ**

Төшем килеше кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне табып языгыз.

*Без күчәсе йортның алдында гөлчәчәкләр күп булса да, боларны да ятим итеп монда калдырмабыз, үзебез белән күчерербез.*

**4. Орфографик анализ**

Язылышы дөрес аңлатылмаган сүзләрнең номерларын языгыз.

1) *шәльяулык* – ь билгесе я хәрефе алдыннан килгәндә, аеру билгесе буларак кулланыла һәм шуңа күрә калын иҗектән соң ь билгесе языла.

2) *көннәр* – нечкә әйтелешле сүз, шуңа күрә *-нәр* күплек сан кушымчасы ялгана.

3) *нәкъ* – нечкә иҗек ахырында к, г хәрефләрен [къ], [гъ] дип уку өчен бу хәрефләрдән соң калынлык билгесе (ъ) куела.

4) *бала-чага* – парлы сүз, шуңа күрә сызыкча аша языла.

5) *җанвар* – *[у]* авазы в хәрефе белән языла.

**Текстны укыгыз һәм 5 – 7 нче биремнәрне үтәгез.**

**Нигә мине татарча өйрәтмәдегез?**

(1) Ничек дип игълан иттеләр әле? (2) «Татарстаннан Ленар Самат улы Вәлиев, Иоганн Себастьян Бах сонаталарын башкарып, беренче урынны алды», – диделәр. (3) Ленар сәхнә уртасына Татарстан флагын күтәреп чыкты. (4) Кул чаптылар. (5) Зал Татарстанны– аның яшелле-аклы-кызыллы төсләрен алкышлады.

(6) Ленар, микрофон янына килеп, рәхмәт әйтә башлады. (7) Шунда алдагы рәтләрдә утырган берәү саф татар телендә:

– Татарча әйт, татарча! Син бит– татар малае! – дип кычкырды. (8) Аңа тагын берничә кеше кушылды. (9) Ленар каушады, чөнки ул татарча белми иде. (10) Элегрәк, авылга кайтып йөргәндә, әбисеннән бераз өйрәнгән иде. (11) Соңгы елларда кайтмый башлады шул. (12) Ә элек белгәннәрен генә оештырып әйтә алмас, мөгаен. (13) Шулай да бөтенләй дәшми калырга теләмәде Ленар.

(14) – Рәхмәт... Мин... әти...әни... Татарстан... яратам... – диде ул.

(15) Шунда ук бераз читтәрәк, затлы урындыкларга утырган әти-әнисенә карады. (16) Ни-чектер кечерәеп калганнар иде алар. (17) Хәзер генә талантлы уллары белән горурланып, башларын күтәреп утырган ата белән ана бу минутта бәхетсез, хәтта сагышлы иде.

(18) Ленар аларга ике төрле сүз, дөресрәге, хис белән карады. (19) Беренче караганда: «Берәр ничек ярдәм итегез инде, бөтен ышанычым сездә», – дип уйласа, бераздан аның каршында «Нәрсә инде бу? Нигә мине татарча өйрәтмәдегез?» дигән моңсу сорау барлыкка килде.

(20) Шунда ук күңелендә ныклы бер уй туды: «Исән-сау Казаныма кайтсам, икенче көнне үк авылга, әбекәй янына китәм. (21) Бөтен дәресләрне, музыканы, котлауларны ташлыйм да...

(22) Кайтып киләм!..»

**5. Текстның эчтәлеген анализлау**

Текстның эчтәлегенә туры килә торган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1. Ленарга гөрләтеп кул чаптылар.
2. Ленар Россия флагы күтәреп чыкты.
3. Ленар татарча белми.
4. Ленарның әти-әниләре бик бәхетле.
5. Ленар кичекмәстән авылга кайтырга карар кылды.

**6. Сәнгатьлелек чараларын анализлау**

Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләләрнең

номерын языгыз.

1) Урындыкларга утырган әти-әнисенә карады.

2) Күңелендә ныклы бер уй туды.

3) Соңгы елларда кайтмый башлады.

4) Берәр ничек ярдәм итегез инде.

5) Ничектер кечерәеп калганнар иде алар.

**7. Лексик анализ**

Тексттан «әләмен» сүзенә синоним булган сүзне табып языгыз.

**1–7 нче биремнәрнең җавапларын сүз (берничә сүз) яки цифрлар белән языгыз. Һәр хәреф яки цифр, бланктагы үрнәктәгечә, аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар буш шакмак калдырмыйча, өтерсез һәм башка тамгаларсыз языла.**

**Барлык җавапларны, эшне башкару буенча күрсәтмәдә әйтелгәнчә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга онытмагыз. Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.**

**II бүлек**

**8.1. «Исән-сау Казаныма кайтсам, икенче көнне үк авылга, әбекәй янына китәм. Бөтен дәресләрне, музыканы, котлауларны ташлыйм да... Кайтып киләм!..»**

Текстта китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, инша языгыз. Укылган тексттан фикерләрегезне раслый торган ике дәлил китерегез. Мисаллар биргәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерларын күрсәтегез. Иншаның күләме 100 сүздән ким булмаска тиеш. Әгәр ул сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу рәвешендә генә булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә. Иншаны пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

**8.2. Туган тел** сүзтезмәсен ничек аңлыйсыз? Үзегез формалаштырган билгеләмәне дәлилләгез. Үзегез язган билгеләмәне тезис итеп алып, **«И туган тел»** дигән темага инша языгыз. Тезисыгызны раслый торган **ике** дәлил китерегез: дәлилнең **берсен** укылган тексттан алыгыз, **икенчесен** тормыш тәҗрибәгездән чыгып формалаштырыгыз.

Әгәр инша сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Иншаның күләме 100 сүздән ким булмаска тиеш.

**Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.**

**Җаваплар**

| | |
|---|---|
| 1 | 124 |
| 2 | 12 |
| 3 | Боларны калдырмабыз |
| 4 | 25 |
| 5 | 235 |
| 6 | 24 |
| 7 | флагын |

14




# И.ЮЗЕЕВНЕҢ «ӨЧӘҮ ЧЫКТЫК ЕРАК ЮЛГА» ПОЭМАСЫН ӨЙРӘНҮ

*(Заман мәсьәләләренең өч герой аша сурәтләнеше. Символик образларның автор идеясен ачудагы роле)*
*(9 нчы сыйныфта татар әдәбияты дәресе)*

**Гөлфия ГАЛИЕВА,**

Әтнә районы Күңгәр урта мәктәбенең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:**
*Дидактик*:
– уку күнекмәләрен формалаштыру өстендә эшләү; эчтәлек буенча анализ ясап нәтиҗә чыгарырга, геройларга характеристика бирергә өйрәнү.
*Үстерелешле:* укучыларның логик фикерләү сәләтен, мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын һәм танып белүне үстерүгә ярдәм итү.
*Тәрбияви:*
– аңлап уку тәрбияләү, үзара һәм үзеңне бәяләргә өйрәтү, аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру; поэма аша укучыларда ихтыяр көче тәрбияләү.
**Көтелгән нәтиҗәләр:**
*Предмет:*
– әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлату, төп фикерне таба белү; әсәрдә автор карашларын ачыклау һәм әсәргә карата үз фикереңне әйтә белү; әдәби әсәрне эчтәлек һәм форма берлегендә аңлау.
**Метапредмет нәтиҗәлелек:**
*Регулятив:* дәреснең темасын, проблемасын, максатын мөстәкыйль таба белү; уку проблемасын чишү; үз фикерләреңне мөстәкыйль дәлилләү; үзанализ һәм үзбәя булдыру.
*Танып белүдә:* әдәби әсәрне дөрес аңлап уку һәм анализлау; дөрес нәтиҗәләр чыгару, гомумиләштерү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булдыру; үз фикереңне исбатлый һәм яклый алырга күнектерү; әсәр хакында дөрес фикер йөртә алу.
*Коммуникатив:* иптәшеңне тыңлый, ишетә белү, ишеткәнен үз фикере белән чагыштыру; нәтиҗәгә килгәнче, төрле карашларны өйрәнү һәм дөрес юлны сайлау; үз фикереңне телдән һәм язма формада башкаларга җиткерә белү; килеп чыккан проблемаларны уртага салып хәл итү; төркемнәргә берләшү, бер фикергә килә белү.
*Шәхескә кагылышлы:* укуга карата теләк-омтылыш, җаваплы караш булдыру; гаделлек, дөреслек, яхшылык, мәрхәмәтлелек һәм аларның киресе булган сыйфатларны тану, бәяләү; алган белем һәм осталыкны тормышта максатчан кулланырга өйрәнү.
**Предметара бәйләнеш:** әдәбият, табигать белеме.
**Танып белү эшчәнлеген оештыру методлары:** проблемалы ситуация тудыру, өлешчә эзләнүле.
**Эш төрләре:** фронталь, төркемнәрдә һәм индивидуаль эшләү.
**Ресурслар:** татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек. 2 кисәктә; компьютер, проектор, тема буенча презентациясе.
**Дәрес барышы**
**I. Ориентлашу-мотивлаштыру этабы**
Уңай психологик халәт булдыру.
**Укытучы.**
*Балачак ул – безнең бишегебез,*
*Нигезебез, туган ягыбыз.*
*Әллә шуңа, олыгайган саен,*
*Балачакка тарта җаныбыз.*
*Балачакның яшел урамнары*
*Безне сагынып каршы алачак.*
*Әгәр кайтмый калсак, беркайчан да*
*Гафу итмәс безне балачак.*
Хәерле көн, укучылар! Бүгенге

дәресебезне менә шундый матур шигырь юллары белән башлап җибәрдем. Р. Миңнуллинның «Балачакка ешрак кайтыгыз!» шигырен тыңлаганда, сезнең күңелегездә нинди хисләр туды. Әгәр сез рәссам булсагыз, нинди рәсем ясар идегез. *(Укучыларның фикерләрен тыңлау.)* Сезнең матур күзаллауларыгыздан чыгып, бүгенге дәресебезнең темасын әйтеп карыйк. (И.Юзеевнең «Өчәү чыктык ерак юлга» поэмасында заман проблемалары…)

**II. Белемнәрне актуальләштерү**

**Укытучы.** Үткән дәресләрдә без И. Юзеевнең тормыш юлы һәм шигырьләре белән таныштык. Ә сезгә өй эше итеп, аның «Өчәү чыктык ерак юлга» поэмасын укып килергә бирелгән иде. Поэма ничек, нәрсә белән башланып китә? *(Ул лирик геройның уйланулары белән башланып китә.)* Әйе, ул лирик геройның балачагы, олы кешенең яшьлеге турындагы фикер карашлары белән башланып китә.

**III. Уку мәсьәләсен кую**

**Укытучы.** Бүген без бу поэма турында әңгәмә корырбыз. Эшне өч төркемдә оештырырбыз. Алдыгыздагы таблицага, дәрестә катнашуыгызга карап, үзбәя куеп барырсыз.

– Укучылар, әйдәгез, поэманың эчтәлеген искә төшереп китик. Моның өчен төркемнәрдә һәм парларда эшләп алырбыз. Поэма шартлы рәвештә өч өлешкә бүленгән, 1 нче төркем – беренче өлешне, 2 нче төркем – икенче, 3 нче төркем өченче өлеш эчтәлеген билгели. Сезнең алдыгызда – әсәрнең төп вакыйгалары билгеләнгән «көймәләр». Бурычыгыз – аларны поэма эчтәлеге буенча тәртипкә салу. Эшне тәмамлагач, тикшерү өчен каршыбыздагы парлар белән алышабыз. Эшләрне тикшерәбез. Каршыдагы парларның хаталары бармы?

**IV. Уку мәсьәләсен чишү**

**Укытучы.** Димәк, беренче нинди вакыйга булган, аннан соң? Укучылар, поэманың сюжетыннан чыгып, поэманың **темасын** билгелик. Әсәр нәрсә турында? *(Яшьлектә дөрес тормыш юлын сайлау хакында.)*

**Укытучы.** Әйдәгез, поэмадагы хисләрне әйтеп карыйк әле. *(Әсәрнең үзәгендә истәлек-хатирәләр, балалык елларын сагыну хисе, дусты өчен борчылу хисе ята. Шагыйрь хәтер канатында яшьлегенә әйләнеп кайта, «су өстендә чалкан яткан чакларын» искә төшереп, гомер йомгагын сүтә башлый*

*–Көймә килә, көймә килә,*
*Өчегез дә уникедә, – ди кәккүк.)*

**Укытучы.** Укучылар, поэмага нинди образлар килеп керә? Образлар системасын карап узыйк. Алдыгыздагы битләргә образларны язып та куярбыз.

Төп герой бирелешенең тирәнлеген ачыклау өчен ярдәмче, эпизодик, табигать, әйбер образлары, җыелма яки ясалма образлар була.

Табигать, әйбер образлары, җыелма яки ясалма образлар кеше образларын ачуга хезмәт итә.

*Төп геройлар:* Фазылҗан, Нур, лирик герой.

*Ярдәмче образлар:* су юлы, көймә, кәккүк.

*Эпизодик образ:* төн кешесе.

*Җыелма образ:* дуслар (сыйныфташлар), пионерлар.

*Ясалма образ:* су юлы, көймә,

кәккүк, төн кешесе (аллегорик).

**Төркемнәрдә эш**

**Укытучы.** Димәк, егетләр төрле авырлыклар узачак, инде хәзер үк алар ишкәк артына утырган.

**Сорау** *(төркемнәргә бирелә)*. Әйдәгез, әсәрдәге ясалма образлар турында сөйләшеп китик. Беренче төркем – кәккүк образы турында, 2 нче төркем – көймә, 3 нче төркем төн кешесе турында әзерләнеп сөйләр.

**1 нче төркем.** Кәккүк образы яшьләрне күзәтеп, искәртеп, киңәшләрен биреп тора.

**2 нче төркем.** Чишмә, көймә образы турында сөйли. Көймә образы – тормыш көймәсе, су юлы – тормыш.

**3 нче төркем**. Төн кешесе.

**Укытучы.** Без әле генә карап узган образлар Фазылҗан образы белән бәйле. Аның турында без нәрсәләр беләбез? Нинди ул? *(Егетләр белән көймәгә утырып, юлга чыга; музыкага сәләтле; адашкан кеше; ихтыяр көче юк; авырлыклар алдында куркып кала.)* Әйе, сез санап киткәннәр – Фазылҗанга хас сыйфатлар. Хәзер, укучылар, үз фикерләрегезне белдерер өчен бер уен уйнап алырбыз. Сез төп герой образы урынына куеп, үз фикерләрегезне язачаксыз.

Безгә алгоритм буенча эш эшләргә кирәк булачак. *(Алгоритм экранда бирелә.)*

1. Бирелгән объект героен сайларга.
2. Герой образына керү. Үзеңне объект урынына куярга һәм аның исеменнән тәэсирләреңне сөйләргә.
3. Геройның эмоциональ халәтен гәүдәләндерү.
4. Һәр үзлекне ассоциация буенча туган образ белән тулыландыру.
5. Проблемалы ситуацияләрне чишү.
6. Иҗади эштә геройның эмоциональ тигезләнешен кайтарып, әсәрне төгәлләү.

**Укытучы.** Әйдәгез, укучылар, иҗади эшебезне башлыйбыз. *(Укучыларның эшләре тикшерелә. Һәр төркем бер эшне яклый.)* Укучылар, әйтегезче, әсәрдә нинди проблемалар күтәрелә? *(Һәркем үз юлын үзе сайларга тиеш. Ләкин сайлаганда ялгышырга ярамый! Җирдә үз сукмагыңны табарга, тормыш сынауларын җиңәргә кирәк.)*

**Укытучы.** Әсәрнең темасын, проблемасын, идеяне (автор әйтергә теләгән төп фикерне) билгеләгез. Автор хисенең сәбәбе турында сөйләгез. *(Укучылар җавабы.)*

**V. Рефлексия**

Гомумиләштерү, нәтиҗә ясау.

**Укытучы.** Поэманың соңгы юллары аша безниләр аңладык?

– Ике юл бар синең алда, – ди кәккүк.

– Теләсә кайсын үзең сайла, – ди кәккүк.

**Укытучы.** Аңлашылмаган моментлар калмадымы, күңелегездә яңа сораулар тумадымы? Гомумән, дәрес буенча нинди нәтиҗәләр ясыйбыз?

**Үзбәя**

**VI. Өй эше**

1. Дәреслекнең 39 нчы битендәге поэмага нәтиҗә ясау өчен бирелгән сорауларга җавап әзерләргә.
2. Кешеләрдәге ихтыяр көчен туплауга туры килгән өч мәкаль табып язарга.
3. «Минем киләчәк тормышым» темасына кечкенә инша язарга.

**VII. Билгеләр кую**




15

# ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ «ӘЙТЕЛМӘГӘН ВАСЫЯТЬ» ХИКӘЯСЕ

*(9 нчы сыйныфта татар әдәбияты дәресе)*

**Ләйсән БАҺАВИЕВА,**

Кайбыч районы Олы Кайбыч урта мәктәбенең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:** язучының биографиясен искә төшерү, әсәр өстендә эшләү; укучыларның иҗади һәм фәнни фикерләү күнекмәләре үсеше өчен шартлар тудыру; гореф-гадәт, йолаларга хөрмәт тәрбияләү.

**Бурычлар:** укучыларның фикерләү активлыгын, сөйләм телен үстерү; укучыларда УУГ (танып белү, регулятив, коммуникатив, шәхескә кагылышлы) формалаштыру.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы:* активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә, акыл һәм рухи эшчәнлеккә өйрәтү.

**Метапредмет нәтиҗәләре***:*

*Регулятив УУГ:*

– мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын формалаштыру;

– максатка ирешү юлларын билгеләү;

– укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү.

*Танып белү УУГ:*

– үзенә кирәкле мәгълүматны төрле формада бирелгән чыганаклардан туплау;

– үз фикерен дәлилләү.

*Коммуникатив УУГ:*

– төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;

– күмәк эш вакытында бер фикергә килә белү.

**Предмет нәтиҗәләре:**

– автор карашын, мөнәсәбәтен аңлау;

– укыган текст буенча сорауларга җавап бирү.

**Предметара бәйләнеш:** тарих.

**Җиһазлау:** дәреслек, компьютер, экран, проектор, PowerPointда презентация, Әмирхан Еники портреты, карточкалар, сүзлекләр.

**Эшчәнлекне оештыру формасы:** парлап, төркемнәрдә эш.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру**

**Укытучы.** Хәерле көн, укучылар! Хәерле эш көннәре теләп, дәресебезне башлыйк.

**II. Белемнәрне актуальләштерү**

**Укытучы.** Бүгенге дәресебезгә эпиграфы итеп «Учагыңда ут сүнмәсен» дигән сүзләрне алам. Дәрес азагында ни өчен икәнен әйтерсез дип уйлыйм.

– Укучылар, сез кайсы язучының биографиясен укып килдегез? *(Әмирхан Еникинең.)*

**III. Танып белү эшчәнлеге. Фронталь эш**

**Укытучы.** Яраткан язучыбызның тормыш юлы ничек үткән? Моны ачыклар өчен даталарга мөрәҗәгать итик. *(Даталар тәкъдим ителә.)*

**Укытучы.** Күргәнегезчә, язучы озын гомер юлында төрле сынаулар аша үткән. Бөек Ватан сугышында катнашкан. Туган туфракка хөрмәт, аны ярату ямьле Дим буенда үскән егеткә тормыш тәҗрибәсе аша килгән. Иҗатының тематикасы: авыл, сугыш, туган туфрак, йолалар.

Ә хәзер сезнең игътибарга видеотасма тәкъдим итәм. *(Видеоязма тыңлыйлар.)*

– Әйтегез әле, әлеге видеотасма белән безнең бүгенге дәресебез арасында нинди бәйләнеш булыр икән?

**Укучы.** Уйлавымча, без бүген Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрен тикшерәчәкбез, Акъәби турында фикер алышачакбыз.

**Укытучы.** Әйе, укучылар, барыгыз да әсәр белән таныш, тулы вариантын да укып чыктыгыз. Нәрсә соң ул васыять? *(Укучылар җавабы.)* Ни өчен әсәр «Әйтелмәгән васыять» дип атала? *(Укучылар җавабы.)*

**IV. Уку эшчәнлеген чишү. Парларда эш**

**Укытучы.** Укучылар, ә сезгә әсәрне укыган вакытта аңлашылмаган сүзләр очрамадымы? (*Кәфенлек*

сүзе.)

**Укытучы.** Тексттан әлеге сүз турында барган урынны табып укыйк әле. («*Һай, кәфенлегемне оныткан-мын бит!» – диде әни кеше. «Куйсана, әсәй!» – диде кыз*.)

– Ни өчен Гөлбикә әнисенең борчылуын аңламый? (*Чөнки кыз үз милләтенең йолаларын белми, оныткан*.) Әйе, бу бик кызганыч. Тагын башка аңлашылмаган сүзләр булмадымы? *(Кылганнар.)*

**Укытучы.** Моңа җавапны сез сүзлекләрдән таба аласыз. Укучылар, Акъәби шәһәргә килә. Бирелә оныклары белән очрашу ничек үтә, алар ничек сөйләшәләр? Искә төшерик әле.

**Укучылар.** Кызлар, әбине сырып алып: «Здравствуй, дорогая бабушка!» –дип күрешәләр. Папаларына мама тиешле әби-карчык.

**Укытучы.** Монда нинди мәсьәлә күтәрелә? *(Туган телне белмәү.)* Укучылар, ни өчен әбинең исеме Акъәби? *(Укучылар җавабы.)* Ә сезнең шундый әбиләрегез бармы? *(Укучылар җавабы.)*

(*Мониторда рәсем чыга*.)

**Укытучы.** Әбинең өс-башы нинди? Алъяпкычына игътибар итегез әле, бу бит – милли киемнең бер элементы. Бөрмә-бөрмә тегелгән, изүе чигүле. Ә болар ни? ( *Элгечтә милли киемнәр элengән*.) Әлбәттә, милли киемнәр. Сезгә болар бары да таныш. Әйтегез әле, Акъәбинең сандыгында ниләр бар иде соң? *(Җаваплар.)* Калпак бүрек ул ни? Ничек ясала? Җавапны шулай ук сүзлекләрдән таба аласыз. Бүген сезгә калпак бүрекне күреп тә, тотып та карау бәхете елмая. Сандыкта тагын ниләр бар? (*Хәситә. Аны да күрсәтү мөмкинлеге табылды*.) Болар барысы да милли киемнәр булып тора. Безнең рухи байлыгыбыз.

**Төркемнәрдә эш**

Укучылар, текст эчтәлегендә символ булырлык сүзләр очрады дип саныйм. Сезнең нindirәк фикерләрегез булыр икән? Әйдәгез, төркемнәрдә эш башкарып алыйк. *(Җаваплар.)* Рәхмәт. Җавапларыгызны кабул итәм.

**Ял минуты:**

**Укытучы.** Хәзер урыннарыбыздан торабыз, һәм стенага беркетелгән рәсемнәр янына барып басуыгызны сорар идем. *(Йорт, чулпы.)* Ни өчен син *(укучыга мөрәҗәгать итеп)* чулпы рәсемен сайладың? Ә син нишләп йорт рәсемен сайларга булдың? *(Барысы да үз фикерләрен әйтеп чыгалар.)* Яхшы. Фикерләрегез кызыклы, шул ук вакытта урынлы да дип саныйм. Ә хәзер мин сезгә парларда эшләргә тәкъдим итәм. Моның өчен мәкальләр таратып чыгам, ә сез аны аңлатып китәргә тиеш буласыз. *(Җаваплар.)*

**Рефлексия**

**Укытучы.** Янәдән эпиграфка кайтыйк әле. Учакта ут сүнмәс өчен без ниләр эшләргә тиеш? Моның өчен учак рәсеме төшкән кәгазь битләренә фикерләрегезне язып, безгә укып, тактага беркетүегезне сорыйм. *(Җаваплар.)*

**Өй эше**

Укучылар, өй эше итеп сезгә сайлап алу мөмкинлеге белән 3 бирем тәкъдим ителә.

1. 107–108 нче биттәге сорауларга җавап бирергә.
2. Әсәрнең планын төзергә.
3. Акъәбинең балаларына үз исемеңнән хат язарга.

Ә хәзер, кулга-кул тотынышып, күңел түреннән чыккан җылылыкны бер-беребезгә өләшеп, әби-бабаларыбыз кабызган учак гел балкып, җылытып торсын, буыннар арасында бәйләнеш өзелмәсен дигән теләктә дәресебезне тәмамлыйбыз. Игътибарыгыз, дәрестә актив булганыгыз өчен рәхмәт.

16





# ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘТҮДӘ «МАВЫКТЫРГЫЧ КЕЛӘМ» УЕНЫ

*(Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен)*

**Зилия ГАЛИМУЛЛИНА,**

*Казандагы 177 нче балалар бакчасының I квалификация категорияле татар теле тәрбиячесе*

«Мавыктыргыч келәм» уены 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телендә аралашучы балалар өчен тәкъдим ителә. Уенны Зифа Зарипованың УМК «Татарча сөйләшәбез»[1] проектының барлык лексик темаларын ныгыту, камилләштерү максатын күздә тотып кулланырга була.



Балалар бакчасында татар телен өйрәтүдә нейропсихолог Татьяна Поневежскаяның[2] келәмен куллану балалар өчен уңай эмоциональ шартлар тудыра. Нейропсихология – баланың үсешен тоткарлаган кимчелекләрне күрергә, сәбәпләрен ачыкларга һәм алар өстендә эшләргә ярдәм итә. Келәмдә уйнаганда бирелгән биремнәр әйләнә-тирә мохиттә ориентлашу үсешенә китерә. Шуның белән беррәттән, бала уйнаганда хәрәкәт тә итә, димәк, физик яктан да чыныга.

Келәм идәндә уйнар өчен җайлана. Тукыманың төренә һәм аның үлчәмнәренә билгеле таләпләр юк. Шәхсән минем келәм буе 1,5 м, иңе 1,5 м булган күн тукымадан тегелгән. Келәм горизонталь һәм вертикаль юнәлешләрдә атлас тасма ярдәмендә бишәр шакмакка бүленгән. Тасмаларның үлчәмнәре 30х30 см, төсе ирекле. Уен барышында бала келәм буенча йөри яисә сикерә.

«Нейропсихологик келәм»дәге биремнәр балаларның яше һәм тел белү дәрәҗәсенә карап үзгәртелә (җиңеләйтелә яки катлауландырыла).

**«Дустыңны сыйла» уены**




*(4–5 яшьтәге балалар өчен тәкъдим ителә.)*

**Максат:**

– «Уенчыклар», «Ашамлыклар» темалары буенча сүзләрне ныгыту;

– «Мә, ипи аша», «Мә, чәй эч», «Рәхмәт, тәмле» сөйләм үрнәкләрен кертү һәм активлаштыру.

**Җиһазлау:** нейропсихологик келәм, уенчыклар (эт, песи, аю, куян, курчак), ашамлык муляжлары яки рәсемнәре (ипи, алма, сөт, чәй, кишер), елмаючы йөз рәсеме (смайлик), кәрзин.



**Уен барышы.** Келәмдәге шакмакларга төрле уенчыклар урнаштырылган. Уенчыкларны урнаштыру тәртибен тәрбияче үзе билгели. Аларның һәр рәттә булуы мәҗбүри түгел. Мәсәлән, 2, 3 нче рәтләрдә генә булырга мөмкин. Бала тиешле ноктага кадәр келәм буенча

**Кулланылган әдәбият**

1. УМК *Татарча сөйләшәбез. 4–7 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек.–Казан: Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты, 2011.– 56 б.*

2. *http://l-integral.ru›ro-io/docs/Ковер нейропсихолога.pdf*

барып җитәргә тиеш. Хәрәкәт итү шакмаклар яки тасмалар өстеннән йөреп башкарыла. Мәсәлән, тәрбияче, балага келәмнең соңгы шакмагында урнашкан куян янына барып, аны сыйларга тәкъдим итә. Ләкин аның янына барып җиткәнче, бала рәтләрдәге шакмакларда урнашкан уенчыкларны (аю, песи, эт, курчак) сыйларга тиеш була. Уенның башлангыч ноктасы булып елмаючы йөз (смайлик) тора. Баланың кулында – ашамлыклар салынган кәрзин. Ул башлангыч ноктага баса һәм уенчыкка барып җиту юлын эзли. Уенчыкларны сыйлау тәртибе рәтләр буенча башкарыла. Иң беренче, 1 нче рәттәге уенчыкка барып җитәргә, аннары 2, 3 нче һәм соңгы рәттәге уенчыкка барып җиткәнче хәрәкәт итәргә тиеш була. Уенчык янына (әйтик, песи булсын, ди) килеп җиткәч иелә, кәрзиннән үзе теләгән ашамлыкны алып сыйлый. Тәрбияче уенчык исеменнән ашамлык белән сыйлана, рәхмәтен белдерә.

**Бала.** Песи, мә сөт эч.

**Песи.** Рәхмәт, тәмле.

Бала ашамлыгын уенчык янында калдыра һәм юлын дәвам иттерә. Шул рәвешле, бала, уенчыкларны чиратлап сыйлап, куян янына барып җитә.

**Бала.** Куян, мә кишер аша.

**Куян.** Рәхмәт, тәмле.

«Дустың белән исәнләш», «Уенчык ал», «Хәлләр ничек?», «Уенчык нинди?» кебек уеннарны да шушы тәртиптә уйнарга мөмкин.


**«Бу нәрсә, нинди?» уены**

*(5 – 6 яшьтәге балалар өчен тәкъдим ителә.)*

**Максат:** «Уйный-уйный үсәбез» проекты кысаларында каралган лексиканы ныгыту.

**Җиһазлау:** магнит тактасы, нейропсихологик келәм, таратма рәсемнәр, хәрәкәтне күрсәтүче уклар.

**Уен барышы**



Уен келәм буенча хәрәкәт итү юнәлешен (уңга-сулга, өскә-аска) күрсәтүче уклар куеп катлауландырыла. Алар бала каршысындагы магнит тактасына беркетелә. Шакмаклар уртасына ламинатор аша үткәрелгән рәсемнәр куела. Бала укларга карап хәрәкәт итә, шакмактагы рәсемне һәм аның билгесен атый.

Рус телле балалар өчен юнәлеш сүзләрен татарча истә калдыру авыр, шуңа күрә өч төрле вариантта эшләргә мөмкин:

1. Бала юнәлешне эчтән генә фикерләп билгели (русча әйтсә дә ялгыш булмас) һәм хәрәкәт итә.

2. Тәрбияче юнәлеш сүзләрен татарча әйтеп бара, бала хәрәкәт итә.

3. Әгәр бала сүзләрне истә калдыра ала икән, аларны тәрбияче артыннан яки мөстәкыйль рәвештә татарча әйтергә мөмкин.

Уенның башлангыч ноктасы булып елмаючы йөз (смайлик) тора.

Мәсәлән, **бирем:** башлангыч ноктадан бер адым өскә. Бу шакмак эчендә кызыл кашык рәсеме. Эшнең максаты сүзләрне активлаштыру булса, сорау-җавап рәвешендә эшлибез.



**Тәрбияче.** Бу нәрсә?
**Бала.** Кашык.
**Тәрбияче.** Кашык нинди?
**Бала.** Кашык кызыл.


Әгәр эшчәнлек активлаштырыла торган тел материалын мөстәкыйль рәвештә куллана белүне ачыклау максатында үткәрелсә, бала шакмаклар эчендәге рәсемнәрнең исемен һәм аның билгесен үзе әйтә. Төрле темаларга караган сүзләрне аралаштырып алырга була. Мәсәлән, сары суган, кызыл күлмәк.

**«Җөмләне дөрес төзе» уены**

*(6 – 7 яшьтәге балалар өчен тәкъдим ителә.)*

**Максат:** таныш лексиканы ныгыту, аны җөмлә калыбында кулланырга өйрәтү.

**Җиһазлау:** магнит тактасы, нейропсихологик келәм, таратма рәсемнәр, хәрәкәтне күрсәтүче уклар, елмаючы йөз рәсеме (смайлик).




**Уен барышы**

Бирем укларга саннар өстәп катлауландырыла. Алар ясаласы адымның санын билгели (мәсәлән, «ике шакмак уңга», «ике шакмак өскә», «өч шакмак сулга», «ике шакмак өскә»). Ук рәсемнәре, бала каршысындагы магнит тактага беркетелә. Келәмнең башлангыч ноктасы булып елмаючы йөз (смайлик) тора. Бала ук күрсәтүе буенча хәрәкәтләнә. Шулай ук өч вариантта эшләргә була. Тәрбияче яки бала үзе «бер шакмак сулга», «өч шакмак уңга», дип әйтеп барырга мөмкин. Адымнарны ясаганда, саннарны ныгыту максатында, кычкырып санарга киңәш ителә. Бала рәсемнәрне, аларның билгесен яисә эш-гамәлен белдерүче сүзне атый һәм аларны җыеп бара. Биремне үтәп бетергәч, җыелган рәсемнәрне дөрес тәртиптә урнаштырып җөмлә төзеп әйтергә тиеш була.





Мәсәлән, башлангыч ноктадан ике адым уңга (бабай рәсеме), ике адым өскә (зурлыкны белдерүче рәсем), өч адым сулга (яшел карават рәсеме), ике адым өскә (эш-гамәлне белдерүче «йоклый» рәсеме). Җыелган рәсемнәрдән түбәндәге җөмлә килеп чыга: «Бабай зур яшел караватта йоклый».

Татьяна Поневежская методикасы буенча ясалган нейропсихологик келәм – универсаль. Аны психологлар, логопедлар гына түгел, тәрбиячеләр дә, татар теле укытучылары да үз эшләрендә продуктив куллана алалар.



17

# МӘКТӘПТӘ НЕЙРОН ЧЕЛТӘРЛӘРЕН КУЛЛАНУ

**Гөлнара ГАЛИМОВА,**

Чирмешәндәге кадет интернат-мәктәбенең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Ясалма фәһем (интеллект) көннән-көн тормышыбызга ныграк керә бара. Ясалма фәһем ул (ЯФ) – корал гына түгел, ә мәгариф үсешендә яңа этап.

ЯФ ул – программа түгел, ә компьютер фәннәренең аерым юнәлеше. ЯФ белгечләре – мәгълүматны анализлаучылар. Алар, кеше эшләгән кебек, үк мәсьәләләрне хәл итүче системалар төзи. Кайвакыт ул нейрон челтәре белән бутала, ләкин бу өлешчә генә дөрес. Нейрон челтәре – баш миендәге нейрон системасы белән рухландырылган ЯФ ясауның бер ысулы. Бу мәсьәләләрне чишү өчен катлаулы алгоритмнар язу урынына, нейрочелтәрләр күпсанлы мәгълүмат нигезендә өйрәнәләр һәм аларда закончалыклар табалар.

Бу нейрочелтәрләр планнар төзи, фәнни мәкаләләрне йомгаклап яза, программа кодын яза, рәсем ясый, музыка яза, сериал сценарийларын уйлап таба һәм хәтта шигырьләр яза белә. Теләсә нинди сорауга җаваплар табарга, шулай ук мәктәп укучылары өчен өй эшләрен дә башкарырга өйрәтелде.

Мәгариф – нейрон челтәрләрен куллану актив үсеш алган өлкә. Ул уку сыйфатын яхшырту һәм белем бирү методикаларын үстерү өчен уникаль мөмкинлекләр тәкъдим итә.

Ясалма фәһем ярдәмендә бик тиз:

– дәрес, проект, презентация өчен уникаль рәсем ясарга;

– презентация, видео, Gif-анимация булдырырга;

– музыка файлын булдырырга һәм эшкәртергә;

– укучылар өчен «гади аңлатма» картасы ясарга;

– проект өчен исем уйлап табарга;

– текстны сөйләмгә, сөйләмне текстка үзгәртергә мөмкин.

Нейрон челтәрләрен дәрескә әзерләнгәндә, дәрес үткәргәндә куллануның берничә ысулы:

1. Программалар төзү. ChatGPT яки башка шундый нейрон челтәр, һәр укучының уникаль ихтыяҗларын һәм уку стилен исәпкә алып, индивидуаль белем бирү программалары һәм планнары булдырырга булыша, дәрес программасын төзи ала.

Чат-бот сез уйлап тапкан теләсә нинди темага уку өчен өзек тәкъдим итә ала. Моннан тыш, ул, укучының яшенә һәм уку күнекмәләренә карап, төрле текстлар төзи ала. Фикер алышу өчен өзекләр, сораулар һәм темалар әзерләргә ярдәм итә. Шулай ук моны вакыт буенча структуралаштырырга тәкъдим итә. Алар материалларны, күнегүләрне һәм бәяләүләрне җайлаштыра ала, шуңа күрә уку процессы һәр укучы өчен нәтиҗәлерәк һәм кызыклырак була.

2. Белем бирү материалларын яхшырту: нейрон челтәрләре, дәреслекләр, видеодәресләр һәм интерактив укыту программалары кебек, белем

бирү материалларын яхшырту өчен кулланылырга мөмкин. Алар мәгълүматны аңлау һәм истә калдыру өчен материалларны җайлаштырырга һәм оптимальләштерергә булыша ала.

3. Биремнәрне автоматик тикшерү: нейрон челтәрләре биремнәрне автоматик тикшерү һәм укучыларның уңышларын бәяләү өчен кулланылырга мөмкин. Алар материалны аңлау дәрәҗәсен һәм башкарылган биремнәрнең сыйфатын бәяләү өчен текст җавапларын, графикларны, тавыш һәм видеофайлларны анализлый алалар. Бу укытучыларның эшләрне тикшерү өчен сарыф иткән вакытын кыскартырга һәм бәяләүнең объектив нәтиҗәләрен ачыкларга мөмкинлек бирә.

Нейрон челтәре ярдәмендә диктантларны һәм иншаларны тикшереп була. Укучыларның текстын нейрон тәрәзәсенә күчерегез һәм хаталар яки плагиат табуны сорагыз.

4. Чат-бот белән аралашу:

Укучылар бот белән үткән материал турында сөйләшә ала. Ботка сораулар биреп, балалар мәгълүматны яхшырак үзләштереп кенә калмый, ә аны тыңларга, анализларга, мөһим мәгълүматны аерырга өйрәнә.

Укучыларга ChatGPTтан өйрәнгән тема буенча контроль өчен сораулар төзергә тәкъдим итегез.

5. Нейрон челтәре ярдәмендә инша язуны кызыклырак итәргә мөмкин.

Кайбер укучыларга инша язу авыр. Алар кайдан башларга белмиләр. ChatGPT текстны башласын, ә укучы аны тәмамласын. Яки киресенчә: чат финалны бирәчәк, ә укучының бурычы – мондый финалга нинди сюжет китергәнен уйлап табу. Соңыннан сез алардан нейрон челтәре белән иншаларны тикшерүне сорый аласыз, аннары алар, аның фикере белән ризамы, дип сорарга мөмкин. Мондый мисаллар – мәктәп укучыларын стандарт булмаган фикер йөртергә, танылган әсәрләрдә яңа мәгънәләр күрергә һәм үз темаларын уйлап табарга өйрәтүнең яхшы ысулы.

6. Инша структурасын булдыру:

Иншаны авыр язучы балаларга нейрон челтәре белән текст структурасын төзергә тәкъдим итегез. Шулай итеп, аларга инде билгеләнгән план буенча мәгълүматны «арттыру» җиңелрәк булачак. Берничә төрле план һәм стильне сынап карагыз, аннары бала үз планы һәм стиле белән язарга өйрәнәчәк.

7. Балаларга сүз байлыгын киңәйтергә булыша.

Әгәр дә сез балаларны яңа сүз белән таныштырсагыз (мәсәлән, чит телдә), боттан бу сүзне берничә җөмләдә куллануны сорый аласыз. Контекст ярдәмендә балалар аның мәгънәсен яхшырак хәтердә калдырачак.

8. Мисаллар тудыру өчен нейрон челтәрен кулланыгыз.

Тиз арада укытучыга яңа термин өчен берничә мисал табу кыен булырга мөмкин. Ярдәмгә нейросеть киләчәк. Мәсәлән, сез рус телен укытасыз икән, сез чат-боттан катлаулы җөмләләрнең ун мисалын уйлап табуны сорый аласыз. Физика һәм математика укытучылары да әзер биремнәр ала ала. Сорауны мөмкин кадәр төгәлрәк төзергә кирәк.

9. Укучыларга характеристика, оешмаларга хат язу.

Хат – бик шәхси текст, әмма шул ук вакытта хат, характеристика, резюме языла торган шаблон бар. Нейросеть сезнең өчен конкрет кешенең өстенлекләрен һәм кимчелекләрен тасвирлый алмый: ул аның белән таныш түгел. Шулай да сез боттан шаблон буенча характеристика, хат, резюме язуны сорый аласыз, бары тик укучының сыйфатларын: төгәллеген һәм җаваплыгын билгеләү мөһим.

10. Укучының әти-әнисе, укучының үзе белән сөйләшү шаблоны булдыру.

Бер укытучы да әти-әнисенә аларның баласы сугышкан яки чиректә икеле алган дип әйтергә теләми. Моннан тыш, сезгә бу тема буенча мәктәп укучылары белән әңгәмә үткәрергә кирәк булырга мөмкин. Моны эшләү җиңел түгел. Нейрон челтәре сезнең өчен мондый сөйләшү планын төзи ала. Ә сез, әлбәттә, монологка үз фикерләрегезне өстәрсез.

11. Исемлекләр төзегез.

Сыйфатлар исемлеге кирәкме? Монархияле хакимият режимы булган илләр? «А» хәрефеннән башланган химик элементлар? Чат-бот берьюлы берничә исемлек төзи ала, сез аларны балаларга җибәрә аласыз.

12. Яшүсмерләр сленгы турында нейрон челтәреннән сорау.

Тел даими үсә, һәм балалар сленг һәм неологизмнарны актив кулланалар. Әгәр дә сез «кринж» яки «тейк»ның нәрсә аңлатканын белмәсәгез, сез ChatGPTтан моны аңлатуны һәм сүзләрне җөмләдә куллануны сорый аласыз.

13. ChatGPT белән фикер алышу.

Нейросеть эзләү системасыннан әңгәмә алып бара алу мөмкинлеге белән аерыла. Бот хәтта сезнең белән «үз» фикере аша уртаклаша ала. Бәхәсле сорау бирегез. Балалар белән нәтиҗә турында сөйләшегез – бу мәсьәләдә аларның фикерен белегез. Аларны нейрон челтәре белән бәхәсләшүне сорагыз – бу үз фикерен яклау күнекмәсен яхшы үстерә, әңгәмәдәш үпкәләми.

Гомумән алганда, нейрон челтәрләре белем бирү системасына уку процессын оптимальләштерү һәм персональләштерү өчен яңа мөмкинлекләр бирә. Алар белем бирүнең сыйфатын яхшыртырга, материалларны шәхси ихтыяҗларга яраклаштырырга һәм, гомумән, белем бирү процессының нәтиҗәлелеген арттырырга ярдәм итә ала.

18



# ШИҺАБ ХӘЗРӘТ УКУЧЫСЫ

**Ләлә МОРТАЗИНА,**

Ш .Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Х.Фәезханов исемендәге Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, педагогика фәннәре кандидаты

Татар мәгарифе күгендә якты йолдыз булып янган мәшһүр мәгърифәтчеләр арасында күренекле галим һәм педагог Хөсәен Фәезханов та бар. Татарлар арасында мәгърифәтчелек идеяләрен таратуга зур өлеш керткән бу шәхес халкыбызның иң мәшһүр галиме Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкерте һәм фикердәше буларак та киң җәмәгатьчелеккә яхшы билгеле.

Хөсәен Фәезхан улы Фәезханов 1823 елда элеккеге Сембер губернасы Сафаҗай авылында дөньяга килә. Туган авылында һәм Бәрәскә мәдрәсәсендә беркадәр белем алгач, Казанга килеп, Ш.Мәрҗанидән дәресләр ала, өстәмә рәвештә белемен арттыра: үзлегеннән татар, гарәп, фарсы, төрек телләрен, тарихын һәм әдәбиятын өйрәнә. Зур белемгә дәрте һәм сәләте булган шәкерт остазының киңәше белән Казан университетына ирекле тыңлаучы булып йөри. 1853 елдан үзе дә университетның Шәрык бүлегендә татар, гарәп, фарсы телләреннән, каллиграфия буенча дәресләр бирә башлый.

1855 елда Шәрык бүлеге Петербург шәһәренә күчерелә. Х. Фәезхановны да, күренекле шәркыятче галимнәр А.Казимбәк һәм И.Березин тәкъдиме белән, Петербург университетына төрек-татар теле укытучысы итеп чакыралар. Бу вакыйга аның олы фән юлына кереп китүенә зур этәргеч бирә, юл ача. Табигый сәләте, гарәп, татар телләрен һәм әдәбиятын төпле белүе, дөньяга карашы киң булу Х. Фәезхановны «үз белгечлеге буенча кем генә мөрәҗәгать итсә дә, аларның барысына да файда китерергә әзер торучы иң укымышлы укытучылардан берсе» итеп таныта. Бер үк вакытта ул үз белемен күтәрү өстендә дә ныклап эшли, В. Розен, В. Вельяминов-Зернов, Б. Дорн, П. Лерх кебек атаклы профессорлар, Көнчыгыш белгечләре белән аралаша, хезмәттәшлек итә, ориенталистика өлкәсендәге яңалыклар белән танышып, бу яңалыкларны үзенең остазы Ш. Мәрҗани белән даими рәвештә бүлешеп тора.

Х. Фәезханов Ш. Мәрҗани белән һәрчак аралашып, хат алышып торган, үзенең фикерләрен җиткергән, киңәш сораган. 1856 елда остазына язган хатта мондый юллар бар: «Аурупада һәркайда басма китап булса, шуны ике ай эчендә алмак мөмкин. Монда кибетләрдә каталог, библиография китаплары бар. Һәртөрле китап басыла, бөтен Аурупага мәгълүм була. Китапханәләрдәге китапларның да каталоглары басыла». Мондый кулланмалар фән белән шөгыльләнүчеләрнең эшен бермә-бер җиңеләйткән. Бу хәлне яхшы аңлаган Х. Фәезханов үзе дә китапларны барлау һәм рәткә салу эшенә тартылган. Рус ориенталистларының тәкъдиме белән ул мөселман китапларының каталогын һәм тасвирламасын эшләүгә алына, бу шатлыгын остазы белән дә уртаклаша.

Х. Фәезханов Ш. Мәрҗанигә рус телендә тарих китаплары сайлауда, фәнни эшчәнлеге өчен кирәкле әдәбият булдыруда зур ярдәм күрсәтә. Ул аңа яңа дөнья күргән китапларны җибәреп торган, фән дөньясы яңалыклары, Петербург галимнәренең эшчәнлеге, хезмәтләре белән таныштырган, бик кирәкле язмаларны остазы өчен татар теленә тәрҗемә иткән. Ш. Мәрҗанине атаклы шәркыятче галимнәргә танытуда да шәкертенең роле зур булган. Еш кына Петербург галимнәре Х. Фәезханов аша Ш. Мәрҗанидән киңәшләр сораганнар, төрки-татар тарихына, исламият мәсьәләләренә караган сораулар буенча ярдәм итүен үтенгәннәр.

Х. Фәезханов, үзенең төп эше белән беррәттән, тарихи истәлекләр, китаплар, кульъязмалар җыю белән дә шөгыльләнә, фәнни экспедицияләргә чыга, ярлыклар,

кабер ташларындагы язмаларны өйрәнә, фәнни мәкаләләр яза. Аның табышлары ориенталистика фәне үсешенә зур йогынты ясый. 1860 елда, мәсәлән, Археология җәмгыяте кушуы буенча, ул борынгы Касыйм шәһәренә экспедициягә чыга һәм шул вакытында татар һәм гарәп язулы кырык кабер ташы таба, 29 ташның күчермәсен алып, җәмгыятькә тапшыра. Академик В. Вельяминов-Зернов, әлеге мәгълүматларны файдаланып, «Исследование о касимовских царях и царевичах» дигән хезмәтен яза, Х. Фәезхановка ярдәме өчен рәхмәт белдерә.

Шәркыят галиме булу өстенә, Х. Фәезханов татар мәгарифенең үсеш юлларын билгеләгән, укыту системасына реформа ясау проекты авторы да. Аның хыялы – милләтен алга җибәрү, алдынгы милләтләр арасында күрү. Бу хыялын тормышка ашыру өчен, ул Казанда Европа мәктәпләре үрнәгендә зур бер мәдрәсә ачарга кирәк дип саный. Әлеге уку йорты, аның уенча, хәзинә хисабына яшәргә тиеш. Анда 60–70 шәкерт укыячак, моннан тыш, ирекле тыңлаучылар да булырга мөмкин. Бу мәктәптә дөньяви фәннәр дә, дини белемнәр дә өйрәтелә, гарәп, фарсы, рус, татар, Европа телләре укытылырга тиеш. Шәригать белеме гарәп телендә укытылса, география, табигать фәннәре – рус телендә, калганнары татар телендә укытыла. Мәктәпнең башлангыч сыйныфларында төрки, фарсы, гарәп, рус телләре, география, геометрия, кыйраәт (уку) укытылса, аннан соң укучылар укуларын ике бүлекнең берсендә – ислам бүлегендә яисә дөньяви бүлектә дәвам иттерәләр. Беренче бүлектә бик тирәнтен итеп шәригать фәннәре, гарәп, фарсы телләре, медицина һ.б. предметлар укытылса, икенче бүлек русларның гимназиясе күләмендә белем бирә, һәм аны тәмамлаган укучылар, һичшиксез, белем алуларын университетларда дәвам итә алачаклар, шулай итеп, татар милләтенең алгарышына ярдәм итәчәкләр. Бу зур хыял була, ләкин, кызганычка, ул тормышка ашмый кала…

Х. Фәезханов, татарларның үз туган телләрен өйрәнү кирәклеген раслап: «Чит телләрне өйрәнә башлаганчы, үз туган телеңне өйрәнергә, дөрес язарга һәм укырга өйрәнергә кирәк. Үз туган телендә укый-яза белгән кеше рус телен дә тизрәк өйрәнә, чөнки телләрне чагыштырып өйрәнә ала. Шуңа күрә барыбызга да мәҗбүри рәвештә туган телебезне, аның бөтен кагыйдәләрен өйрәнү тиеш…» – ди.

Х. Фәезхановның татар телен фәнни өйрәнү өлкәсендәге эшчәнлеге дә зур бәягә лаеклы. 1862 елда ул «Татар теленең кыскача уку грамматикасы»н язып бастыра, төрки телләр сүзлеген һәм хрестоматиясен төзи. Галимнәрнең билгеләвенчә, Х. Фәезхановның лингвистика өлкәсендәге тикшеренүләре татар сөйләм һәм язма теле формалашу юлларын ачыклауга, язма телне гарәп, фарсы сүзләреннән арындыруга зур өлеш кертә. Фәнни гыйлемнәргә ия булу белән бергә, халык тормышы, аның сөйләме белән дә бик яхшы таныш булуы уку әсбапларында халыкчан материалларны кулланырга мөмкинлек биргән. Бу исә язма, әдәби телне сөйләм теленә якынайтуга булышлык иткән.

Шиһаб хәзрәтнең иң сәләтле, иң мәшһүр шәкертләренең берсе булган Хөсәен Фәезханов, милләт файдасына эшлисе бик күп эшләрен калдырып, бик иртә – 1866 елда үпкә авыруыннан үлеп китә. Аның кыска, әмма гыйлем туплауга юнәлтелгән тормышы, күпкырлы эшчәнлеге бүген дә милләттәшләребезгә үрнәк булып тора.